ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

ISSN 0130-2418

1920 ЕЛДАН НӘШЕР ИТЕЛӘ

№ 2 (349)
ФЕВРАЛЬ 2021

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

ЛИЛИЯ ГАЛИМОВАНЫҢ «ЗӘҢГӘР ШӘЛЕ»

16+

Редакция:
420066, Казан,
Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина, vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров, sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасарлары:
Нияз Әхмәдуллин, ahmadullin@tatmedia.com
Алсу Дәүләтшина
Чыгарылыш мөхәррире:
Фәридә Әхмәтҗанова
Бүлек мөхәррирләре:
Олеся Бондаревская, Ольга Туманская, Руфия Фазылова
Веб-редактор: Алсу Дәүләтшина
Авторлар: Илдус Заһидуллин, Мөршидә Кыямова
Фотографлар: Александр Ефремов, Лилиана Вәлитова
Дизайн-макет: Леонид Гобәйдуллин
Вёрстка: Игорь Глушков, Леонид Гобәйдуллин
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Офис-менеджер: Ләйсән Һадиева
Тышлыкта: Рамил Гали фотосы

Журнал 1920 елдан нәшер ителә

1977 елда Халыклар дуслыгы ордены белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәттә теркәлгән. Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж:
2 300 данә

Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан» журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела. Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри. Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция җавап бирми.

Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә басылды: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ №: Е-424
Басарга кул куелды: 12.02.2021
Басмадан чыкты: 18.02.2021

Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Миләүшә Байрашева,
milyaushanb@tatmedia.com

Махсус проектлар бүлеге җитәкчесе:
Алсу Троицкая, alsu_1970@list.ru
тел.: (843) 222-09-79

Коммерция директоры:
Юлия Фәсәхова, 89272483384_pr@mail.ru
тел.: (843) 222-09-76, +7-9272-483-384

«Татарстан» журналы шулай ук рус телендә 2350 данә тираж белән чыга.
Гомуми тираж: 4650 данә
Реклама 16+

Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел. (843) 222-09-80

ЯЗ КӘЕФЕ

Урамда кыш, әмма күңел язны көтә. Басмабызның февраль саны да яз кәефен чагылдыра. Кышкы салкыннардан, бураннардан күшеккән күңелләребезгә язны кем китерә соң? Әлбәттә, гүзәл затларыбыз. Ватанны саклаучылар бәйрәме алдыннан ТР Президентының матбугат хезмәте җитәкчесе Лилия Галимова да безне татар халкының милли ризыгы – гөбәдия белән сыйлады. Гөбәдияне әзерләгән арада үз фикерләре, күзәтүләре, һөнәри хезмәте серләре белән дә уртаклашты. Кызыклы әңгәмә һәркемгә ошар, дип уйлыйбыз.

Февраль саны мәгълүматка шактый бай: ковидтан прививка ясату-ясатмау, аграр секторны цифрлаштыру темалары бүгенге көндә бик актуаль. Күп кенә күренекле татар зыялылары, шул исәптән Салих Сәйдәшев исеме белән бәйле Кызыл Байрак авылы укучыларыбызда кызыксыну уятыр, дип өметләнәбез. Республикабызның Кукмара районында урнашкан Починок-Кучук авылында уза торган мари халык бәйрәме белән таныштырабыз. Ә Әлки районы башлыгы Александр Никошин укучыларыбызга район буенча экскурсияне үзе үткәрә. «Кече Ватан патриотлары» дип аталган традицион рубрикабызда аталы гармунчы – Фәйзулла Туишевны искә алабыз. Бөек рус җырчысы Федор Шаляпин белән бергә концертлар куйган, Максим Горький белән таныш булган гаҗәеп язмышка ия шәхес. Үзе күптән бакыйлыкка күчсә дә, аның көйләре онытылмаган, безне язга якынлаштырып әле бүген дә яңгырый.

Сезнең әзләнүчән редакциягез

Редакция советы:
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рәфкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВ Разил Исмәгыйлевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзум Кәлимуллович
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

ТАТ МЕДИА

Гамәлгә куючы:
«ТАТМЕДИА» АҖ
Нәшер итүче:
«ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан,
Академическая ур., 2

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла
Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә
Индекс **П2381** – татар телендә
Индекс **П2378** – рус телендә
Ярты елга язылу бәясе: **942 сум 00 тиен**

«Татарстан» журналына РФ буенча онлайн-язылу:
Индекс **П7077** – татар телендә
Индекс **П7076** – рус телендә

100 яшь «ТАТАРСТАН» журналына

#ТАТАРСТАННЫҢ 100 җәүһәре

#бары тик ТАТАРСТАНДА

НЕМЕЦ ГЕНЕРАЛЫН БЕРЕНЧЕ ТАПКЫР КЕМ ӘСИРЛЕККӘ АЛГАН?

Сталинград сугышы барышында 23 генерал әсирлеккә алынган, ягъни бөтен сугышлар тарихындагыннан да күбрәк. Хәрби немец башлыгын беренче тапкыр әсирлеккә алган кеше Татарстанның Арча районында туып-үскән полковник Гани Сафиуллин була. Аның сугышчылары 1943 елның 25 гыйнварында генерал-майор Мориц фон Дребберны вермахтның пехота дивизиясе калдыклары белән бергә бирелергә мәҗбүр итә. Гани Сафиуллин Сталинградтан соң генерал-майор исемен алачак, корпус белән командалык итәчәк. Сафиуллин һәм аның корпусының тагын 72 офицеры һәм солдаты Советлар Союзы Геройлары булачак.

WWW.PROTATARSTAN.RU

© «Татарстан» журналы

ЭЧТӘЛЕК

акыллы гамәлләр

4. Вакцина әзер
Ковидтан прививка: ясатыргамы, юкмы?

6. Үзебездә сыналган
Вакцинаны кадаткан кешеләрнең фикерләре

12. Цифрлаштыру юлында
Аграр өлкәгә – яңа технологияләр

23. Космоска караганда мөһимрәк
Нинди һөнәргә һәрвакыт ихтыяҗ булачак

24. Ярдәмче роботлар
Компьютерның нинди гамәлләре савымнарда чагылыш таба

26. Нитратларсыз һәм пестицидларсыз
Экологик чиста яшелчә кайда үстерелә

игелекле эшләр

34. Редакция кухнясы
Татарстан Президентының матбугат секретаре бәйрәм хөрмәтенә нинди сый әзерләде

42. «Әбидә кунакта»
«Татарстан» журналы онытыла барган шөгыльләрне барлый

44. Заманча, үзенчәлекле, затлы
Ил буенча кайсы проектлар иң яхшылар дип табылды

46. «Алтын егермелек»
2020 елда Милли туристлык рейтингын кайсы төбәкләр җитәкләде

52. Җирдәге иң шәп урын
Әлки районы башлыгы нәрсә турында хыяллана

мәңгелек кыйммәтләр

60. Ир-атлар кырыс статистика күзгесендә
Көчле затлар нинди өстенлекләргә ия

64. Ватанны саклаучылар көне
Геройларны кем тәрбияли

70. «Кече Ватан патриотлары»
Күренекле гармунчы Фәйзулла Туишев турында

82. Татар авыллары
Кызыл Байракка сәяхәт

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта: **protatarstan.ru**

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

21.01

Татьяна ГОЛИКОВА, РФ Хөкүмәте Рәисе урынбасары:

– Чит ил кунаклары өчен Мәскәү һәм Санкт-Петербургның озак вакытлар дәвамында төп үзәк булуын сез беләсез инде. Россияне шуларга карап таныганнар. Хәзер мин шуны төгәл әйтә алам: Татарстан һәм Казан шулай ук үзенә җәлеп итә. Монда карар нәрсә дә, сөйләр нәрсә дә күп, уникаль тарихи фактлар сакланган. Татарстанга мин шәхси визит белән килдем, республика тарихы турында күп нәрсәләр тыңладым, кайберләре минем өчен ачыш булды. Татарстан яшьләрендә үз туган җирләренә, гореф-гадәтләренә мәхәббәт тәрбияләүләре бик яхшы.

26.01

Илсур Метшин, Казан мэры, – 18 нче шәһәр клиник хастаханәсе каршындагы яңа амбулатор травматология үзәгенә килгәч:

– Бу – космик корабльдер. Минем әнием сәламәтлек саклау өлкәсендә эшләде, ҮРХндә. Ул чакта табибларда нинди җиһазлар булган да хәзер ничек – искиткеч зур аерма. Хезмәтегез өчен рәхмәт сезгә. Халык өчен ул бик мөһим. Шәһәрдә медицина учреждениеләре инфраструктурасының үсеше, эш сыйфатының яхшыруы – җитди мәсьәләләр. Безне бу сораулар беренче ел гына борчымый, һәм әлеге җәһәттән күп нәрсәләргә ирештек инде.

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР



01.02

Аида Гарифуллина, Россия опера җырчысы, РФнең һәм Татарстанның атказанган артисты:

– Мин беренче тапкыр Ватиканда булдым һәм атаклы Папа залында җырладым. Әлбәттә, бу мине нык тәэсирләндерде. Шул ук вакытта үземә карата да зур кызыксыну тойдым. Папа Франциск белән кечкенә әңгәмә дә кордык. Кайсы яктан булуым турындагы соравына, Татарстан җырчысы, дип җавап бирдем.

акыллы гамәлләр

Акыллы гамәлләр

Мәңгелек кыйммәтләр

Игелекле эшләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Россия вакцинасы **КЕМНЕ** коронавирустан якларга сәләтле

Аграрийларга цифрлаштыру **НИ ӨЧЕН** кирәк

Компьютерның **НИНДИ** гамәлләре савымда чагылыш таба

КАЙСЫ тармак космостан перспективалырак

ЯСАТЫРГАМЫ, ӘЛЛӘ ЯСАТМАСКАМЫ?

Әлеге сорау бүген гаять актуаль. Сүз дөнья күләмендә таралган ковидтан прививка ясату турында бара. «Татарстан» журналының февраль саны – нәкъ шул турыда. Теманы дөрес һәм төрле яктан яктырту өчен без экспертларга, медицина хезмәткәрләренә һәм, әлбәттә, инде прививка ясатырга өлгергән кешеләргә мөрәҗәгать иттек. Укыгыз, уйланыгыз, нәтиҗәләр ясагыз. Әмма «Ясатыргамы, әллә ясатмаскамы?» дигән тыйнак кына сорауның исән калу турындагы бик җитди сорауга җавап була алуын да исегездән чыгармагыз.

Татарстанда коронавирустан массакүләм вакциналаштыру 18 гыйнварда башланды

Февраль башында*
14 100
кешегә «Спутник V» вакцинасы ясалды

Шулардан
2617
кеше икенче дозаны ясатты

Татарстанда
16 302
COVID-19 очрагы теркәлде

Шушы чор эчендә
12 812
кеше савыкты

Абруйлы белгечләр һәм чыганаклар «Спутник V» вакцинасы турында

Иң абруйлы медицина фәнни журналларының берсе – Lanzet басмасы битләрендә:
«Клиник тикшеренүләрнең өченче фазасы барышында «Спутник V» нәтиҗәлелекнең, иммуногенлыкның һәм куркынычсызлыкның югары дәрәҗәләрен күрсәтте. Вакцинаның нәтиҗәлелеге – 91,6%. Өлкән яшьтәгеләр өчен куркынычсызлык күрсәткечләре югары булып тора».

Мөхәммәт Мөнир, Ланкастер университетының молекуляр вирусология буенча лекторы:
«Спутник V» вакцинасының кайбер үзенчәлекләре аның бик перспективалы булуын раслый. Юнәлеш сыйфатында төрле ике аденовирусны куллану идеясе күп кенә алдынгы вакциналардан өстен тора».

Хильдегуд Эртл, Филадельфиядәге Вистар институтының Вакциналар һәм иммунотерапия үзәге профессоры:
«Вакцина авыруның җитди һәм үлем очракларын булдырмауда 100% нәтиҗәлелек күрсәтә».

*3 февральгә булган мәгълүмат. ТР Сәламәтлек саклау министрлыгы матбугат хезмәтеннән алынды

«Спутник V» вакцинасы турында 3 төп факт

Вакцинаның нәтиҗәлелеге – 91,6%. Дөньяда әлегә бары тик өч кенә вакцина 90%тан югарырак нәтиҗәлелек күрсәтте.

Аны кадаганнан соң бер генә аллергия реакциясе һәм анафилактик шок очрагы теркәлмәде.

Җитди өстәмә зарарлы йогынтыларның бик түбән дәрәҗәсе – 0, 27% (Pfizer – BioNTech – 0, 58%, Moderna – 0, 97%)

Нәрсәдән башларга*



1. Вакцина кадату өчен, бердәм 122 номеры буенча яисә РФ дәүләт хезмәтләренең бердәм порталында / ТР дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр порталында / поликлиникада язылырга.

2. Билгеләнгән вакытта вакциналаштыру пунктына беренче прививкага килергә.

3. Табибның барлык киңәшләрен үтәргә: өч көн дәвамында вакцина урынын юешләтмәскә, саунага йөрмәскә, хәмерле эчемлекләр кабул итмәскә, авыр физик эшләр эшләмәскә.

4. Беренче һәм икенче прививка арасындагы интервал – 21 көн. Шунысы мөһим: коронавирус йоктырмас өчен, бу вакыт дәвамында битлек кияргә һәм социаль дистанцияне сакларга кирәк. Алай булмаганда икенче прививка ясалмаячак.

5. Иммунитет вакцинаның икенче компонентын ясатканнан соң 2 атна үткәч барлыкка килә.

*Вакцина бушлай, 18 яшьтән өлкәнрәк кешеләргә ясала.

ҮЗЕМДӘ СЫНАДЫМ, ЯКИ КАРАР КАБУЛ ИТҮ ӨЧЕН ДҮРТ ФОРСАТ

Прививка ясатыргамы, юкмы? Бу сорау бик күпләрне бимазалый. Шул ук вакытта бик күпләр вакциналаштыру үзәкләренә барып, сорауларына җавап алып кайткан да инде. Гыйнвар ахырына андыйлар 13 меңгә якын кеше иде. Бу карарны кабул иткәндә, алар нәрсәгә таянган? Һәм процедураны ничек үткәргән?

«БАЛАЛАРГА ӘТИНЕҢ СӘЛАМӘТ БУЛУЫ КИРӘК»

Рәис Мостафин, Чистай районы үзәк дәваханәсенең баш табибы, медицина фәннәре кандидаты:

– 6 гыйнварда «Спутник V» вакцинасының икенче этабын ясаттым. Язмышны күпме сынарга, чир эләктермәгән һәр көн өчен Ходайга күпме рәхмәт укырга була инде? Эшем буенча меңә коронавируслы авырулар белән дә, авыруны йоктыру ихтималы булган кешеләр белән дә аралашырга туры килә. Шул ук вакытта балаларымның этиләре сау-сәламәт булуын да телим.

Исегезгә төшерәм, Россиядә коронавирустан өч вакцина эшләнде. Әлегә без аларның берсен – «Спутник V» дигәнен генә кулланабыз. Бу препаратның куркынычы юк, дип саныйм, һәм аңа ышанмаска да сәбәпләр юк. Россия галимнәре һәм вирусолог табибларның прививкалар буенча тәҗрибәләре шактый зур, алай гына да түгел, бу җәһәттән без – дөньяда алдынгылар рәтендә. Илебез тарихында йогышлы авыруларны җиңгән очракларны хәтерлисезме? 1960 елда Мәскәүдә кара чәчәк авыруы эпидемиясен туктатып калганнар иде. Ул вакытта берничә көн эчендә 10 миллионга якын кешегә прививка ясадылар, һәм ул дөньяда моңа кадәр күрелмәгән күләмдә вакцина салу очрагы булды!

Ковид авыруының өзлектерә, өстәлә торган формалары куркыныч. Безнең практикада танып, идарә итеп булмый торган хәлләр дә килеп чыга. «Спутник V» вакцинасы коронавирустан ике елга җитәрлек иммунитет бирергә сәләтле. Препарат нигезендә – аденовирус, мин аның белән авырдым һәм монда кот очарлык берни дә күрмим. Язгы-көзге чорларда без барыбыз да аны йоктырып алабыз! Шуңа карамастан, прививкадан өзлегеп, аппендицит, холецистит, аяк-кул сыну кебек авыруларны да шуның нәтиҗәсе итеп күрсәтергә тырышучы кешеләр табыла...

Гыйнвар ахырына «Спутник V» вакцинасын 195 кешегә ясадык. Һәркайсы белән элемтәдә тордык. Биш кешенең бераз гына температурасы булды. Дүртесенеке – иң күбе 37,4 кә җитте. Һәм миндә генә икенче уколдан соң берничә сәгатькә 38 гә кадәр күтәрелеп алды. Мондый реакцияләр ихтималлыгы препаратның аннотациясенә җентекләп язылган, һәм өзлегү булып саналмый. Бары тик кайберәүләрнең организмы иммунитетны шулай итеп булдыра.

«Спутник V» прививкасының беренчесен ясатуга ук кайберәүләр битлексез йөри, социаль ара калдырмый, кул юарга оныта башлый. Ә бит ковидка антитәнчекләр 4–6 атнадан соң гына формалаша башлый. Шушы вакыт эчендә ковид йоктырмас һәм үзеңнең ваемсызлыгыңны вакцинага сылтап калдырмас өчен сакланып йөрергә кирәк. Имештер, файдасы юк. Бар! Прививка ясатыгыз.

Фото: Александр Ефремов



«СӘЯХӘТ ИТҮ ҺӘМ АРАЛАШУ ТУРЫНДА ХЫЯЛ!»



Галина Арефьева, Яр Чаллы кешесе, лаеклы ялда:

– Без ирем белән прививкалар ясату турында массакүләм мәгълүмат чараларыннан укып белдек һәм шунда ук ясатырга карар иттек. Поликлиника да якында гына, бюрократик баскычлар аша да үтәсе булмады.

Икебез дә алтмышның теге ягында без, әлбәттә инде, шушы яшебезгә хроник авыруларыбыз да җитәрлек, иремдә – үпкәләрнең хроник төстәге обструктив авыруы. Шул рәвешле безгә коронавирус йоктыру икеләтә куркыныч. Прививкадан курыкмадык. Авырудан куркырга кирәк. Вакцинаны җиңел үткәрдек – бернинди тискәре йогынтысын сизмәдек.

Без төньяктан Татарстанга былтыр күчеп кайттык. Балаларыбыз монда, ерак түгел, Чувашиядә, туганнарыбыз яши. Туганнар белән очрашу безнең өчен бик мөһим. Фатирдан чыгып, бу якларны күреп кайтасы, кунакка йөрисе, оныклар карашасы килә. Бер сүз белән әйткәндә, сафта буласы килә әле! Вакцина безгә үзебезгә дә авырмаска, башкаларга да йоктырмаска мөмкинлек бирә. Менә шундый өметләр бездә.

«КОВИДНЫҢ НИ ИКӘНЕН БЕЛӘМ»

Наталья Головизнина, Яр Чаллы сугыш ветераннары госпиталенең кабул итү бүлеге өлкән шәфкать туташы:

– Без, медиклар, беренчеләрдән булып, прививка ясата башладык. Мин госпитальдә эшлим, COVID-19 турында ишетеп кенә белмим. Коронавирусның «икенче дулкыны» безгә пациентларның тагын да авыррак хәлдәгеләрен китерде. «Кызыл зона»да эшли торган хезмәттәшләрдән көн саен төрле хәлләр турында ишетү бер дә рәхәт түгел.

Мин вакцинаның ике этабын да үттем. Әлбәттә, ничек үткәрермен, дип борчылдым. Ихтималлыгы булган билгеләрдән – баш авыртуы, тән сызлавы, температура күтәрелүләр – берсе дә сизелмәде. Барысы да җиңел үтте. Антитәнчекләргә экспресс-тест та ясаттым – инде барлыкка килгәннәрме, шуны беләсем килде. Вәгъдә ителгәннән тизрәк тә барлыкка килгәннәр иде.

Прививкага күптән инде уңай карыйм – грипптан да ел саен ясатам. Әлбәттә, кешеләр шикләнә, яңа вакцинага ышанып бетмәүчеләр дә бар. Әмма мин аның көченә ышанам. Бүген безнең поликлиникага «Спутник»ның яңа партиясе кайта, хезмәттәшләрем арасында аны ясатырга теләүчеләр бар.

«ӘЛЕГӘ БАШКА САКЛАНУ ЧАРАСЫ ЮК»

Ирек Закиров, Буа якташлык җәмгыяте президенты:

– Без хатыным белән «65+» яшь аралыгына керәбез һәм прививканы күптән көттек. Мин моны акыллы кешеләр өчен бердәнбер дөрес юл, дип саныйм. Чөнки бу куркыныч авырудан башка төрле саклану чарасы юк бит. Коронавирустан дарулар да юк әле. Вакцина исә – бу йогышлы авыруга каршы максатчан рәвештә көрәшә торган чара.

Вакцинаның бер ампуласы биш кешегә исәпләнгән. Бу турыда ишеткәч, мин якын-тирәдәгеләрем белән сөйләшеп алырга булдым. Шулай итеп, хезмәттәшләремә дә, безнең якташлык җәмгыяте идарәсенең әгъзаларына да прививка ясату идеясе туды. Биш кеше – хатыннары белән ун кеше! Дөрес, моннан нindидер акция ясарга уйламадык та. Безнең арада Татарстанда билгеле кешеләр дә бар иде – ТРның халык шагыйре Ренат Харис, Казан архитектура-төзелеш университеты ректоры Рәшит Низамов... Ихтимал, бәлки, шул сәбәпле дә матбугат безнең турыда белеп алгандыр. Вакцинаның беренче этабын барыбыз да җиңел кичердек. Февральдә икенчесен ясатачакбыз.

ВАКЦИНА ӘЗЕР

Россиялеләрнең нибары 38 проценты гына коронавирустан саклану өчен вакцина ясатырга әзер. 58 проценты исә хәтта бушлай прививка ясатырга да җыенмый. Шул ук вакытта шулкадәр үк кеше (57 процент) чирне йоктырудан курка. «Левада» аналитика үзәге күптән түгел үткәргән тикшерену нәтиҗәләре менә шундый булып чыккан. Димәк, кешеләр вирустан гына түгел, бәлки аңа каршы вакцинадан да курка? Безнең хәбәрчебез бу турыда ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының баш эпидемиологы Дмитрий Лопушов белән әңгәмә корды.

V ДӘРӘҖӘДӘГЕ САКЛАНУ

– Дмитрий Владимирович, февраль азагына кадәр Татарстанга 190 мең доза чамасы вакцина кайтартылачак. Аз түгелме бу?

– Бу партияләрдән берсе генә әле. Без барлык халыкның 60 процентына вакцина ясатуны планлаштырабыз.

– Ә бу кирәкме соң? Республикада коронавируска каршы коллектив иммунитетның ничек формалашуы өйрәнелде, һәм нәтиҗәләр оптимизм уятырлык. Тикшерелә торган төркемдә коллектив иммунитет инде 2020 елның декабрендә үк 50 проценттан арткан...

– Без тикшерену нәтиҗәләрен шартлы рәвештә бөтен республикага тараттык, әмма бу бары тик математик модель генә. Әйе, без 3 мең кешене тикшердек, әмма калганнарны тикшермәдек бит. Шунлыктан җавап мондый: без халыкның 60 процентына вакцина кадарга тиеш.

– Ясалма юл белән булдырылган иммунитет табигый барлыкка килгәненнән аерылачакмы?

– Юк, ике очракта да вируска каршы антитәнчекләр ясалу процессы башлана. Һәм ул ике очракта да эшли.

– Вакцина ясау юлы белән булдырылган иммунитет COVID-19 чиреннән күпме вакыт саклаячак?

– Без 2 елга өметләнәбез – бу «Спутник V» вакцинасы тәэсиренең математик хисабы. Моннан тыш, гомер буена җитә торган күзәнәк иммунитеты төшенчәсен дә онытмаска кирәк. Ул кешедә конкрет бер йогышлы авыруга каршы булдырыла һәм кандагы махсус күзәнәкләр ярдәмендә гамәлгә ашырыла – кирәк вакытта алар антитәнчекләр җитештерә. Ягъни билгеле бер вакыттан соң антитәнчекләр юкка чыга, әмма кеше организмында аларны эшләп чыгарырга сәләтле күзәнәкләр кала. Мондый

Дмитрий Лопушов, ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының баш эпидемиологы

Фото Дмитрий Лопушов архивыннан

гомерлек иммунитет – пандемиядән иң шәп саклану чарасы ул. Кайчан булачак бу хәл? Әлегә төгәл җавап юк, без күзәтү процессында гына.

– Көзен дөньяда коронавирусның яңа штаммы пәйда булды. Бүгенге вакцина аннан саклаячакмы?

– Ул теләсә нинди штаммнарга каршы нәтиҗәле булачак, чөнки вакцина җитештерүдә вирустагы бөтен антигеннар кулланыла. Мутация процессында антигенның ниндидер бер өлеше үзгәрә, башка бөтен нәрсәсе үзгәрешсез кала. Шунлыктан «Спутник V» гади штаммнан да, Бөекбританиядә табылганыннан да, яңа гына Израильдә ачыкланганыннан да саклый.

КУРКУГА КАРШЫ ПРИВИВКА

– Күптән түгел барлык социаль челтәрләрне бер яңалык шаулатып алды: Арчада бер хатын-кыз прививка ясатканнан соң үлеп киткән. ТР Сәламәтлек саклау министрлыгы әлеге очрак буенча рәсми аңлатма бирде инде: хатын-кыз вакцина ясатуга бәйле булмаган сәбәптән дөнья куйган. Шулай да күп кешедә прививкадан курку бар. Әгәр мөмкин булса, аның зыянлы булмавына инандырыгыз әле.

– Препаратның кеше организмына, шул исәптән репродуктив функциягә дә китергән зыяны клиник сынауларның беренче этабында ук тикшерелгән инде. Нәтиҗә – «Спутник V» вакцинасы зарарлы түгел.

> – Препаратның кеше организмына, шул исәптән репродуктив функциягә дә китергән зыяны клиник сынауларның беренче этабында ук тикшерелгән инде. Нәтиҗә – «Спутник V» вакцинасы зарарлы түгел.

– Шулай да аны 18 яше тулмаганнарга кадамыйлар...

– Вакцина уйлап табучыларга өлкәннәрне саклау бурычы куелган иде, чөнки балалар коронавирус белән бөтенләй авырмый диярлек, йоктырсалар да, кагыйдә буларак, җиңел формада гына чирлиләр. Шунлыктан вакцинаның балалар организмына йогынтысы өйрәнелмәде. Әлегә. Тикшеренү быел башланачак. Әгәр инде вакцинаны кемгә кадарга ярамавына килсәк, теләсә нинди хроник яки йогышлы авыруларның кискен фазасындагыларга, аның компонентларына аллергия килеп чыгу ихтималы булучыларга, шулай ук иммунитетны көчсезләндерә торган препаратлар (мәсәлән, онкологик чирләрне дәвалаганда) кулланучыларга. Соңгы очракта вакцина бөтенләй тәэсир итмәячәк. Һәм шуның белән бетте.

– Кешеләрне иң куркытканы: бәлки, мин инде коронавирус белән чирлимдер, әмма бу турыда белмимдер, ә миңа тагын вакцина да кадап куйсалар... Мондый хәл бик куркынычмы?

– Куркыныч түгел, чөнки мондый хәлнең булуы мөмкин түгел. Әгәр кеше коронавирус белән каты авырый икән, аңа бу фазада беркем дә прививка ясамаячак. Ә менә инде инкубацион (симптомнарсыз) фаза чорында булу – башка вариант. Бу очракта да прививка башланып килгән чиргә берничек тә йогынты ясамаячак, аны көчәйтмәячәк.



Фото: Александр Ефремов

– Ә инде COVID-19 белән чирләргә өлгерүчеләргә нишләргә? Аларга вакцинаны кайчан ясатырга?

– Бу очракта антитәнчекләрнең күпме саклануын белү зарур. Быелтыр мартта ук чирләсәләр дә, хәзергә кадәр антитәнчекләре булган кешеләр бар. Шул ук вакытта, моннан 3 ай элек кенә авырсалар да, коронавируска каршы антитәнчекләре булмаучылар да бар. Без моның нигә шулай икәнен өйрәнәбез. Әлегә җавап мондый: вакцинаны сихәтләнгәннән соң 6 ай үткәч ясатырга кирәк.

ЧИКЛӘҮЛӘРСЕЗ?

– Ни өчен күпләп вакцина ясату өчен яңа технология буенча уйлап табылган «Спутник V» сайлап алынган? Ни өчен Новосибирскидагы «Вектор» Дәүләт вирусология һәм биотехнологияләр фәнни үзәгендә эшләнгән «классикага» якынрак «ЭпиВакКорона» түгел?

– Без вакцинаны сайламыйбыз һәм сатып та алмыйбыз – бу федераль бюджет хисабына эшләнә. Бүгенге көндә «Спутник V» күпләп җитештерү тулысынча җайга салынган бердәнбер вакцина булып тора. «ЭпиВакКорона» соңрак теркәлгән, аның җитештерү куәте көйләнә генә әле. Чыгару арткан саен, препарат әйләнешкә күбрәк керә барачак, шул исәптән безнең республикада да. Россиядә коронавируска каршы өченче вакцина да бар әле, ул чагыштырмача күптән түгел Россия Фәннәр академиясенең Чумаков исемендәге Федераль фәнни тикшеренүләр һәм иммунобиологик препаратлар эшләү үзәгендә уйлап табылды. Без аның да бераз вакыттан соң кулланышка керәсенә өметләнәбез.

– Һәм һәркем үзе өчен препаратны үзе сайлый алачакмы?

– Куллану буенча күрсәтмәләрдәге мәгълүматка нигезләнеп, аны табиб тәкъдим итәчәк. Хәзер вакциналарның эшләнү технологиясе нечкәлекләре турында сөйләү урынсыз дип уйлыйм: без бит столбняк һәм дифтериягә каршы нинди прививкалар булуын тикшереп тормыйбыз – барабыз да ясатабыз. Республиканың 10 мең кешесенә вакцина ясату нәтиҗәләре шуны ачык күрсәтә: «Спутник V» эшли. Әлбәттә, «ЭпиВакКоронаны» да, Чумаков вакцинасын да кәтәргә була, бу һәркемнең үз ихтыярында, әмма шуны төгәл аңлау зарур: чирләп китү куркынычы арта бара. Мондый көтүнең нәтиҗәсе бик аяныч тәмамланырга мөмкин. Әлеге өч вакцина үзләренең техник башкарылышы буенча бик төрле, әмма аларның төп параметрлары абсолют бертөрле – куркынычсызлык һәм нәтиҗәлелек.

– Россия вакциналары чит илләрнекеннән калышмыймы? Ә чит ил вакциналары безгә кайтартылачакмы?

– Алар Россиядә теркәлү кенәгәсе алган очракта гына. Ә инде чит ил вакциналарының яхшыракмы яки начарракмы икәнен мин әйтә алмыйм. Кызганычка, алар турында җентекле мәгълүматны мин хәтта абруйлы журналларда басылган фәнни мәкаләләрдә дә тапмадым.

– Вакцина ясату якын киләчәктә безнең тормышны ничек үзгәртәчәк?

– Әгәр ул кирәкле күләмдә үткәрелсә, без бөтен чикләү чаралары хакында онытa алачакбыз. Кешелек күнегелгән тормышына кайтачак. Мин, киләчәктә COVID-19 чиренә каршы вакцина ясату елына берничә тапкыр үткәрелер, дип уйлыйм. Һәм әгәр вирус структурасында берниндi куркыныч үзгәрешләр килеп чыкмаса, бүгенге пандемия кебек хафалы афәт бүтән кабатланмаячак.

– Ә сез үзегез вакцина ясаттыгызмы инде?

– Юк, чөнки мин авырдым инде. Киләчәктә, вакыты җитүгә үк, һичшиксез, прививка ясатачакмын.

Фото Альберт Ризванов архивыннан

ИҢ ЯХШЫ ВАКЦИНА

Прецизион һәм регенератив медицина фәнни-клиник үзәге директоры, КФУның Фундаменталь медицина һәм биология институты генетика кафедрасы профессоры Альберт Ризванов COVID-19 яңа коронавирус инфекциясенә каршы тагын бер вакцина булдыру белән шөгыльләнә. Шулай да ул хәзерге вакцинаны иң яхшысы, дип саный.

– Россиядә теркәлгән беренче ике вакцина – «Спутник V» һәм «ЭпиВакКорона» – 90 процентттан артыграк нәтиҗәлелеккә ия, – ди Альберт Ризванов. – Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы исә нәтиҗәлелеге 50 процентттан югарырак булган вакцинаны кулланырга ярый, дип саный. Ягъни әлеге ике препарат минималь нормадан күпкә өстенрәк. Чумаков институтында уйлап табылып, хәзер теркәлү үтә торган Россиядәге өченче вакцинаның нәтиҗәлелеге бераз кимрәк. Әмма ул традицион технология буенча ясалган һәм киңрәк комплекслы иммунитет барлыкка китерә: ул ниндидер бер генә аксымга каршы түгел, бәлки бөтен коронавируска каршы эшли. «Спутник V» – теркәлгән вакциналардан беренчесе, ул яңа технология нигезендә булдырылган һәм коронавирус тышчасына S-аксым генын китереп җиткерү өчен вектор сыйфатында кеше аденовирусы кисәкчекләрен файдалана, шуннан соң аңа каршы антитәнчекләр эшләнә башлый. Экспертлар фикеренчә, бу иммун җавап тудыруның бик нәтиҗәле ысулы. Әмма кешедә коронавируска каршы гына түгел, аденовируска каршы да антитәнчекләр барлыкка килү ихтималы бар. Бер яктан караганда, бу яхшы, чөнки безне аденовирус инфекциясеннән дә саклаячак. Икенче яктан караганда, кайбер кешеләрдә аденовирусларга каршы иммунитет инде булырга мөмкин, бу исә вакцинаның нәтиҗәлелеген киметергә ихтимал. Нәкъ менә шуңа «Спутник V» ике компоненттан тора – әлеге ихтималны киметү өчен. Моннан тыш, шул ук вакцинаны кабат кадату белән проблема килеп чыгарга мөмкин, чөнки организм коронавируска каршы гына түгел, бәлки вакцинаның үзенә каршы да иммунитет булдырачак. Һәм инде, әлбәттә, яңа технологиянең киләчәктә нинди зыян китереп чыгарачагын әлегә бәяләү кыенрак. Сынауның беренче стадиясендә кискен тәэсирләр – организмның якындагы көн һәм айларда үзен ничек тотасы бәяләнә. Еллар үткән саен нәрсә буласын шул вакытта гына беләчәкбез. Хәер, вакцинаның куркынычсызлыгында шикләнү өчен теоретик сәбәпләр юк – өстәмә тәэсирләр ихтималы бик аз.

Шәхсән мин үзем «Спутник V»ны куркынычсыз дип саныйм һәм хәтта әниемә дә вакцина ясатырга киңәш бирдем, чөнки ул – бүген Татарстанда кулланырга рөхсәт ителгән бердәнбер вакцина. Вакциналардан иң яхшысы – хәзер кадатып була торганы, чөнки коронавирус инфекциясе белән бәйле зыян прививкадан соң килеп чыгарга мөмкин булган зыяннан меңнәрчә тапкыр артыграк. Мин үзем әлегә вакцина ясатырга җыенмыйм. Чөнки коронавирус белән чирләдем инде. Антитәнчекләрнең күпмегә җитәчәген әлегә беркем дә белми. Һәм кешедә иммунитет үзенчә барлыкка килә. Популяция позициясеннән караганда исә әлеге вакыт якынча 8-12 ай тәшкил итә. Һәрхәлдә, башка коронавируслар якынча шундый иммунитет булдыра. Шунысын белү мөһим: беренче уколдан соң иммунитетның тулысынча формалашуына кадәр ике айлап вакыт таләп ителә. Тагын бер мөһим нюанс бар: вакцина кешене вирустан 100 процентка сакламый. Юк, без «кабырчык эчендә» калмыйбыз, чөнки өч вакцина да, стерильләштереп, инфекцияне 100 процентка булдырмый торган түгел. Әмма алар инфекциянең бик авыр кичерелүеннән саклаячак, дигән өмет зур. Нәкъ менә шуңа күрә прививкадан соң да Сәламәтлек саклау министрлыгының социаль дистанцияне саклау һәм битлек киюгә кагылышлы киңәшләрен тоту зарур. Моның белән без үзебезне генә түгел, әйләнә-тирәдәгеләрне дә саклаячакбыз. Чөнки, әгәр син вакцинадан соң симптомнарсыз чирләп китәсең икән, димәк, моны белмичә, башкаларга авыруны йоктыра аласың.

Әңгәмәдәш:
Ольга Туманская

Авыл хуҗалыгын цифрлаштыру

Азык-төлек иминлеге һәм авыл хуҗалыгы продукциясенең көндәшлеккә сәләтлелеге – болар кыен яраша торган бурычлар кебек тоела, базар шартларында кайвакыт берсе икенчесенә каршы да килә. Әмма Татарстан аграрийлары әлеге каршылыкларны шактый уңышлы җиңеп чыга. Аларга әлеге эшләрендә цифрлы технологияләр, дәүләтнең республика һәм федераль бюджетлар хисабына финансланган ярдәм программалары булыша. Тармакның былтыргы эшенә нәтиҗә ясар өчен һәм «ТатАгроЭкспо» форумын үткәрер алдыннан без ТР вице-премьеры, ТР авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Җаббаровтан кайбер сорауларыбызга җавап бирүен үтендек.

– Марат Азатович, бүген авыл хуҗалыгын цифрлаштыру турында сөйләү киң таралды. Бу безнең ерак киләчәкме?

– Агросәнәгать комплексын цифрлаштыру безнең өчен абстракт төшенчә түгел, бәлки конкрет һәм уйланылган карарлар кабул итү, алар инде бүген үк сизелерлек нәтиҗә күрсәтә, хезмәт җитештерүчәнлеген һәм авыл хуҗалыгы җитештерүенең нәтиҗәлелеген, предприятиеләрнең рентабельлелеген арттыру мөмкинлеген бирә, республиканың ветеринар иминлеген тәэмин итәргә булыша.

Шуннан башлыйк: хайваннар һәм кеше өчен хәвефле чирләрнең республика территориясенә керү һәм таралу куркынычы аграрийлар, фермерлар һәм шәхси ярдәмче хуҗалык тотучы гражданнар өчен иң актуаль һәм мөһим проблемалардан берсе булып тора. Шунлыктан моны булдырмау, шулай ук куркыныч чир тудыручыларның республикабыз территориясендәге чыганакларын һәм таралу юлларын ачыклау өчен, мөгезле эре терлекне бердәм тәңгәлләштерүне кертү эшен башладык.

Әлеге тәңгәлләштерүнең асылы шунда: бозауның бер колагына уникаль сан һәм QR-кодлы тамга, икенчесенә исә бердәм мәгълүмат системасында теркәлгән электрон чип урнаштырыла. Ветеринария хезмәте һәр бозауга ветеринария паспорты ача, анда хайванга кагылышлы барлык мәгълүмат теркәлә бара. Телефонын тамгадагы QR-кодка юнәлтеп, теләгән һәркем хайванның әлеге паспорты белән таныша ала.

Бүгенге көнгә республика буенча хайваннарны исәпкә алу программасында 18,5 мең баш мөгезле эре терлек (барлык терлекнең 3%ы) тәңгәлләштерелгән һәм теркәлгән. 2021 елда республикадагы барлык мөгезле эре терлекне тәңгәлләштерү бурычы куела.

– Ә агросәнәгать җитештерүенә, авылдагы кече бизнеска цифрлы технологияләр кертүнең конкрет мисаллары бармы?

– Терлекчелек предприятиеләрендәге җитештерү процессына цифрлы технологияләр кертү буенча колачлы эшне без 2020 елда башладык. Һәр районда хайваннарны көтү һәм тукландыру белән идарә итәрлек программалар кертелә торган база хуҗалыкларын билгеләдек. Инде беренче уңышлар да бар, аларның нәтиҗәлелеге хәтта авыл хуҗалыгыннан бик ерак торучы кешегә дә аңлашыла.

Теләче районындагы «Агролак» хуҗалыгында сөт терлекчелегендә цифрлы технологияләр кулланылган ярты ел эчендә савым сыерларының продуктивлыгы - тәүлегенә 2,2 килограммга, хайваннарның җитештерү күрсәткечләре 14% ка артты. 380 баш сыер асралган авыл хуҗалыгы предприятиесе сөт сатудан 4 миллион сум өстәмә керем алды. Әмма хуҗалык ирешелгәнгә канәгать булып туктап калырга җыенмый. Заманча бозау абзары файдалануга тапшырылган, бозауларга эчертү өчен пастеризаторлы үзйөрешле сөт таксие сатып алынган. Шулай ук азык үзәге бик тиз төзелеп ята.

Фотолар ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы матбугат хезмәтеннән алынды

Ә Актаныш районындагы «Әнәк» агрофирмасында инде 3 ел дәвамында көтү белән идарә итү программасы эшли, шулай ук узган ел башында хайваннарны туендыру белән идарә итү системасы да урнаштырылган. Технологияләр хуҗалыкка, сыерларның баш санын арттырмыйча да, бозаулар үрчемен 148 башка җиткерү, аларның яшәүчәнлеген саклау мөмкинлеген биргән. Әлеге эш чорында, продуктлылыкны арттыру хисабына, сөт сатудан 89 миллион сум өстәмә табыш алынган. Шул ук вакытта терлекне ашату белән идарә итү һәм рационнарны баланслау ел саен 17 миллион сумлык азыкны янга калдыру мөмкинлеге бирә.

Бүгенге көнгә республика буенча хайваннарны исәпкә алу программасында 18,5 мең баш мөгезле эре терлек (барлык терлекнең 3%ы) тәңгәлләштерелгән һәм теркәлгән. 2021 елда республикадагы барлык мөгезле эре терлекне тәңгәлләштерү бурычы куела.

Терлекчелектә цифрлаштыру һәм автоматлаштыру процессларын кертү җитештерүнең хезмәт күләмен киметүгә, ә хезмәт җитештерүчәнлегенең артуына булыша. Хезмәткә түләү системасы да камилләшә. Мондый мисаллардан берсе – Тукай районындагы «Вятские Зори» хуҗалыгы. 2020 елда предприятиедә хезмәт җитештерүчәнлеге шактый яхшырган. Бер хезмәткәргә акча кереме 53% ка арткан һәм 6,2 миллион сумны тәшкил иткән. Шулай ук азык янга калдырылган, аны төягәндә югалтулар кимегән. Нәтиҗәдә азык чыгымын экономияләү аена 7 миллион сум акчаны янга калдырган.

Шунысы да мөһим: предприятиеләрнең цифрлы технологияләр кертү нәтиҗәсендә алынган өстәмә керемнәре җитештерүне модернизацияләүгә инвестицияләнәчәк.

– Бүген республика авыл хуҗалыгы продукциясенең күп төрләрен җитештерү буенча әйдәп баручылардан санала. Әмма соңгы елларда без берничә тапкыр шуңа инандык инде: югары тулаем күрсәткечләр һәрвакытта да югары табышны аңлатмый...

– Шунысын аңлау мөһим: авыл хуҗалыгы – бизнес һәм табыш кына түгел әле ул. Безгә республиканың азык-төлек иминлеген тәэмин итү бурычы да йөкләнгән. Икенче төрле әйткәндә, без халык ихтыяҗын тәэмин итәрлек күләмдә продукция җитештерергә тиеш. Шунлыктан авыл хуҗалыгы җитештерүчеләренә дәүләт ярдәме чаралары каралган. Әйтик, ТР Хөкүмәте, Россия авыл хуҗалыгы министрлыгы карарлары белән 2020 елда авыл хуҗалыгы җитештерүчеләренә 13 миллиард сум дәүләт ярдәме бүленгән. Бөтен ил өчен авыр ел булса да, барлык ярдәм чаралары тулы күләмендә сакланган.

Татарстан Республикасы Алексеевск районының ерак бистәсендә авыл кибете ачылышы.

Нәтиҗә буларак шуны әйтергә була: икътисадның барлык секторларында күрсәткечләр начараюга карамастан, Татарстан аграрийлары 2020 елда җитештерү индексын 104% ка җиткерә алды. Моннан тыш, бүген без республика халкын барлык төп туклану продуктлары (ит, сөт, май, йомырка, икмәк, шикәр һ.б.) белән тулы күләмдә тәэмин итәбез һәм авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерү буенча Россия Федерациясендә беренче урыннарны алып торабыз.

Авыл хуҗалыгы җитештерүчеләренә без һәрвакыт шуны җиткерәбез: гектардан ничәдер центнер уңыш алу күрсәткечләре артыннан куарга кирәкми, гектардан алынган табышка, авыл хуҗалыгы җитештерүенең рентабельлелегенә йөз тоту мөһим.

Шуңа күрә без игенчелекнең чыгымнарны киметүгә һәм басуның нәтиҗәлелеген арттыруга юнәлтелгән системасын булдырырга омтылабыз. Югары җитештерүчән заманча техника куллану, җир ресурсларыннан нәтиҗәле файдалану, сортларны яңарту, үсемлекләрне сыйфатлы һәм үз вакытында саклауны тәэмин итү һ.б.ның зарурлыгы ачык. Әлбәттә, без боларның барысын да кулланырга киңәш итеп кенә калмыйбыз, әлеге чараларга субсидияләр дә бирәбез, шуның белән нәтиҗәлелеккә омтылган авыл хуҗалыгы җитештерүчеләренә ярдәм итәбез.

Ә инде авыл хуҗалыгы продукциясенә булган бәяләргә килгәндә, алар республикадагы җитештерү күләменә генә бәйле түгел. Бәяләрне дөнья базары формалаштыра. Шунлыктан 2021 елга, мәсәлән, үсемлекчелек буенча бурыч – җитештерү күләмен (агымдагы елга нисбәттә) 105% ка җиткерү һәм үзкыйммәтне 5%ка киметү. Югары уңыш алу шартлары исә мондый: оптималь структура, сыйфатлы орлык, уңышны формалаштыру (тукландыру һәм саклау) белән идарә итү, технологик дисциплина һәм югары квалификацияле кадрлар.

– Авыл хуҗалыгы продукциясен эшкәртү азык-төлек тотрыклылыгының мөһим өлеше булып тора. Аны үстерү өчен республикабызда ниләр эшләнә?

– Әлбәттә, үзебездә җитештерелгән продукцияне үзебездә үк эшкәртергә дә кирәк. Бары шулай гына өстәмә кыйммәт алып була. Без моны аңлыйбыз һәм хәл итәргә тырышабыз. Республикада 2020 елның 11 аенда ашамлыклар җитештерү индексы 2019 ел белән чагыштырганда артты һәм 114,2% ны тәшкил итте. Һәм без эшкәртү күләмен арттыруны планлаштырабыз.

Инвестицион үсеш агентлыгы ярдәмендә без азык эшкәртү сәнәгатендә 80 инвестицион проект буенча эш алып барабыз. Аларның гомуми бәясе – 57 миллиард сум.

Татарстан – Россиядә сөт җитештерү буенча лидер. Шуңа күрә сөт продукциясен эшкәртүгә дә аеруча игътибар бирелә. Сөт тармагына инвестицияләр якынча 5 миллиард сумны тәшкил итәчәк. Бу сөт эшкәртү күләмен тәүлегенә 1,5 мең тоннага җиткерү мөмкинлеген бирәчәк.

– Тагын бер мөһим бурыч – сату. Татарстан халкы үз республикасында җитештерелгән продукцияне сатып алырга тели. Моның өчен нәрсә эшләнә?

– Кулланучыларның Татарстанда җитештерелгән продукцияне сатып алу теләген аңлап була. Моның өчен бөтен мөмкинлекләр дә бар. Безнең товарлар сәүдә челтәрләрендә шактый күп, алар халыкның барлык категорияләре дә сатып алырлык.

Икмәк пешерү предприятиеләренә 2020 елда республика бюджетыннан субсидияләр бүлгәне өчен Татарстан Президенты Рөстәм Нургали улы Миңнехановка рәхмәтемне җиткерәсем килә. Чыгымнарның бер өлешен капларга тәгаенләнгән әлеге субсидияләр икмәккә бәяне арттырмау гына түгел, җитештерүнең күләмен, шулай ук предприятиеләрдәге эш урыннарын саклап калырга мөмкинлек бирде.

Азык-төлек продуктларын сатуда ярминкәләр мөһим роль уйный. Алай гына да түгел, күпчелек фермерларыбыз һәм күмәк фермер хуҗалыклары өчен ярминкәләр продукция сатуның төп урыны булып тора. Дәүләт аграрийларга бушлай сәүдә урыннары бирә, аларның транспорт чыгымнарын каплый, нәтиҗәдә һәркем, беренче чиратта, әлбәттә, ашамлыкларны сәүдә челтәрләрендәгедән арзанрак бәягә сатып алган халык ота.

«Казан» агросәнәгать паркы эшен аерым билгеләп үтәр идем, ул хәтта пандемия шартларында да штат режимында эшләде.

– «ТатАгроЭкспо» кебек зур форумнар үткәрү нәтиҗәлеме? Булачак күргәзмәдән нәрсәләр көтәсез?

– 2021 елның 10–12 февралендә «Казан Экспо» Халыкара күргәзмәләр үзәге территориясендә 3 нче махсуслашкан «ТатАгроЭкспо» күргәзмәсе үткәреләчәк. Бирегә без агросәнәгать комплексының төп тармаклары экспозициясен һәм эшлекле форумны берләштерәчәкбез.

Үткән еллар буенча бәяләгәндә, әлеге чараның актуаль проблемаларны тикшерү, яңа эшлекле элемтәләр урнаштыру, үз продукциясен һәм эшкәртүләрен тәкъдим итү, шулай ук инвесторлар игътибарын җәлеп итү белән кызыксынган меңләгән агробизнес вәкилен үзенә җыюын күреп була.

Быел күргәзмә экспозициясе яңа «Хронологик чылбыр» концепциясендә тәкъдим ителәчәк. Аның кысаларында агросәнәгать комплексының бөтен төп тармаклары (үсемлекчелек, терлекчелек, авыл хуҗалыгы техникасы) технологик эзлеклелектә күрсәтеләчәк.

Хуҗалык итүнең кече формалары һәм авыл хуҗалыгы продукциясен эшкәртү блогында Татарстанда җитештерелгән иң яхшы ит, сөт, май, икмәк продукциясе тәкъдим ителәчәк; фән блогында тармак уку йортлары үз казанышларын һәм проектларын күрсәтәчәк; цифрлаштыру блогы агросәнәгать комплексы өчен ИТ-чишелешләр тәкъдим итәчәк.

Республика агросәнәгать комплексларында инвестицион проектларны тәкъдим итү күргәзмәнең яңалыгы булачак. Катнашучылар аларның гамәлдәгеләре һәм аеруча өметлеләре белән танышачак. Күргәзмә экспозициясендә Россия Федерациясенең 30 төбәге һәм 50 шәһәреннән барлыгы 200 дән артыграк предприятиенең, әйдәп баручы чит ил компанияләре вәкилләренең катнашуы көтелә.

Мин «ТатАгроЭкспо» – эшлекле хезмәттәшлек урнаштыру һәм ныгыту, тармакны үстерүнең актуаль мәсьәләләрен тикшерү һәм агросәнәгать комплексының соңгы казанышлары белән танышу өчен уникаль мөмкинлек, дип саныйм!

Әңгәмәдәш: Нияз Әхмәдуллин

0+

* Айти

ИПИ ИСЕ, ИПИ ТӘМЕ...

2020 елда республика компанияләренә бик авыр мәсьәләне чишәргә туры килде: кырыс локдаун шартларында продукция күләмен һәм сыйфатын саклап калу кирәк иде. «Чаллы икмәге» компанияләр төркеме мондый бурычларны лаеклы үтәп, халыкны тәмле һәм файдалы ризыклар белән тәэмин итүне киметмәү генә түгел, үсешкә таба яңа адым да ясады – җитештерүне модернизацияләү программасы кысаларында яңа линия эшләтеп җибәрде.

МИЧТӘН ГЕНӘ ЧЫККАН КЕБЕК

2020 елда компанияләр төркеме өчен төп вакыйгаларның берсе – рустикаль икмәк пешерү өчен, Испаниядә эшләнгән югары технологияле заманча линияне эшләтеп җибәрү булды. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: мондый линияләр илнең берничә икмәк пешерү предприятиесендә генә кулланыла. Рустикаль икмәкләрнең ассортиментын: француз багетлары, арыш оныннан багетлар, эре бөртекле багетлар, Артизан ипие, җитенле, мүк җиләкле ипиләр һәм төрле Панини күмәчләрен җитештерү күләме сәгатенә 500 кг га кадәр җитәр, дип планлаштырыла. Бу продукция сатып алучылар арасында бик популяр. Рустикаль дип, әле генә авыл миченнән чыккан ипигә бик охшаган ипиләрне атыйлар. Мондый икмәкнең бик камил булмаган формасы һәм тышкы кыяфәте үзенчә ымсындырып тора. Бу ипинең сындырган урыны хуш исле һәм кабарып тора. «Чаллы икмәге» компаниясендә икмәк пешерү традицияләренә зур игътибар бирелә, шуңа күрә рустикаль камырның әзер камыр ашлары өчен дигәне дә, ярымфабрикатларга дигәне дә кимендә бер тәүлек кабартыла. Ә заманча җиһазларда пешерү исә файдалы, хуш исле, озак саклана торган тәмле икмәк җитештерергә мөмкинлек бирә. Нәкъ авыл миченнән чыккан кебекне...

«ТУҢДЫРУ» ВАКЫТЫ

Катлаулы 2020 елда «Чаллы икмәге» компанияләре төркеме хезмәт хакларын 10% ка индексацияли алды. Моңа исә нигездә предприятиенең технологияләрне һәм ассортиментны даими камилләштерүе, дөнья һәм ил базарларындагы тенденцияләрне һәрвакыт күзәтеп баруы аша ирешелде. Әйтик, туңдырылган һәм суытылган икмәк-күмәч ярымфабрикатларын җитештерү азык-төлек базарында үсешкә барган трендларның берсе булып тора. Андый ярымфабрикатлар кунакханәләргә, кафеларга, рестораннарга һәм супермаркетларга клиентларны теләсә кайсы вакытта һәм кирәкле күләмдә яңа пешкән икмәк һәм күмәч белән тәэмин итү мөмкинлеге бирә. «Чаллы икмәге» компаниясе – үсеш кичерүче ярымфабрикатлар базарында барлык төр продукцияне «туңдыру» эшен башлап җибәргән тәүге предприятиеләрнең берсе. Моның өчен предприятиедә яңа цех ачылган, анда югары технологияле Австрия җиһазлары ярдәмендә компания тәүлек саен 7 тоннага кадәр ярымфабрикат җитештерә. Алар озак вакыт дәвамында кабара торган чүпрә белән әзерләнә. Әзер продукция махсус суыту комплексында саклана. «Туңдырыла» торган камыр гадәттәгечә кабарттырылганга күрә, 5-10 минут эчендә җылытып алынган икмәк-күмәчләр яңа пешкәннән тәме һәм сыйфаты ягыннан бер дә аерылмый.

УҢЫШ БАШЫ

Тышкы шартларга карамастан тотрыклы эшләүнең җайлашу сәләтенең, продукция сыйфатын даими камилләштерүнең нигезе – «Чаллы икмәге» компанияләр төркеменең үз ресурс базасы һәм яхшы үсеш алган җитештерү инфраструктурасы. Икмәк-күмәч пешерү өчен кирәкле 100% ашлыкны компания үзенең «Туган як» агрофирмасы карамагындагы 25 мең гектар мәйданда үстерә, бу агрофирманың җирләре Татарстанның Сарман, Мөслим һәм Минзәлә районнарында урнашкан. Соңгы биш елда компания

Реклама. Фотолар «Чаллы икмәге» компанияләре төркеме матбугат үзәгеннән алынды

агрофирманы үстерүгә 450 млн сумнан артык акча тоткан. Аның территориясендә 40 мең тоннага кадәр һәм аннан да күбрәк күләмдә ашлык кабул итү, чистарту, киптерү һәм саклау буенча биналар һәм җиһазлар булдырылган. «Чаллы икмәге» тегермән-элеватор комплексы дүрт тегермән белән җиһазландырылган һәм тәүлегенә 150 тоннага кадәр ашлык эшкәртә. Бу бүлекчәнең өзлексез эшләве компаниянең җитештерү департаментларын үзендә тарттырылган он белән 100% тәэмин итәргә мөмкинлек бирә. «Чаллы икмәге» продукциясе ассортиментында 400 дән артык төрдәге икмәк-күмәч ризыгы бар: классик мич төбе икмәге һәм калыплы икмәкләр, эре бөртекле ипиләр, батоннар, коры вак клиндерләр, баранкалар, милли тәм-томнар, тортлар, вафли, прәннек һәм печеньелар. Соңгы биш елда җитештерү тармагына 900 млн сумнан артык инвестиция кертелгән. Технологияләрне модернизацияләгәндә, компания икмәк пешерү буенча дөньяда һәм Европада танылган ширкәтләргә йөз тота. «Чаллы икмәге» белгечләре дөньядагы иң билгеле брендларның вәкилләрендә стажировка үтә.

Ә БӨТЕН СЕР – ТЕРЕ, ГАҖӘЕП БАКТЕРИЯЛӘРДӘ

«Чаллы икмәге»нең җитештерү департаментлары икмәк җитештерү технологиясенең нечкәлекләренә тиешенчә игътибар бирү өчен кирәкле бар нәрсә белән тулысынча җиһазландырылган. Бу нечкәлекләрне профессионаллар гына белә, әмма нәкъ әнә шундыйваклыклар, нечкәлекләр предприятиегә көндәшлек көчле булган базарда алдынгылыкны саклап калырга мөмкинлекләр бирерлек өстенлекләрне тәэмин итә. Мәсәлән, иң популяр икмәк төрләрен җитештергәндә технологлар ачыткыга аеруча игътибар бирә. «Чаллы икмәге» компаниясенең ипи пешерүчеләре куе ачыткыны ярдырып тарттырылган арыш онынан махсус профессионал җиһазларда ясый. Батон рецептурасының да үз серләре бар, һәм анда иң мөһиме – камыр ачыткысы. «Чаллы икмәге» ширкәтендә аны төп процесс башланырга 16–18 сәгать кала әзерлиләр. Бу вакытта камыр ачыткысы кабара башлый, анда әчкелтем тәм барлыкка килә, ул исә камыр сыйфатын яхшырта һәм махсус матдәләрсез генә батонның гомерен озайта.

ЛОГИСТИКА ЮНӘЛЕШЕНДӘ ОТЫШЛЫ АДЫМ

Әлеге интенсив үсеш һәм камилләшүнең нәтиҗәсе – компаниянең кибет киштәләрендә. «Чаллы икмәге» сәүдә йорты челтәренә «йорт янында» форматындагы 61 кибет һәм супермаркет, шулай ук «Мудрый Пекарь» исемле 20 пекарня керә. Компания татарстанлылар табынын сыйфатлы икмәк кенә түгел, ит ярымфабрикатлары белән дә тәэмин итү бурычын куя. Ит продуктларын җитештерү һәм эшкәртү белән «Чаллы икмәге» компанияләр төркеменә кергән «Чаллы-Фуд» ширкәте белгечләре шөгыльләнә. Биредә тәүлегенә 170 төрдәге 10 тонна продукция эшләп чыгарыла. Компания ирешелгәннәрдә генә тукталып калмый: «Чаллы икмәге» структурасында эшләп килгән «Чаллы-Логистик» бүлү-тарату үзәге ширкәт продукциясен мөмкин кадәр күбрәк сандагы сатып алучыга китерүдә яңа мөмкинлекләр ача. Әлеге үзәк 13 мең квадрат метр мәйдан били һәм көненә уртача 250 тонна продукция төяп җибәрә.

Һәрчак хәрәкәттә торган, алдынгы технологияле заманча компанияләр төркеме – «Чаллы икмәге» 2022 елда үзенең нигез салынуына 50 ел тулуны билгеләп үтәчәк. Ярты гасырлык юбилей – предприятиенең авыр һәм якты җиңүләр белән тулы озын юл үтүен күрсәтә торган сан. Әмма җиңүләрнең яңалары, иң колачлылары – алда әле!

Дөнья – үзен эшкәрткәннәрен көтеп торган уңдырышлы җир кебек. Орлыгын чәчеп, уңышын җыярга кирәк.

Эдвин Герберт Лэнд

УҢЫШ ӨЧЕН КӨРӘШТӘ ҖИҢҮГӘ ЮЛ

10–12 февраль көннәрендә, инде гадәткә кергәнчә, «Казан Экспо» Халыкара күргәзмә үзәгендә 3 нче махсуслашкан «ТатАгроЭкспо» күргәзмәсе узачак. Чара барышында кунакларга Чаллыдагы CNH Industrial заводында җитештерелә торган, һәр аграрийга билгеле New Holland һәм Case IH брендлы яңа авыл хуҗалыгы техникасы тәкъдим ителәчәк. «АльфаСервис» компаниясе Татарстанда Case IH, New Holland, Kongskilde, Överum брендлы югары сыйфатлы авыл хуҗалыгы техникасын һәм CNH Industrial оригиналь запас частьләрен сату һәм аларга хезмәт күрсәтү буенча бердәнбер рәсми дилер булып тора.

Республиканың авыл хуҗалыгы тармагындагы һәр товар җитештерүчегә басу-кырлардагы эшнең авыр хезмәт икәнлеге, аның ышанычлы техникадан башка мөмкин түгеллеге яхшы билгеле. Шул ук вакытта аның бәя ягыннан арзанлыгы, экономиялелеге, экологик яктан чисталыгы, ассортимент байлыгы һәм киләчәктә уңайлы рәвештә хезмәт күрсәтелүе мөһим фактор булып тора. Техника белән тәэмин итүгә бәйле мәсьәләләрне хәл итү өчен, авыл хуҗалыгы тармагы вәкилләре эре компанияләрнең отышлы тәкъдимнәрен даими күзәтеп бара, профильле күргәзмәләрдә катнаша. Февраль аенда узачак күргәзмә Татарстан башкаласында Россиянең 30 төбәге һәм 50 шәһәреннән һәм чит илләрдән 200 дән артык предприятиене берләштерәчәк. Агросәнәгать комплексының төп тармаклары экспозициясендә Чаллының CNH Industrial заводы да катнаша. Аның продукциясен рәсми дилеры – «АльфаСервис» тәкъдим итәчәк. Компания, җирле фермерлар һәм эре хуҗалыклар җитәкчеләренә кырчылык тармагындагы бурычларын тормышка ашырып, реаль нәтиҗәгә ирешү өчен таләп ителгән, сыйфатлы авыл хуҗалыгы техникасы алырга мөмкинлек бирә, бу җәһәттән иң кулай һәм сыналган вариант булып тора.

Чаллы шәһәрендә New Holland Agriculture[1] һәм Case IH брендлы авыл хуҗалыгы техникасын чыгарачак «СиЭнЭйч Индастриал Руссия» заводына 2010 елда нигез салына һәм, җитештерүне башлап җибәргәннән соң, комбайннардан тракторларга кадәр теләсә нинди төрдәге 3000 берәмлектән артык авыл хуҗалыгы техникасын эшләп чыгарып, компания үзен бу өлкәдә ышанычлы партнер итеп таныта. Завод продукциясенә ихтыяҗ зур икәнлеге анык, әмма җитештерелә торган машина компонентларының күпчелеге Россиядә эшләнү дә гаять мөһим. CNH Industrial заводында төп операцияләрнең шактые башкарыла: кабиналар ясау, җыю һәм эретеп ябыштыру, тракторларның интерьеры һәм экстерьеры белән бәйле эшләр.

«АльфаСервис» авыл хуҗалыгы өчен комплекслы хезмәт тәкъдим итә: чәчү, уңыш җыю, азык әзерләү техникасы, оригиналь запас частьләр һәм майлар, CNH Industrial Capital[2] лизинг партнеры белән берлектә кулай финанслау шартлары. Ширкәт шулай ук 24/7 режимында квалификацияле сервис күрсәтә.

«АльфаСервис» тәкъдим итә торган техниканың күплеге сайлап алу мөмкинлеге бирә: тракторлар,

Реклама. Фотолар «АльфаСервис» компаниясеннән алынды.

[1] Нью Холланд Агрикалча, [2] СиЭнЭйч Индастриал Кэпитал, [3] Кейс Патриот 4430, [4] Нью Холланд ЭрБи 180, [5] Конгскилде ВиЭм 14-2Эс

комбайннар, пресслап җыю, сиптерү, чәчү комплекслары, туфрак эшкәртү техникасы һәм заманча төгәл кырчылык системалары.

Компаниянең төп өстенлекләре нидә соң? Техника ширкәттә инде бар – үзйөрешле техника, асылмалы һәм тагылма агрегатлар сатып алганда, сезгә үз чиратыгыз җиткәнне көтәргә туры килмәячәк. Икенчедән, клиент Татарстан Республикасы чикләрендә югары квалификацияле персонал тарафыннан күрсәтелә торган күчмә профессионал сервис белән тәэмин ителгән. Һәм, әлбәттә, турыдан-туры җитештерүчедән китерелгән оригиналь запас частьләрнең һәрвакыт әзер торуы мөһим плюс булып тора. Барлыгы 2000 нән артык исемдәге продукция бар. Нәкъ менә шушы техниканы кулланып, Татарстан аграрийлары югары җитештерүчәнлек, нәтиҗәлелек һәм ышанычлылык күрсәткечләренә ирешә. Заводның инновацияле продукциясе көнүзәк таләпләргә җавап бирә, авыл хуҗалыгындагы алдынгы ысуллар һәм хезмәтләрне колачлый. Аграр хуҗалыклар чәчү яки урып-җыю кампаниясендә туфрак эшкәртүдән алып, терлек азыгы җыюга кадәр төрледән-төрле кыр эшләрен башкара торган барлык техника белән тәэмин ителә ала. Моннан тыш, төгәл кырчылык системалары басу эшләренең барышын теләсә кайдан торып контрольдә тотарга мөмкинлек бирә.

New Holland техникасы авыл хуҗалыгы эшендәге агрегатларның киң ассортиментын колачлый: тракторлар, үзйөрешле чапкычлар, прессы җыйгычлар, терлек азыгы һәм ашлык җыю комбайннары. Case IH брендлы түбәндәге техника төрләрен алып була: тракторлар, үзйөрешле сиптергечләр, ашлык җыю комбайннары, культиваторлар, тирәнтен йомшарткычлар, дисклы сабаннар, чәчү комплекслары. Kongskilde – паспорты Россиянеке булган техника: культиваторлар, таш җыю машиналары, асылмалы һәм тагылма чапкычлар, пакус каплагычлар, күбә салгычлар, тагылмалы терлек азыгы җыю комбайннары, тагылмалы азык тараткычлар. Overum – паспорты Россиянеке булган техника: капламалы асма, ярым асма һәм тагылма сабан, тигезләгечләр. «ТатАгроЭкспо» күргәзмәсендә «АльфаСервис» компаниясе төрле кулланыштагы авыл хуҗалыгы техникасының өрьяңа алты үрнәген тәкъдим итәчәк. Алар арасында урып-җыю өчен кирәклеләре дә, автомат системалар да бар – Case IH Patriot 4430[3] үзйөрешле сиптергече, New Holland RB 180[4] пресслап җыю җайланмасы, Kongskilde, VM 14-2S[5] азык болгату һәм тарату машинасы, Överum EVL 81080 F[6] капламалы сабаны, Case IH Magnum 340[7] тракторы, New Holland 17060[8] тракторы.

Тиздән республика авыл хуҗалыгы предприятиеләре җитәкчеләре, басу-кырларны эшкәртү өчен, Россиядә чын премьера булган алдынгы, куәтле, яхшы эргономикалы һәм уңайлы Case IH AFS Connect Steiger[9] тракторын сатып ала алачак. Ул яңа буын цифрлы технологияләрне кулланып, смартфон яки планшет кебек уңайлы итеп эшләнгән. Android[11] нигезендәге AFS Vision Pro[10] операция системасы, смартфон яки планшет кебек, теге яки бу эш өчен мониторны тиз һәм җайлы гына көйләп кую мөмкинлеге бирә. Сез дисплейда күренгән теләсә нинди объектларны күчерә, урыны һәм масштабын үзгәртә аласыз. Моннан тыш, мониторга 4 тышкы видеокамера да тоташтырып була. Bluetooth[12] ярдәмендә мобиль җайланмалар белән бәйләнеш урнаштыру, шулай ук дисплейга читтән торып тоташу мөмкинлеге каралган. Хәзер авыл хуҗалыгы предприятиеләре җитәкчеләре агрономиягә бәйле бөтен мәгълүматны, шулай ук тракторның торышы турында мәгълүматны реаль вакыт режимында күреп тора.

АЛЬФАСЕРВИС

«АльфаСервис» турында тулырак мәгълүматны 88005113647 телефоны аша алырга яки https://alfacnh.ru/ сайтында табарга була.

[6] Оверум ИВиЭл 81080 Эф, [7] Кейс Магнум 340, [8] Нью Холланд Ти7060, [9] Кейс АйЭйч ЭйЭфЭс Коннект Стейгер, [10] ЭйЭфЭс Вижн Про, [11] Андроид, [12] Блютуз

ФӘННУР ЗАРИПОВ: «МАКСАТЫМА ТАБА БАРУ МИҢА КӨЧ БИРӘ»

Татарстанда нәселле терлекчелек югары үсеш алган, сау-көр терлек үрчетү традицияләре исә дистәләрчә еллар белән исәпләнә. «Элита» нәселле терлек үрчетү предприятиесе — селекция эшенең чын осталарыннан гыйбарәт коллектив ул. Предприятие, иң заманча җиһазлар һәм технологияләр кулланып, нәсел үгезләренең орлык материалын җитештерү һәм сату белән шөгыльләнә. «Элита» нәселле терлек үрчетү предприятиесе АҖ директоры Фәннур Зарипов хәзерге эш барышы, генетикадагы тенденцияләр һәм мотивация шартлары турында сөйләде.

– Исәнмесез, Фәннур Рәфхәтович! «Элита» – нәселле үгез орлыкларын җитештерү һәм сату өлкәсендә Россиянең иң эре предприятиеләренең берсе. Тарихыгыз 1977 елда ук башланган, ә хәзер предприятиедә эшләр ни хәлдә?

– Безнең төп бурычыбыз үзгәрешсез – иң югары кыйммәткә ия үгезләрнең орлыгын кулланып ясалма орлыкландыру ысуллары кертү юлы белән мөгезле эре терлекнең продуктлылык сыйфатларын яхшырту. Ясалма орлыкландыру икътисадый яктан иң нәтиҗәле һәм куркынычсыз ысул санала. Без Татарстан терлекчеләренә ярдәм итү максатыннан техник базаны актив үстерәбез. Бүген предприятиедә АКШ, Германия, Голландия, Канададан китерелгән 60 баш нәселле үгез бар, хайваннарның бер өлеше карантинда һәм тулы тикшерү уза. 2020 ел ахырында Нидерландлар, Германия һәм Франциядән үгезләр кайтарылды. Бездә дистәдән артык токымның орлык материалы бар. Сөтчелек юнәлешендә яхшы лаборатория булдырдык, сөтнең сыйфат күрсәткечләрен 11 категория буенча тикшерәбез. Быелтыр иң алдынгы дөнья стандартлары нигезендә корылган терлек азыгы лабораториясен эшләтеп җибәрдек. Үзебездә менә шундый шартлар тудырып, эш өчен кирәкле барлык коралларга ия булып, без аграрийларга нәтиҗәлелекне арттыру юлында тиз һәм отышлы карарлар кабул итәргә булышабыз. Безнең штатта 90 хезмәткәр эшли, аларның күбесе клиентларыбыз янына барып йөреп хезмәт куя – ясалма орлыкландыруда, товарлар сатуда ярдәм итә. Күчмә бригадалар, ясалма орлыкландыру өчен күчмә пунктлар быелтыр яңа мөмкинлекләр белән эшкә керешә. Агропредприятие штатында кирәкле белгечләр юк икән, без ярдәмгә үз хезмәткәрләребезне тәкъдим итәбез, әлеге хуҗалык хезмәткәрләрендә укытабыз, шул рәвешле бизнеска үсәргә һәм табыш китерергә булышабыз. «Элита»ның клиентлары, кагыйдә буларак, Татарстанның эре терлекчелек предприятиеләре җитәкчеләре. Һәр фермерга, кече агрофирма хуҗасына орлыкландыручы белгеч тоту кыен, икътисадый яктан кыйммәт һәм отышлы түгел, шуңа күрә без аларга бу эштә булышлык күрсәтәбез.

– Үз тәҗрибәгездә замана генетикларының нинди фәнни ачышларын кулланасыз?

– Эшебез фән белән тыгыз бәйләнештә. Генетиканы нәтиҗәгә ирешү өчен күп билгесезлек билгеләрен табарга кирәк булган математик тигезләмәләр белән чагыштырырга мөмкин. Без Татарстан, Россия һәм дөнья галимнәре тәҗрибәләрен һәрвакыт актив кулланабыз. Соңгы елларда «Сколково» Инновацияләр институты белән берлектә хайваннарны генотиплаштыру буенча пилот проектны гамәлгә ашырабыз, анда шулай ук Н.Э.Бауман исемендәге Казан дәүләт ветеринария медицинасы академиясе һәм Бөтенроссия терлекчелек институты кебек югары уку йортлары да, хәтта Ирландиядән чит ил партнерларыбыз да катнаша. Бу – катлаулы, авыр һәм кыйммәтле проект, әмма без инде бүген үк аның беренче нәтиҗәләрен күрәбез. Хәзер без төрле агрохуҗалык җитәкчеләренә, кулларында әлеге мәгълүматлар булган хәлдә, терлек көтүе белән уңышлы идарә итә алсын өчен, аңлату эшләре алып барабыз.

– Предприятиедә эпизоотик иминлек мәсьәләсе ничек хәл ителә?

– Чыннан да, бу – бик мөһим мәсьәлә, әмма әлегә бездә мондый очраклар булмады, киләчәктә дә булмас, дип ышанам. Моның өчен бар көче-

Реклама.Фото «Элита» нәселле терлек үрчетү предприятиесеннән алынды.

безне салабыз. Терлекләрне ике елга бер мәртәбә алып кайтабыз, бу вакытта барлык куркынычсызлык чаралары, ветеринария законнары һәм Россельхознадзор таләпләренең катгый үтәлүен тәэмин итәбез. Башта хайваннар ике этаплы карантин уза, шул рәвешле куркыныч тудырырлык факторлардан котылабыз. Сколково белән уртак фәнни эшчәнлек нәселле терлекләрне чит илдән кертүгә бәйлелекне киметүгә юнәлдерелгән, шул очракта без читтән терлекләр сатып алмыйча, малларны сыйфатлы итеп үрчетүгә ирешәчәкбез.

– Бу пандемияле катлаулы ел сезгә дә үзен сиздердеме?

– Эпидемиологик вазгыятьне күздә тотып, эш графигына үзгәрешләр кертсәк тә, пандемияне әллә ни тоймадык диярлек. Бу чир коллективка эләкмәсен өчен, кулдан килгәннең барын да эшләдек. Эш шунда ки, республикада һәр хуҗаның диярлек фермасында терлекләре бар, ә хайванны бит карарга, ашатырга-эчертергә, орлыкландырырга кирәк. Һәм бу – өзлексез эш циклы, аны хәтта коронавирус янаган вакытта да туктатырга ярамый.

– Хәзер Россиядә нәселле терлекчелекнең киләчәккә өмет-ниятләре нинди?

– Фән бер урында гына тормый, хәзерге заманда генетика иң ышанычлы мәгълүматлар нигезендә тирәнтен өйрәнелә. Илдә нәселле терлекчелекнең бөтен системасы якындагы елларда гамәлгә ашырылырга тиешле үзгәрешләр һәм яңа эш тәҗрибәләрен кертү стадиясендә тора. Алдынгы генетик тикшеренүләр терлекләр өчен сыйфат һәм сан күрсәткечләр ягыннан продуктлылыкны арттыруда ныклы нигез булачак. Хәзер ясалма орлыкландыру эше буенча норматив документлар әзерләнә, алар инде күптән кирәк иде. Авыл хуҗалыгы предприятиеләрендә генетик эш – контроль булырга тиешле тармак. Югыйсә бөтен терлек көтүен бозарга мөмкин. Үзләренә артык ышанган, бары кәгазьдә генә белгеч булган генетиклар, сезнең хуҗалыкка килеп, күп еллар хезмәт куеп ирешелгән уңышларны тулысынча җимерергә, юкка чыгарырга мөмкин. Малларның генетикасы бик тиз бозыла, ә менә яңадан торгызу – бик озак һәм катлаулы эш.

– Сез «Элита» нәселле терлек үрчетү предприятиесен күп еллар уңышлы җитәклисез. Сезнеңчә, җитәкче өчен уңышның сере нидә?

– Хәзерге мәгълүмати байлык заманында дөньяда рекламаның ысул-алымнары бик төрле һәм кайчак дөресен сайлап алу, нәрсәнең начар, нәрсәнең яхшы икәнен чамалау да кыен. Һәркем үз товарын кычкырып-кычкырып мактый, аны матур, күз явын алырлык төргәктә тәкъдим итә. Продукция составына яки аппаратның эш принцибына бераз гына үзгәреш кертеп, күп кенә намуссыз эшмәкәрләр шунда ук «инновацияле, яңа продукт» турында сөрән сала. Алар үз хезмәтләренең бәясен арттыра һәм авыл хуҗалыгындагы беркатлы җитештерүчеләр хисабына акча эшли. Әмма безнең тармакта гайре табигый берни дә уйлап табылмаган, барлык төп параметрлар күптән билгеле һәм хәзер дә гамәлдә. Шуңа күрә барлык факторларны искә алып, төпле нигезле карарлар кабул итәргә кирәк. Шул ук вакытта терлекчелек бизнесының торышын контрольдә тоту гына түгел, заман белән бергә атлау, ИТ-нигезле заманча ысул-алымнар куллану да таләп ителә.

– Эшегездә яңа казанышларга сезне нәрсә этәрә?

– Минем өчен иң зур кызыксындыру чарасы – яңа проект, яңа мәсьәлә, яңа бурыч. Мәсәлән, Татарстан өчен уникаль лаборатория булдыру. Без аңа бәйле мәгълүматны бик җентекләп эзләдек. РФ Мәгариф һәм фән министрлыгы исеменнән федераль фәнни-техник проектта катнашабыз, анда без ветеринария академиясе белән берлектә фәнни тикшеренүләрнең нәтиҗәләрен һәм комплекслы планнарын тәкъдим итәчәкбез. Куелган максатка таба әнә шул рәвешле хәрәкәт итү мине рухландырып тора.

АЙРАТ ВӘЛИЕВ:
«ИҢ ЯХШЫНЫ САКЛАП, ЯҢАЛАРЫН БУЛДЫРЫП...»

Казан дәүләт аграр университеты (КДАУ) – Россиядәге аграр югары уку йортларының иң борынгыларыннан берсе. «Татарстан» журналына интервьюсында университет ректоры Айрат Рәсим улы Вәлиев уңыш нигезләре, кадрлар белән тәэмин итүгә бәйле проблемалар һәм авыл хуҗалыгы тармагының киләчәге турында сөйли.

– Айрат Рәсимович, 2020 елда университет барлык юнәлешләр һәм әзерлек баскычлары буенча дәүләт аккредитациясе процедурасын уңышлы узды, бу исә гамәлгә ашырыла торган уку-укыту программаларының югары сыйфатын раслый. Мондый уңышның төп шартлары нидә?

– Исәнмесез! Безнең уңыш – иң элек югары профессиональлек һәм укытучылар белән университет хезмәткәрләренең интеллектуаль потенциалы ул. Педагогларның 90% тан артыгы гыйльми дәрәҗәгә ия. Тагын бер фактор – агросәнәгать тармагы өчен югары квалификацияле кадрлар әзерләүнең уңышлы тәҗрибәсе һәм йөзьеллык тарихыбыз. Вузда 5000 гә якын студент белем ала. Уку-укыту процессы заманча матди-техник базада тормышка ашырыла. Соңгы елларда гына да агрономия факультеты базасында яңа фәнни-тикшеренү лабораторияләре комплексы булдырылды, Механикалаштыру һәм техник сервис институты базасында агросәнәгатьне роботлаштыру һәм цифрлаштыру лабораторияләре комплексы ачылды, урман хуҗалыгы һәм экология факультетының бинасы ремонтланды һәм заманча җиһазлар белән тәэмин ителде, индустриаль партнерлар һәм агробизнес белән берлектә 20 дән артык дәрес бүлмәсе җиһазланды. Университетның ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, шулай ук аграр икътисадның реаль секторындагы ширкәтләр белән тыгыз хезмәттәшлеге уңышның өченче факторы булып тора. Әлеге хезмәттәшлек яшьләргә һөнәри юнәлеш бирү, максатчан әзерлек, җитештерү практикасын оештыру, шулай ук төрле стипендия программалары аша матди ярдәм күрсәтүне күздә тота. Ел саен 40 лап студентыбыз ТР авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрының исемле стипендиясен ала, 50 дән артык студент төрле агросәнәгать предприятиеләре һәм Россельхозбанк, Август, Баер һ.б. кебек оешмаларның стипендиаты булып тора.

– Казан дәүләт аграр университетының җитештерү тармагы белән фәнни-техник хезмәттәшлеге турында сөйләсәгез иде.

– Соңгы елларда КДАУ Россия Авыл хуҗалыгы министрлыгының 54 югары уку йорты арасында фәнни-тикшеренү эшчәнлеген финанслау буенча 1 урынга чыкты. Без Татарстан һәм Россиянең алдынгы фәнни-тикшеренү институтлары, югары уку йортлары белән актив хезмәттәшлек итәбез, фәнни-техник үсеш программаларын гамәлгә ашыруда актив катнашабыз, агросәнәгать комплексының реаль секторы заказы белән эшлибез. Мәсәлән, федераль максатчан программаны тормышка ашыру кысаларында, галимнәребез «Bionovatic» компанияләр төркеме белән хезмәттәшлек итеп, үсемлекләрне саклау өчен яңа биологик препаратлар, аларның сыйфатын экспресс бәяләү өчен тест-система эшләп чыгарды. Уйлап табуларга 10 патент алынды, лицензия килешүе нигезендә алар, күпләп җитештерү өчен, индустриаль партнерга тапшырылды. Моннан тыш, Татарстан Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы белән берлектә, без университетның Агробиотехнопарк проектын гамәлгә ашырабыз, 2020 елда андагы 1600 кишәрлектә 50 дән артык тәҗрибә-сынау эше башлап җибәрелде, 40 тан артык препарат һәм 30 га якын яңа сорт һәм гибрид сыналды, шулай ук 255 тонна элиталы бодай орлыгы һәм 55 тонна вируссыз орлык бәрәңгесе җитештерелде.

– Авылда кадрлар кытлыгы проблемасы ничек хәл ителә?

– Татарстанның авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Җаббаров билгеләп үткәнчә, белгечләрне әзерләү мәктәп эскәмиясеннән үк башланырга тиеш. Шуңа күрә һәр районның төп авыл хуҗалыгы предприятиеләре белән берлектә без авыл мәктәпләрендә профильле агрокласслар концепциясен гамәлгә ашыру юнәлешендә актив эш алып барабыз. 2019 елда Балтач районында гына да дистәдән артык шундый сыйныф ачылды. Төп максат – мәктәп укучыларына алдан ук һөнәри юнәлеш бирү аша яшь кадрлар тәрбияләү, университетта сыйфатлы әзерлек булдыру һәм киләчәктә лаеклы хезмәт хакы алырлык эшкә урнаштыру.

– Агросәнәгать комплексының киләчәген нинди итеп күзаллыйсыз?

– Дөньяның алга киткән илләре ике меңенче еллар башыннан актив рәвештә биоикътисадка күчеп бара, ул исә авыл хуҗалыгына алдынгы технологияләр кертүне күздә тота. Киләчәктә агроботлар һәм автопилотлы авыл хуҗалыгы техникасы, ясалма интеллект һәм цифрлы технологияләр, ясалма агробиоценозлар булдыру, ген инженериясе һәм авыл хуҗалыгында геном технологияләр кебек технологик инновацияләр алдынгылык яулар дип саныйм. Моннан чыгып, без былтыр ук «Авыл хуҗалыгы биотехнологиясе», «Технологик процессларны автоматлаштыру һәм роботлаштыру», «Мәгълүмати системалар һәм технологияләр» кебек яңа программаларга студентлар җыйдык.

Татарстан һәм Россия агросәнәгать комплексындагы иң яхшыны саклап, яңаларны булдырып һәм комплекс үсешендә актив катнашып, бүген без киләчәккә ышаныч белән атлыйбыз.

Фото Казан дәүләт аграр университетыннан алынды.

КОСМОСТАН ДА МӨҺИМРӘК

Тотрыклы азык-төлек базасын булдыру – галәм киңлекләрен яулау кебек үк кешелек өчен мөһим бурыч. БМО фаразларынча, XXI гасыр уртасында планетабызда халык саны 9,7 миллиард кешегә кадәр артачак, ә азык-төлеккә ихтыяҗ дәрәҗәсе тарихи максимумга җитәчәк. Мондый юнәлешләр көчәя барган чорда аграр белгечлекләр, беренче чиратта, ветеринария табибы һөнәренең мөһимлеге көннән-көн арта.

Н.Э. Бауман исемендәге Казан дәүләт ветеринария медицинасы академиясе инде бүген үк киләчәк таләпләренә җөз тота. Биредә үз һөнәрләрен яхшы белгән, чиктәш өлкәләрдә дә эш алып барырлык, даими һөнәри үсешкә омтылучы квалификацияле белгечләр әзерләнә. Бу профессионаллар, Татарстан һәм илнең башка төбәкләренең азык-төлек иминлегенә зур өлеш кертеп, авыл хуҗалыгының алдынгы тармакларында хезмәт куя.

Академиянең ветеринария медицинасы факультетында «Ветеринария» белгечлеге һәм «Ветеринар-санитар экспертиза» юнәлеше буенча 1 меңнән артык студент укый, 300 студент биотехнология һәм стандартлаштыру факультетында «Зоотехния» һәм «Авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү һәм эшкәртү технологиясе» юнәлешләре буенча белем ала. Моннан тыш, Россия Федерациясенең төрле субъектларыннан 500 дән артык студент өстәмә һөнәри һәм читтән торып белем алу факультетында укый. Әзерлек программасына, шул исәптән терлекчелектәге һәм ветеринариядәге инновацияле технологияләр, «Меркурий» системасында электрон документ әйләнешенә өйрәтү дә керә. Былтыр фермерлар өчен беренче ветеринария ярдәме күрсәтү күнекмәләренә өйрәтү курслары ачылды.

Академия чит илләрнең югары уку йортлары һәм оешмалары белән актив хезмәттәшлеккә омтыла. Академиягә әзерлек үзәгендә Төркия, Мисыр, Сүрия, Таҗикстан, Төркмәнстан һәм башка илләрдән 100 гә якын студент белем ала. Үз чиратында, безнең иң алдынгы студентлар чит ил предприятиеләрендә һәм клиникаларында практика һәм стажировка уза. Бу юнәлештә академия Төркия һәм Германия оешмалары белән хезмәттәшлек итә. Вузда чит ил югары уку йортлары белгечләре һәм мөгаллимнәренең лекцияләре һәм осталык дәресләре даими уздырыла. Хәзер Академия Европа ветеринария белеме учреждениеләре ассоциациясенең (EAEVE) аккредитациясен алырга әзерләнә, бу исә халыкара эшчәнлекне яңа югарылыкка күтәрергә мөмкинлек бирәчәк.

Ветеринария уку йортында фәнни эш даими үсештә, 5 фәннитикшеренү лабораториясе эшли. Академия агросәнәгать комплексы калдыкларын утильләштерү технологияләрен әзерләү, дару препаратлары һәм азык өстәлмәләрен эшләү һәм гамәлгә кертү буенча кластер булдыру кебек инновацияле проектлардан читтә калмаска тырыша.

Шул ук вакытта академия студентларның иҗади, спорт, социаль активлыгын хуплый. Биредә студентлар советы, иҗат коллективлары, волонтерлык отрядлары, матбугат үзәге, туристлык клубы, студентлар иминлек хезмәте, коррупциягә каршы студентлар комиссиясе, спорт клубы, студентлар өчен фәнни түгәрәкләр, тулай торак советлары һ. б. эшләп килә. Академия студентлары «Татарстан Республикасының ел студенты-2019», студент хезмәт отрядлары конкурсларында, төрле дәрәҗәдәге спорт ярышларында лауреат исемен алды һәм призлы урыннар яулады.

2023 елда Академия үзенең 150 еллыгын билгеләп үтәчәк. Россиянең иң өлкән ветеринария мәктәбе буларак, ул бай фәнни-гамәли мирасны саклап калу, шул тәҗрибәне заманча белем бирү методикаларын һәм стандартларын кертүдә нәтиҗәле файдалануны максат итеп куя.

ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕННӘН:

1873 елда император Александр II Казанда ветеринария институтын булдыру турында указга кул куя: әлеге уку йорты Россия империясендә дүртенче һәм дөньяда утыз алтынчы ветеринария институты була. Аның фәнни мәктәпләре ватаныбызда һәм чит илләрдә киң танылa. 1959 елда Казан ветеринария институты Советлар Союзы күләмендәге эре уку-укыту һәм фәнни-тикшеренү үзәге итеп үзгәртелә. 1973 елда институтка Ленин ордены бирелә. 1995 елда югары уку йорты Н.Э.Бауман исемендәге Казан дәүләт ветеринария медицинасы академиясенә әйләнә. Академияне тәмамлаучылар арасында күренекле галимнәр, дәүләт премияләре лауреатлары, министрлар, депутатлар, муниципаль берәмлекләр башлыклары, төрле дәрәҗәдәге җитәкчеләр бар. Бүген академиядә Россиянең төрле төбәкләреннән, БДБ һәм ерак чит илләрдән 2000 нән артык студент белем ала.

Фото Н.Э.Бауман исемендәге Казан дәүләт ветеринария медицинасы академиясеннән алынды.





ИНВЕСТОР ФӘЛСӘФӘСЕ

1200 башка исәпләнгән роботлаштырылган сөт комплексы Саба районында ике ел эчендә япан кырда барлыкка килде. Быел инде ул тулы куәтенә эшли башлаячак һәм ике тапкырга зуррак булачак. Инвестор – «ПМК» ҖЧҖ чыгымнарның тиз генә капланмаячагын аңлап тотына әлеге проектка. Әмма максатны төгәл куя: финанс нәтиҗәләре максималь дәрәҗәдә булырга тиеш.

«САННАРДАГЫ» СЫЕРЛАР

Комплексның бер бинасында салкын җил йөреп тора. Адәм балалары өчен бик ярап бетмәс иде ул, ә менә сыерлар өчен салкынча саф һава әйбәт кенә. «Сыер караучы»лар да андый гына салкыннан курыкмый: ферманың киң юлларыннан хуҗаларча үтеп йөри торган робот җилгә битараф мөнәсәбәттә. Ул бик эшлекле кыяфәт белән азыкны тагаракларга китереп куя да, эшләрен төгәлләп, зарядка алырга китә. Сыерлар роботлардан тамчы да курыкмый, курыкмаулары да яхшы: шөбһәләнмәгән саен сөт тә күбрәк була.

Россиядә сөт терлекчелегендәге объектларны цифрлаштыру әлегә баш саны 800дән артыграк булган сөт комплексларына гына кагыла. Алар фермаларның гомуми саныннан 4,3 процентны гына тәшкил итә, әмма шул ук вакытта илдә җитештерелә торган сөт күләменең 30 проценты аларга туры килә.

– Хайван бернинди стресс та кичерергә тиеш түгел, – дип ачыклык кертә «ПМК» ҖЧҖ идарәчесе Марат Нигъмәтҗанов. – Күрәсезме, кайсылары ята, кайсылары күши, әмма барысы да тыныч. Саудырырга теләсәләр, робот янына киләләр, аларны берәү дә кумый. Менә алар, сөтләрен саудырырга теләп, чиратка

тезелгәннәр. Алар роботның үзләрен савасын да, ашатасын да белә. Аннан соң инде сыерлар үзләренең «эшләре» белән китәләр.

Идарәче сүзләренә караганда, роботлар савып алынган сөтнең күләмен 10 нан 25 процентка кадәр арттыруны тәэмин итә. Сәбәбе? Сыерлар планлаштырылган вакытта түгел, ә үзләре теләгән вакытта саудыра. Башка яктан да файдасы бар. Сыерны роботлар саву хайванның сөт бирү чорын да озайта – сыерның үзе теләп саудыруы, сыйфатлы итеп ашавы һәм аның сәламәтлеген күзәтеп тору, хәрәкәтләнү, «аппетит»ының булу-булмавын, сөтенең сыйфатын һәм майлылыгын, авырлыгының динамикасын контрольдә тоту хисабына. Әгәр дә берәр сыер авырып китә икән, аны дәвалау мөмкинлекләре дә зуррак, чөнки хуҗалыкта һәр хайван турында мәгълүмат базада даими рәвештә яңартылып тора. Уртача күрсәткечләрдән аз гына тайпылыш була икән, ул шунда ук сизелә. Роботлар кулланылмый торган сөт хуҗалыкларында еллык брак 30 процент булса, ул гадәти санала, биредә исә бу саннар, ким дигәндә, ике тапкырга азрак. Комплексның барлык системалары бердәм компьютер челтәренә тоташкан, ул шунда ук бөтен мәгълүматны комплекс идарәсендәге компьютер экранына һәм җитештерүдә катнашучы хезмәткәрләрнең кесә телефоннарына чыгара. Уңайлы да, нәтиҗәсе дә бар. Һәм тагын. Бүген сабалылар бер сыердан уртача 38,6 литр сөт савып ала. Бу – республикадагы иң яхшы күрсәткеч.

Реклама. Фото: Александр Ефремов



ИНВЕСТИЦИЯЛӘРГӘ ЯРДӘМ

«ПМК» ҖЧҖ сөт комплексын 30 гектар мәйданда төзи. Проект дүрт чиратка бүленгән, һәркайсы 600 сыерга исәпләнгән. Сөт комплексы төзелеше 2021 елга тәмамланырга тиеш, дип планлаштырыла. Биредә көн саен 33–35 тонна сөт савып алалар.

– Әйе, бүген аграр өлкәдә «цифрлар» дигән төшенчәне киң кулланыла дип әйтергә иртәрәк әле, әмма заманча технологияләр нормага әйләнеп килә, – дип ышандыра комплексның җитәкчесе Константин Маковеев. – Чынлыкта теләсә кайсы инвестор өчен инвестицион климатның җәлеп итүчәнлеге – уңышны билгели торган төп шарт булып тора. Нәкъ менә ул проектларны кыска вакыт эчендә чыгымнарын каплатып, табыш алу мөмкинлеге бирә. Район башлыгы, Татарстанның Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан ярдәм күрсәтелүе биредә Европача тәҗрибә белән эшли торган комплекс барлыкка килүгә зур этәргеч бирде. Ышаныгыз, хакимият белән бизнесның тырышлыклары бергә кушылмаса, ике ел эчендә ялан кырда мондый дәрәҗәдәге объект барлыкка килә алмас иде.

Минем фәлсәфәме? Гавамга иярмәскә, югыйсә урта кул гына булып калачаксың. Мин агымга каршы барырга яратам. Республикада безнең тарафтан гамәлгә ашырылган проектларның финанс ягыннан югары нәтиҗәләргә ирешүенең төп шартлары – дөрес уйда булу, күп эшләү һәм яхшы команда туплау. Ә минем команда – искиткеч!

P.S. «ПМК» ҖЧҖнең әлеге проекттан соң тормышка ашырылачак планында – тагын бер сөт комплексы төзү. Бу юлы 6 мең башка!

Узган елның декабрендә «Ел җитәкчесе» конкурсында җиңүчеләрне котлап, ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов болай билгеләгән иде: пандемия белән бәйле туган кыенлыкларга карамастан, Татарстан күп кенә социаль-икътисадый күрсәткечләр буенча алдынгы позицияләрендә кала.

Республикада масштаблы программалар һәм проектлар тормышка ашырыла. 2020 елда үзләренең коллективлары белән югары күрсәткечләргә ирешкән лауреатлар арасында авыл хуҗалыгы предприятиеләре һәм җитәкчеләре дә бар иде. Шуларның берсе – «Предприятиене цифрлы трансформацияләгән өчен» номинациясендә Саба районының «ПМК» ҖЧҖ директоры Константин Маковеев.

«Майский» компаниясе җитәкчелеге белемле белгечләрне җәлеп итү һәм аларга кирәкле шартларны тудыру мәсьәләсенә җитди игътибар бирә. Без республикада барлык параметрлары белән дөньяның иң яхшы үрнәкләренә тиңләшерлек теплица комбинаты булу белән горурланабыз».

Рөстәм Миңнеханов,
Татарстан Республикасы Президенты

МАЙСКИЙ» КОМБИНАТЫ: КИЛӘЧӘККӘ ЙӨЗ ТОТЫП

Татарстан – агросәнәгать комплексында күптәннән һәм ныклы адымнар белән алдынгы урыннарда бара торган төбәк. Бу җәһәттән яшелчә, яшел тәмләткечләр һәм җиләк җитештерүчеләр арасында җирле хуҗабикәләрдә абруй казанган һәм яхшы билгеле брендларның берсе – «Майский» теплица комбинаты продукциясе.

1974 елда нигез салынган «Майский» теплица комбинаты яшелчә, яшел тәмләткечләр һәм җиләк җитештерүгә йөз тоткан предприятие булып тора. Комбинат Татарстанның һәм эре федераль үзәкләрнең яңа җыелган, нитрат һәм пестицидларсыз үстерелгән, экологик чиста яшелчә, яшел тәмләткечләр һәм бакча җиләгенә ихтыяҗларын канәгатьләндерә. Мондый югары нәтиҗәләргә исә комбинатта меңгә якын кешенең көндәлек тырыш хезмәте нәтиҗәсендә ирешелә, шунысы да мөһим: аларга лаеклы хезмәт хакы түләнә. Химикатлар кулланмау – предприятиенең генераль директоры, аны күп еллар җитәкләгән Илшат Ганиевнең принципиаль позициясе, ул экология һәм технология таләпләренең үтәлүен һәрвакыт беренче планга куя. Мондый карашны тормышка ашыру бәрабәренә «Майский» халыкара сыйфат системасын гамәлгә кертеп, үсемлекләрне биологик саклау системасын актив үстерә, комбинат ябык грунтта яшелчә, яшел культуралар һәм җиләк уңышы буенча Россиядә лидер булып тора. Катлаулы ел булуга карамастан, алыштыргысыз җитәкчесе кул астында комбинат үз алдына куйган бурычларны уңышлы хәл итте, алай гына да түгел, яшелчә, яшел тәмләткечләр һәм җиләк җитештерүчеләр арасында алдынгыларның берсе булып калган хәлдә, хезмәтләрне цифрлаштыру процессын башлап җибәрде.

Предприятиедә технологик процесслар белән идарә итү системасын автоматлаштыру (ТП ИСА) буенча колачлы эш тулысынча тәгәлләнде.

Барлык теплицаларга да төп җитештерү параметрларын (30 берәмлектән артык) – һаваның җылылыгы һәм дымлылыгыннан алып, тупланган кояш радиациясе күләменә кадәр булган күрсәткечләрне контрольдә тоту һәм саклау өчен автоматлаштырылган система көйләнде.

Предприятиедә «акыллы челтәрләр» системасы гамәлгә кертелде, ул электр энергетикасы объектлары белән идарә итеп, генераторларны һәм трансформаторларга автомат рәвештә йөкләнеш бирү һәм бушату мөмкинлеге бирә.

Кече энергетика объектларында югары дәрәҗәдәге ТП ИСА гамәлгә ашырылды, автоматлаштырылган система түбәндәгеләрдән гыйбарәт: газлы-пешкәкле 20 станция белән идарә итү, теплицаларны өстәмә яктырту һәм бүленеп чыккан газларны чистарту һәм аннан соң теплицага углекислый газ бирү системасы белән идарә итү.

Автоматлаштыру һәм цифрлаштыру процессларын җайлаштыру максатында предприятиедә җитәкчелек карарларының тизлеген һәм нәтиҗәлелеген арттырырга мөмкинлек бирә торган электрон документ әйләнеше гамәлгә кертелде.

Югарыда күрсәтелгән чараларны тормышка ашыру җитештерү нәтиҗәлелеге буенча Европадагы алдынгы күрсәткечләргә (кыярларның иң зур уңыш – 220 кг/кв. м, томатларда – 110 кг/кв. м) һәм продукциянең энергия сыйдырышлылыгы (чыгымы) буенча рекордлы түбән күрсәткечкә (1 кг яшелчәгә 1,5 кг шартлы ягулык) ирешергә мөмкинлек бирде.

Компаниянең атаклы теплицалары Татарстан бюджетына керем китерә, төбәкнең азык-төлек иминлеген тәэмин итә һәм җирле халык өчен эш урыннары булдыра. Республика агросәнәгать комплексындагы лидерларның берсе буларак, Татарстан предприятиесе авыл хуҗалыгы ярминкәләрендә һәм профильле күргәзмәләрдә даими катнашып килә. Шул рәвешле, бүген әлеге предприятие чын профессионаллар коллективы булып тора, алар республика һәм ил файдасына экологик чиста продуктлар җитештереп кенә калмыйча, заман белән бергә үсә, алга бара.

Фото «Майский» теплица комбинаты» ЖЧЖ тарафыннан биреле

Реклама

www.protatarstan.ru
Поиск...
РУС | ТАТ
ТАТАРСТАН
Иҗтимагый-сәяси басма
Подписка!
Где купить журнал "ТАТАРСТАН"
Монда «Татарстан» булды
Әһәмиятле
Игелекле
Мәңгелек
Сайттагы яңалык
Яңалыклар
04 февраля 2021
Казанда бушлай татар теле курслары башлана
03 февраля 2021
Кан җыю буенча хәйрия акциясе Казанда узачак
Әсгать Сафаров Тик-токка милли контент белән чыгарга киңәш итте
Айдар Сәлимгәрәев: Милли матбугат үсеше — мөһим бурыч
02 февраля 2021
Татарстанда халыкка социаль ярдәм чаралары күрсәтү өчен «Кайгырту»
игелекле
Индус Таһировның тормыш линиясе
Кем күпме генә әйтсә дә, татар теленең киләчәге бик зур. Аңа карата кызу күбрәк булган саен, халык ныграк уяна. Һәм бүген моның ачык мисалын күрәбез. Татарстанда гына
02.02.2021
мәңгелек
Чыпчык: дуслык яшәгән җирдә
Күпмилләтле Чыпчык
29.01.2021
мәңгелек
Иман академиясе
...Очлаеп килгән тар тәрәзәле бина нинди борынгы шәһәр кирмәнен хәтерләтә. Әлеге диварлар бик сайлап алынган, сирәк затларга гына ачык белем-гыйлемнәрне саклый. Без әлеге кирмән эченә — Болгар
21.12.2020
игелекле
әһәмиятле
мәңгелек

Реклама 16+

АЛАБУГАНЫҢ УҢЫШ СЕРЛӘРЕ

Татарстан илебезнең алдынгы сәнәгать төбәкләренең берсе санала. Биредә яңа җитештерү объектлары уңышлы эшләп китә, яңа заводлар ачыла. Махсус икътисадый зона территориясендә урнашкан «Август-Алабуга» – шундыйларның берсе. Ул үсемлекләрне саклау буенча химик продукт җитештерә торган «Август» компаниясенең яшь, ультразаманча предприятиесе. Директор Владимир Алин җитәкчелегендәге завод 2020 елның декабрендә «Ел җитәкчесе – 2020» конкурсында «Инвестицион активлык өчен» номинациясендә лауреат дип табылды.

Исегезгә төшерәбез: завод тантаналы рәвештә 2019 елның 28 июнендә ачылды, анда Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов та катнашты. Гомуми инвестицияләр күләме 4,5 млрд сумлык булган әлеге уникаль проект бер түбә астында бердәм офис һәм җитештерү комплексыннан гыйбарәт, хезмәткәрләр берсеннән икенчесенә урамга чыкмыйча гына йөреп-чыгып йөри ала. Заводның проекттагы куәте – елына 50 млн литр продукция һәм 8 млн канистр эшләп чыгару, бу саннар Россиянең үсемлекләрне саклау буенча химик продуктлар базарының өчтән бер өлеше дигән сүз.

– Үсемлекләрне саклау чаралары – агросәнәгать комплексының уңышка ирешүендә иң җитди элементларның берсе. Сер түгел, корткычлардан саклау чараларының төп өлешен без һәрвакытта да сатып ала идек, ә бүген «Август» компаниясе Россиядәге кулланучыларны гына тәэмин итеп калмаячак, ул үзенең продуктын 20 илгә тәкъдим итә. Минемчә, илләр саны алга таба артачак кына. Яңа предприятиедә 4.0 технологияләре кулланыла – бу югары сыйфат һәм югары җитештерүчәнлек, югары нәтиҗәлелек, – дип ассызыклады Рөстәм Миңнеханов.

10 июльдә РФ Премьер-министры Михаил Мишустин җитәкчелегендә РФ Хөкүмәтенең Татарстанга сәфәре кысаларында заводта сәламәтлек саклау министры Михаил Мурашко, РФ ФСХ башлыгы Даниил Егоров, шулай ук Татарстан Республикасының сәламәтлек саклау министры Марат Садыйков кебек дәрәҗәле кунаклар булды. Вазыйфаи затларның җентекле игътибары очраклы түгел: биредә мондый җитештерүнең барлыкка килүе төбәктә авыл хуҗалыгы үсеше өчен стратегик яктан мөһим адым булды. Завод беренчә төрдә агрохимикатлар – гербицидлар, фунгицидлар, инсектицидлар, орлыкларны зарарсызландыру продуктлары эшләп чыгара, алар авыл хуҗалыгы җитештерүенең уңдырышлылыгын арттырырга ярдәм итә. Җитештерү барышы югары дәрәҗәдә автоматлаштырылган, Россиядә һәм чит илләрдә җитештерелгән җиһазлардан торган завод 2019 елның июнендә ачылганнан алып, бүгенге көнгә кадәр барлыгы 14 млн литр күләмендә продукция эшләп чыгарган.

Заводның уңышлары турында саннар күбрәк сөйли. 2020 елда завод 10,6 млн литр әзер продукция биргән – план 108 процентка үтәлгән. 2020 ел башыннан барлыгы 1 млн 686 мең биш һәм унар литрлы канистр, шулай ук 2 млн 198 мең капкач эшләнгән. 2020 елның декабрь ахырына предприятиедән 7 млн 800 мең литр препарат Ставропольдән алып Барнаулга кадәр озатылган. Шушы исәптән үсемлекләрне саклау буенча продуктларның шактый күләмдәге өлеше – 1 млн 900 мең литр Казахстан аграрийларына туры килә. Сүз уңаеннан, 2021 елда сату географиясе шактый киңәйгән – планда әзер продуктны Латин Америкасының кайбер илләренә, аерым алганда, Колумбия белән Эквадорга сату каралган.

Узган елда завод үзебезнең илдә уздырыла торган «Нефть, газ. Нефть химиясе» дип аталган нефть химиясе күргәзмәсендә катнашкан, ТР Сәүдә-сәнәгать палатасы составына кергән, шулай ук халыкара сыйфат стандартлары, экологик менеджмент, сәламәтлек саклау һәм хезмәт куркынычсызлыгы таләпләренә туры килү буенча аудитор тикшерүе узган. Моннан тыш, «Август-Алабуга» ҖЧҖ коллективы, инвестицион проектларны гамәлгә ашыруга керткән өлеше өчен, Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт хатына лаек булган. 2020 ел завод лабораториясе өчен дә истәлекле булган, ул аттестация процедураларын уңышлы узган. Былтыр завод үзе өчен яңа булган «Миура» гербицидын җитештерә башлаган. 2021 елда тагын биш төрле яңа гербицид чыгарырга планлаштырыла, шул исәптән «Балерина Супер», «Ластик Топ» һәм «Гамбит», шулай ук «Брейк» инсектициды.

Предприятиедә коллектив өчен социаль проектлар да актив рәвештә гамәлгә ашырыла, чөнки, мәгълүм булганча, барысын да кадрлар хәл итә. Хәзерге вакытта заводта 226 хезмәткәр эшли, алга таба аларның саны 300 гә җитәргә мөмкин. Уртача

Реклама. Фотолар «Август-Алабуга» ҖЧҖ-нән алынды



хезмәт хакы 60 мең сумнан артып китә. Территориядә ачык һавада спорт мәйданчыгы бар. Җәй көне «Август-Алабуга»да беренче ярышлар узган. Сәламәт яшәү рәвешен популярлаштыру максатыннан заводның үзенең Физкультура-спорт җәмгыяте барлыкка килгән – ярышларда катнашу чыгымнарын предприятие үз өстенә алган. Завод Алабуга шәһәренә дә ярдәм итә – 2020 елда медицина учреждениеләренә, ветераннарга һәм иҗтимагый оешмаларга тулаем ярдәм күләме 1 млн 383 мең сум тәшкил иткән.

2020 елда дистәләрчә завод хезмәткәре өстәмә белем алуын да билгеләп үтәргә кирәк. Моннан тыш, Рационализаторлык тәкъдимнәре нигезләмәсе эшләнеп, кулланылышка кертелгән, аның нигезендә предприятиедә эшләүче һәркем эш барышын яхшырту буенча үзенең идеясен тәкъдим итә һәм аның өчен тиешле бүләккә лаек була ала. Объектның шактый куркыныч булуын исәпкә алып, заводта күптән түгел генә үзенең штаттан тыш авария-коткару бүлекчәсе төзелгән, аны предприятиедә эшләүчеләр тәшкил итә.

Заводның төп үзенчәлеге – анда күп процессларның югары дәрәҗәдә автоматлаштырылган булуы, бу исә, үз чиратында, җитештерүнең сыйфатын һәм нәтиҗәлелеген тәэмин итә. Сәнәгать роботлары, автоматлаштырылган комплекслар һәм цифрлы җиһазлар куллану нәтиҗәсендә кеше факторы һәм кул хезмәте бик аз дәрәҗәдә. Мәсәлән, предприятиедә һәркайсы 470 кг күтәрә ала торган KUKA[1] маркалы паллетларга урнаштыручы ике робот бар. Алар Германиядә эшләнгән, җитештерүдә төрле бурычларны җиңел генә хәл итү мөмкинлеге бирә. Роботның төп вазыйфасы – продукцияле тартмаларны автомат рәвештә паллетларга урнаштырып бару. Шундый бер агрегат берьюлы 100 кг продукция күтәреп, өч фасовкалау сызыгын чиратлаштырып хезмәтләндерергә сәләтле, шул рәвешле предприятиенең ресурслары һәм вакыт янга кала. Предприятиедә шулай ук Германиянең Cyklop[2] фирмасының паллетлый торган комплекслары эшли, алар сәгатенә 50 паллет куәткә ия, әзер продукцияне тартмаларга тутырудан алып, складларга илтеп куюга кадәр эшләр циклын башкаралар. Складта программалы идарә итү аша продукциянең һәрбер төрен танып белү, шулай ук саклау урыннарында калган продукция буенча мәгълүматны теләсә кайсы вакытта белеп була.

Мәгълүмати технологияләр бүлеге арсеналында PRTG[3] базасының мониторинг системасы бар – телевизион мониторы булган бәләкәй генә компьютерда предприятиедәге барлык мәгълүмати процесслар чагылып бара. Экранда онлайн режимда челтәргә тоташтырылган җиһазны, аның эш режимын, коммутатор процессорына йөкләнешен, эчке туплагычта буш урынны, суыту системасының эшен, җиһазларның агымдагы температурасын, электр белән тәэмин ителешен, челтәр портында трафик саны турындагы мәгълүматны күзәтеп барырга була. Нинди булса тайпылышлар булган очракта Мәгълүмати технологияләр бүлеге хезмәткәрләренең телефоннарына СМС килә, ул хәбәр электрон почтага да җибәрелә.

Предприятиенең мөмкинлекләре турында «Август» фирмасы АҖнең генераль директоры Александр Усков болай диган иде: «Хезмәт бурычларымны үтәгәндә, миңа үзебезнең илнең генә түгел, чит илләрнең дә химия предприятиеләрендә булырга туры килгәне бар. Һәм бүгенге көнгә җитештерү процессларын автоматлаштыру дәрәҗәсе ягыннан, уникальлеге һәм заманча җиһазландырылуы ягыннан «Август-Алабуга» дөньядагы иң яхшы химия заводларының берсе дип, ышанып әйтә алам!»

«Август» компаниясенең шигаре болай яңгырый: «Безнең белән үсү җиңелрәк!» Алабугадагы җитештерү мәйданының алга таба да безнең аграрийларга үсәргә һәм зур уңышлар җыеп алырга ярдәм итеп, әлеге кагыйдәгә тугры калачагына шик юк!

[1] KUKA – КУКА; [2] Cyklop – Циклоп; [3] PRTG – ПРТГ.

МАРАТ ХӘЙРУЛЛИН: «БЕЗНЕҢ ХЕЗМӘТНЕҢ ТӨП КҮРСӘТКЕЧЕ – ПАЦИЕНТЛАРНЫҢ КАНӘГАТЬ БУЛУЫ»

Медицина хезмәтләре күрсәтү базарында пластик хирургия хезмәте күрсәтү иң популяр юнәлешләрнең берсенә әйләнде. Пластик операцияләр ясаучы хирург Марат Хәйруллин бу өлкәдә 20 елдан артык эшли, һәм шушы вакыт эчендә үзен клиентларның ихтыяҗларына югары дәрәҗәдә җавап бирә ала торган оста белгеч итеп күрсәтте. Бөтен ил, бөтен дөнья медицинасы өчен катлаулы булган елда да әлеге өлкәдә клиентлар арта гына бара.

– Марат Максутович, бүгенге көндә сез, меңнәрчә операция ясаган, абруйлы белгеч, тәҗрибәле хирург булып торасыз. Бу һөнәргә ничек килдегез, хезмәт юлыгыз кайдан башланды?

– Мин табиблар династиясеннән дияргә дә ярый, чөнки әнием – табиб. Әлеге өлкә миңа кечкенәдән таныш. Мәктәптә укыганда ук, параллель рәвештә медбрат булып эшләп, тәҗрибә туплый башладым. Ир-егеткә терапевт кына булып «утыру» килешми дип, Казан медицина институтына укырга кергәндә, «балалар хирургы» дигән белгечлекне сайладым. Соңыннан икенче квалификация алдым: пластик операцияләр ясаучы хирург. Миңа бик ошый һәм менә 21 ел инде шушы һөнәремә тугрылык саклыйм.

– Хәзер сезнең белгечлек көннән-көн популярлык яулый бара. Бу турыда газеталарда язалар, телевидениедә роликлар төшерәләр, социаль челтәрләрдә фикер алышалар. Эшегез нидән гыйбарәт?

– Пластик хирургия буенча махсуслашу 1940 нчы еллар ахырында барлыкка килә, әмма Россиядә ул 2011 елда гына теркәлә, гәрчә андый операцияләрне күптән ясасалар да. Ул әле яшь фән, даими рәвештә камилләшә тора –

Реклама. Фото Марат Хәйруллинның шәхси архивыннан алынды

ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ. НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТОВ

ай саен Германия, АКШ, Италия, Испаниядәге хезмәттәшләребез белән конференцияләр уздырабыз, яңа технологияләр кулланабыз. Даими рәвештә вебинарлар карыйбыз, үзебез үткәрәбез, чит ил белгечләре белән тәҗрибәләр алышабыз. Һәм безнең хирурглар тамчы да калышмый! Чит илдә яхшырак дигән стереотип дөрес түгел – безнең илдә пластик хирургия югары дәрәҗәдә. Клиентларның теләкләре дә төрле – хатын-кызларның яшь буласы, матур буласы килә, 25 яшьтән үк. Иң өлкән пациентыма 82 яшь иде – без аның бит тиресен тарттырдык. Битне яшәртә торган операцияләр озак – өчтән җиде сәгатькә кадәр ясала. Пластика – шактый зур финанс чыгымнары сорый торган процедура, бездә исә кайбер төр операцияләр, илебез башкаласы белән чагыштырганда, арзанрак чыга. Клиентлар Мәскәүдән, Ульяновскидан, Себердән килә. Америкадан килүчеләр дә бар, маммопластика ясаталар – АКШта ул берничә тапкырга кыйммәтрәк чыга. Клиентларымның 97 процентын нәфис затлар – хатын-кызлар тәшкил итә, әмма ир-егетләр дә елдан-ел активлаша бара. Әйтик, уңышка ирешкән эшкуарлар, дәүләт хезмәткәрләре һәм медиашәхесләр, ботокс һәм контурлы пластика ясатып, үзләренең югары статусын сакларга тели.

– Сезнең медицина учреждениесендә тагын нинди операцияләр ясала? Иң югары нәтиҗәләргә ирешү өчен нинди җиһазлар кулланасыз?

– Гомумән, без пластик операцияләрнең бөтен төрен дә уңышлы башкарабыз – балалар операцияләре, сөт бизләренә, төзәтә һәм яшәртә торган операцияләр, пластика һәм җөйләрне төзәтә торган. Кагыйдә буларак, балаларга отопластиканы җиде яшьтән – мәктәптә үчекләшә башлагач ясыйлар. Хәзерге вакытта аппаратлы косметология үсештә, һәм без һәр төрле яңалыкны актив рәвештә кулланабыз. Бездә ярты елга бер тапкыр югары класслы инженер-техниклар командасы җиһазларны тикшереп тора, алар клиникада даими штатта эшли. Медицина базарында иң яхшылардан санала торган Schtorc немец фирмасы җиһазларында эшлибез. Ул бик кыйммәтле һәм бик төгәл. Бирегә мин шулай ук хирургия бүлеге мөдире дә, без бүсергә ясала торган операцияләрдән алып, холецистостомиягә кадәр ясыйбыз.

– Клиника турында җентекләбрәк сөйләгез әле. Нинди дәвалау мөмкинлекләре белән тәэмин итә ул, һәм организмны тикшерү процессы ничек бара?

– Безнең клиника – игътибарлы медицина клиникасы, югары дәрәҗәле медицина учреждениесе. Без пациентлары турында кайгырта торган билгеле «Мейо» клиникаларының Европа стандартлары буенча эшлибез. «Скандинавия» – иң яхшы клиникаларның берсе, клиент бездә анализлардан башлап, операциядән соңгы дәвалануның тулы циклы белән тәэмин ителә. Төрле белгечләр, консультацияләр яки тикшерүләр бар, МРТ үткәрүгә кадәр. Нәрсә кирәк – барысы да бар. Бездә заманча газлы севоран наркозы кулланыла – аларның сәламәтлеккә зыяны юк диярлек. Сәгатьләр буена ясалган операцияләргә карамастан, организм бу төр наркозны күпкә җиңелрәк кичерә. Косметология буенча ясалган операцияләрдән соң, пациентның хәле катгый контрольдә тотыла. Операциягә чират айга якын алдан билгеләнә, һәм ул шулай тиеш тә. Пациентлар да, без дә үзебезне куркыныч астына куймас өчен, процедураларга билгеле бер әзерлек эшләре башкарыла: алар кардиолог һәм эндокринологтан башлап, УЗИ, терапевтка кадәр тикшеренүләр уза. Бездә кадрлар мәсьәләсе хәл ителгән, «урамнан» кергән табиблар безгә эләгә алмый, биредә тәҗрибәле һәм югары квалификацияле белгечләр генә эшли.

– Эпидемиологик вазгыять ноктасыннан караганда, узган ел пластик хирургия өлкәсе өчен катлаулылыклар тудырмадымы?

– 2020 елда бик күпләр өчен проблема тудырган пандемиягә карамастан, безнең өлкәдә уңай тенденцияләр күзәтелде, ихтыяҗ ике тапкырга диярлек артты. Коронавирус сәбәпле чикләүләр белән бәйле, кешеләр чит илләргә күпләп чыга алмый башлады, акчалары янга калды, һәм алар сәламәтлекләренә игътибар итә башлады. Шуны да әйтеп үтәсе килә: клиникага килгән һәркем COVID-19 га тикшерелә. Хикмәт шунда: безнең клиникада бала тудыру йорты да бар, шуңа да без йөкле хатыннарга куркыныч тудырмас өчен, вируска каршы чараларга җаваплы карыйбыз.

– Хәзерге заманда җәмгыятьтә тышкы кыяфәткә аеруча зур әһәмият бирелә. Сезнең өчен эштә иң мөһиме нәрсә? Пациентларның иминлеге хакына хезмәт итү өчен сезне озак еллар нәрсә илһамландыра?

– Минем өчен иң мөһиме – клиентларның эмоциональ яктан канәгать калуы, бернәрсә белән дә чагыштырып булмый торган тойгылары. Барысын да исәпкә алганда, клиент гарантияле рәвештә югары класслы медицина ярдәме ала, аны тәҗрибәле белгечләр игътибар белән алдынгы җитештерүчеләрнең иң заманча җиһазларында карый, шуңа да ул уңай нәтиҗәгә ышанып килә. Бу безнең хезмәтнең нигезе – клиентларның бездән канәгать булып китүе. Аларның бәхетле йөзләре безгә алга таба да эшләргә этәргеч бирә. Алай гына да түгел, нәкъ менә пластик хирургия өлкәсендә без турыдан-туры 100 процентка эшләргә ниятлибез, чөнки биредә «сарафан» радиосы эшли, шулай ук эшнең ни дәрәҗәдә югары сыйфатлы итеп башкарылуы клиентның туры мәгънәсендә йөзенә язылган була – иң яхшы реклама шул!

“
– Минем өчен иң мөһиме – клиентларның эмоциональ яктан канәгать калуы, бернәрсә белән дә чагыштырып булмый торган тойгылары. Барысын да исәпкә алганда, клиент гарантияле рәвештә югары класслы медицина ярдәме ала, аны тәҗрибәле белгечләр игътибар белән алдынгы җитештерүчеләрнең иң заманча җиһазларында карый, шуңа да ул уңай нәтиҗәгә ышанып килә.

ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ, НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТОВ

ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

Реклама 16+

Безнең Инстаграмда – «Татарстан»ның йөрәге!

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

игелекле эшләр /

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

Бу санда тәкъдим итәбез:

Татарстан Президенты матбугат секретаре бәйрәм хөрмәтенә **НИНДИ** сый әзерләде

Онытыла барган шөгыльләрне **КАЙДА** эзләп таптык

Татарстанның **НИЧӘ** төзелеше ил буенча иң яхшы 10 проект исәбенә керде

Әлки районы башлыгы **НӘРСӘ** турында хыяллана

ТАТАРСТАН
ЛЕНИНА
и история РКП(б)
ТАТАРСТАН
ВЕСТНИК

РЕДАКЦИЯ КУХНЯСЫ

ЛИЛИЯ ГАЛИМОВА ГӨБӘДИЯ ПЕШЕРӘ

Якынлашып килүче Ватанны саклаучылар көне уңаеннан «Татарстан» журналы Татарстан Республикасы Президентының матбугат хезмәте җитәкчесе Лилия Галимова белән татар халык ашы – гөбәдия пешерде.

ХУҖАБИКӘ

ТР Президенты командасында иң гүзәл генә түгел, иң уңган да хатын-кызлар эшләвен «Татарстан» яхшы белә. Чираттагы мисал – безнең каршыбызда: Татарстан Президентының матбугат хезмәте җитәкчесе Лилия Галимова башына яулык бөркәнүгә, аш бүлмәсендә бөтен нәрсәгә җан керде... Күз ачып йомганчы, плитәдә дөге пешә, куна тактасында камыр җәелә башлады, күңелне исә өйдә пешкән тәмле нигъмәтләрне көтү ләззәте биләде...

– Лилия, җитәкчелек итү һәм бәлеш пешерүне ничек бер-берсенә яраштырып була соң?

– Җитәкчелек итү – шул ук эш бит ул. Мәсәлән, минем әнием инде 41 ел буе хастаханәдә эшли. Иртәнге сәгать 8 дә эшкә китә һәм кичке 5 тә кайта. Көн саен, өйгә кайтышлый, ул кибеткә керә, чөнки аңа кичке аш әзерләү өчен продуктлар кирәк. Һәм бу гомер буе көн саен шулай кабатлана. Ул моны бик тыныч кабул итә – эшне һәм көндәлек мәшәкатьләрне бер дә авырсынмыйча яраштырып яши. Бүгенге мөмкинлекләр исә көнкүрешне тагын да җиңеләйтә: заказ бирсәң, теләсә кайсы ашамлыкны өйгә үк китерәләр. Шуңа күрә хатын-кызның тормышын икегә – йә йорт кына, йә эш кенә бүлүне дөрес түгел, дип саныйм. Бөтен нәрсәгә өлгереп була. Икенче бер нәрсә бар: хатын-кызларның кайберләре ашарга пешерергә ярата, икенчеләре яратмый. Әмма андыйлар өчен дә мөмкинлекләр җитәрлек: ярымфабрикатлар, әзер ризыклар, өйгә китереп бирү... Хәзерге заманда мөмкин булмаган нәрсә юк, шунлыктан көнкүреш көннән-көн җиңеләя бара.

ҺӘРВАКЫТ АЛГА!

– Сез ничек уйлыйсыз, журналист һөнәре дә үзгәрә, җиңеләя барамы?

– Әлбәттә, үзгәрә. Кем өчендер бу процесслар бик җиңел үтә, кемгәдер исә кыенга туры килә. Журналист һөнәре бик тиз үзгәрүчән, даими яңарып торучан бит ул. Заманча тенденцияләр, яңа технологияләр, мәгълүмат табуның тизләнүе, гаджетлар, эшнең яңа форматлары, интернет – болар барысы да журналист эшенә сизелерлек үзгәрешләр кертә. Минемчә, безнең һөнәр – иң кызыклысы. Ул башкаларга охшамаган – күп еллар буе бер үк нәрсә белән шөгыльләнү түгел

Фото: Александр Ефремов, Рамиль Гали

БЕЗГӘ КИРӘК БУЛАЧАК:

- атланмай – 250 г;
- йөзем – 250 г;
- корт – 300 г;
- маргарин – 180 г;
- кефир – 200 мл;
- йомырка – 5 данә;
- дөге – 1 стакан;
- он – 3 стакан;
- тоз – 0,5 чәй кашыгы;
- камыр көпшәкләндергеч – 1 чәй кашыгы;
- сөт – 1 аш кашыгы.

инде. Син һәрвакыт укырга, өйрәнергә тиеш, алайса беркемгә дә кирәгең булмаячак. Син һәрвакыт тизләнергә тиеш, югыйсә материалың актуальлеген югалтачак. Журналистның яңа технологияләрне өйрәнми хәле юк, моның мең төрле сәбәбе бар. Ә син һәрвакыт алга барасың икән, бу үзеңә дә рәхәтлек бирә.

БАСМА МАТБУГАТ ИНТЕРНЕТТАН УЗДЫРЫРГА ТЫРЫШМЫЙ

– Сезнеңчә, басма матбугатны нинди язмыш көтә, яңа технологияләрне үзләштерүдә иң алга китүчеләр аның көннәре санаулы, дип фаразлый бит?

– Газета редакцияләрендә интернет-басмалардагы һәм яңалыклар программаларындагы кебек оперативлык түгел, бәлки хикәяләү, анализлау осталыгы таләп ителә... Әлеге осталык журналист эшендә иң кирәклесе дә, аны саклау мөһим. Гаммәви матбугат чараларының һәр юнәлешенең үз төсмере бар. Һәм мин, бүген газеталарны беркем дә укымый, диючеләр белән килешмим. Бу дөрес түгел! Мин билгеле бер басманы көтеп алучы бик күп кешене беләм: аларга уку процессы, уку гадәте мөһим – газетаны, журналны тизрәк карап чыгу, иң кызыклы мәкаләне сайлап уку, ләззәтләнү, башкаларга да укырга тәкъдим итү... Басма матбугат, бер мизгеллек яңалык кебек, эфирга, галәмгә чыгып китеп югалмаячак. Аны һәрвакыт үзеңдә сакларга, кемгәдер күрсәтергә, бүләк итәргә, истәлеккә сакларга мөмкин. Базарда басма сүзнең төрле вариацияләре никадәр күбрәк пәйда булса – укучылар өчен шулкадәр яхшырак. Интернетны үз иткәннәр интернеттан укый, газета-журналларны яратканнар – басма матбугатны укый. Һәркем үз кызыксынуын һәм ихтыяҗын баса, бөтен кешене бер калыпка салырга кирәкми. Гаммәви матбугат чараларының теге яки бу формалары, әлеге ихтыяҗны канәгатьләндерү өчен, барыбер яшәргә тиеш. Мин, басма матбугат һәрвакыт нәшер ителер, дип уйлыйм. Ихтимал, хәзерге интернет-басмалар кебек бик күп булмас алар. Әмма аларның бурычы – интернеттан уздыру түгел, бәлки сыйфатлы материал әзерләү. Табигый ки, әгәр кемнеңдер ниндидер яңалыкны шул мизгелдә үк беләсе килә икән, ул интернетка мөрәҗәгать итәчәк. Ә инде ниндидер тирән, кызыклы, мавыктыргыч, үзең дә кушылып хыяллана, фикер йөртә торган мәкаләне укыйсың килә икән – бу БАРЫ ТИК газета яки журнал гына булырга мөмкин.

– Үзебез җитештергән һәм өстебезгә һәр тарафтан чиләкләп койган яңалыклар яңгыры безне акыллырак итәме?

– Сезнең каршыгызда гаять күп яңалык җитештергән һәм җитештерүче кеше басып тора. Бу миңа ничек тәэсир иттеме? Бередә эш акылда түгел, бәлки хәбәрдарлыктадыр, дип уйлыйм, чөнки без һәр вакыйганы белеп торырга тиеш. Чынлыкта хәзер инде хәбәрләрне журналистлар гына түгел, без барыбыз да тудыра. Социаль челтәрләрдә безнең һәркайсыбызның аккаунты бар, алар аша без бер-беребезгә даими рәвештә ниндидер яңалык тапшырабыз. Бүген бу – бик киң таралган күренеш: урамда ниндидер кызыклы нәрсә күрсәләр, кешеләр аны фотога һәм видеога төшерә, социаль челтәргә урнаштыра һәм мәгълүмат чыганагына әйләнә – аны башкаларга ирештерә. Без үзебезнең социаль челтәрдә шул мәгълүмат белән танышабыз... Шунлыктан, минемчә, хәбәрләрнең күп булуы начар түгел, тик менә мөһим яңалыкларны мәгълүмати чүп-чардан аера белергә кирәк. Чөнки әлеге чүп-чарның безнең интеллектны зәгыйфьләндерүе дә ихтимал.

ДӨНЬЯ БЕЛӘН МӘГЪЛҮМАТ ХУҖАСЫ ИДАРӘ ИТӘ

– Бүген мәгълүмат – иң зарур продуктмы? Пандемиянең беренче көннәрендәге карабодайдан да кирәгрәкме?

– Соңгы елларда тарихның сәяси вакыйгаларга бәйле үсешен исәпкә алганда, бу һичшиксез шулай. Без аны инде мәгълүмат дәрәҗәсендә үк аңлыйбыз. Һәм «Кем мәгълүматлы, шул дөнья белән идарә итә» гыйбарәсе бүген бөтенләй башка мәгънә ала башлады. Чөнки без геосәяси мәйданда сәясәтчеләр, башка илләр арасында глобаль үзгәрешләр баруын күреп торабыз... Гаммәви мәгълүмат чараларыннан башка исә без анда нәрсә булганны белмәс идек. Бу биредә дә, анда да карарлар кабул итүгә йогынты ясый. Ягъни, һичшиксез, мәгълүмат, бигрәк тә эксклюзив булганда, бүген шактый сакраль мәгънәгә ия. Аның кем кулында булуы исә – икенче мәсьәлә. Чөнки тиешсез кулга эләккән очракта зур зыян китерергә мөмкин. Мәгълүмат белән бик сак эшләргә кирәк. Соңгы елларда без фейк-ньюс тенденциясеннән никадәр зыян күрдек! Кайвакыт, хәтта ниндидер ялган хәбәрне кире каккан да, моның инде беркемгә дә кирәге калмавын ачыклыйбыз. Минем көн саен бик күп мәгълүмат белән эш итүемне исәпкә алганда, укучыларга киңәшем шул: бер үк хәбәрне төрле чыганаклардан укырга тырышыгыз – чагыштырыгыз һәм кабат-кабат тикшерегез. Минем эшемнең асылы да нәкъ менә шул инде.

МӘГЪЛҮМАТ БИРҮ ГЕНӘ ТҮГЕЛ, Ә НӘТИҖӘ ӨЧЕН ЭШЛӘҮ

– Сезнең өчен гаммәви матбугат чараларында һәм матбугат хезмәтендәге эш арасында сизелерлек аерма бармы? Озак вакыт буе болай саналган бит: янәсе, гаммәви матбугат чараларында эшләүчеләр төп көчен мәгълүмат табуга тота, ә матбугат хезмәтләрендә эшләүче журналистлар, киресенчә, мәгълүматны ничек тә алардан яшерергә тырыша.

– Әлбәттә, болар икесе ике төрле бурыч. Әмма ун ел буе яңалыкларда эшләү тәҗрибәм нык булыша, чөнки мин иң әүвәл журналист буларак фикерлим. Ә яңалыклар әзерләүчедә эшли-эшли бер сыйфат барлыкка килә – һәрвакыт мәгълүматка шикләнеп карау. Ул тормышта булыша да, комачаулый да. Мин нинди дә булса хәбәр укыйм, нинди дә булса яңалык күрәм яки миңа нәрсә дә булса сөйлиләр икән, иң әүвәл аңа шикләнеп карыйм. Моның чыннан да шулай булуына инану өчен, миңа әлеге яңалыкны берничә тапкыр тикшереп карарга кирәк. Һәр көн иртәнге киңәшмә вакытында Рөстәм Нургалиевичны республикадагы хәлләр белән таныштырам, кайда нәрсә язуларын, моңа кешеләрнең фикере нинди булуын, Татарстан турында федераль медиада ничек язуларын, республикабызны кайларда телгә алуларын хәбәр итәм... Бу минем һәр иртәне һичшиксез эшләнергә тиешле эшем, һәм минем ялгышырга хакым юк.

Президентка җиткерәсе мәгълүмат абсолют төгәл булырга тиеш. Ул бөтен вак-төякне һәм детальләрне җентекләп тикшерә, күп сораулар бирә, төпченә, аныклый. Ягъни мин бар сорауга да җавап бирергә әзер булырга тиеш. Чөнки безнең Президентыбыз – хәбәрдар, киң карашлы кеше, һәм хәбәр итәсе яңалыкны ул инде миңа кадәр үк белергә мөмкин. Минем шикләнүләрем һәр яңалыкны кабат-кабат тикшерергә, барлык детальләрне җентекләп ачыкларга булыша. Бу көн картинасын күзаллау мөмкинлеген бирә, без аңа яңалыкларны бары нидер хәбәр итү өчен генә җиткермибез бит. Әлеге яңалыкларга нигезләнеп, еш кына бик мөһим карарлар кабул ителә. Халыкка, тармакларга ниндидер ярдәм чарасына бәйле карарлар. Кайвакыт бу – республика халкының күпчелегенә кагылышлы глобаль яңалыклар, ә кайчагында исә – чыннан да президент игътибарына лаеклы бердәнбер кешенең бердәнбер тарихы булырга мөмкин. Бу мәгълүмат бирү генә түгел, ә нәтиҗә өчен эшләү.



– Татарстан Президенты матбугат хезмәтендә барлыгы ничә кеше?

– Турыдан-туры оештыру белән шөгыльләнүчеләр нибары алтау гына. Әмма безнең техник хезмәткәрләребез күп: фотографлар, видеографлар – турыдан-туры трансляцияләр алып баручы һәм социаль челтәрләр белән эшләүче кешеләр...

– Президентның эш сәфәрләре бик күп. Сез һәрвакыт аны озатып йөрисезме?

– Операторлар һәм фотографлар алмашына, ә мин үзем барысына да өлгерергә тырышам. Кайвакыт кына коллегаларым алыштыргалый.

– Ягъни барыгызның да алмаштыручысы бар, ә Президентыбыз берүзе барысына да ничек өлгерә соң? Графигы бик тыгыз бит аның.

– Мондый киеренке графикка авылда үскән кеше генә чыдый ала. Татар авылы нинди соң ул? Анда бик иртә йокыдан торасың, чөнки, беренчедән, һәр гаиләдә мал-туар бар һәм аларны карарга кирәк. Авыл халкы таң атканчы тора һәм, эшкә киткәнче, терлекләрен ашатырга, асларын чистартырга тиеш, хатын-кызлар исә гаиләгә иртәнге аш әзерли, балаларын мәктәпкә озата һәм аннары гына үзләре дә эшкә китә. Ябалакмы син яки тургаймы, мөһим түгел – авылда тугансың икән, димәк, башка вариант юк. Бу – яшәү рәвеше. Эштән соң кабат йорттагы мәшәкатьләр көтә. Ягъни бу синең туган мохитең. Анда кемдер эшләп, кемдер ял итеп ята алмый. Авыл гаиләсендә һәркем балачактан хезмәткә өйрәтелгән. Минемчә, Президентыбыз башка яшәү рәвешенең ничек булуын белми дә, холкы да шундыйрак. Аңа бөтенесен тиз эшләргә кирәк, нәтиҗәсе шундук күренерлек булсын. Әгәр ул сиңа нинди дә булса эш йөкли икән, уйланып торырлык вакытың юк, син аны тиз арада башкарырга тиеш, чөнки Рөстәм Нургалиевич теләсә кайсы вакытта аның ничек үтәлешен тикшерергә мөмкин. Нинди дә булса тагын бер эш тә өстәргә мөмкин әле. Бу өзлексез процесс. Безнең эштә иң рәхәте – нәтиҗәне күрү. Син бик күп кешенең ниндидер глобаль проблемаларының чынбарлыкта ничек хәл ителүен күрәсең. Инде өметсез тоелган бурычлар күз алдында хәл ителә, чөнки ярдәмчеләр, команда, барысы бердәм булып, җиң сызганып эшкә керешә. Президентның барлык тармакларда да бик күп талантлы ярдәмчеләре бар. Уртак көч тауны күчергәч, икенчесенә тотынабыз. Мондый команданың хәленнән килмәслек бернәрсә дә юк.

АЛЛАҺ ИРТҮК ТОРГАННЫ ЯРАТА

– Сер булмаса әйтегез әле, Сез иртән сәгать ничәдә уянасыз?

– Мин 5.45 сәгатьтә торам. 7.00 сәгатьтә мин инде эштә булам. 8.00 сәгатьтә кече киңәшмәдә бүгенге көнгә планнар һәм оператив яңалыклар тикшерелә. Мин – беренче докладчы, көн картинасын сурәтләп бирәм. Хәзер иртәнге киңәшмәләрдә республикада коронавирус буенча санитария-эпидемиология вазгыяте, ничә очрак теркәлү, бу кешеләрнең хәле, хастаханәләрдә эшнең ничек торуы, авыруларга ничә урын кирәклеге һ.б. турында да хәбәр ителә. Аннары инде агымдагы киңәшмә башлана: чаралар, Казан, районнар буенча сәфәрләр. Җәен көненә өчәр районга бара идек, кичкә әле Казанда да берәр чара планлаштырылган була. Барлык чаралар тәгәлләнгәч кенә, эш көне дә тәмамлана. Шул сәгатьтән шул сәгатькә кадәр эшлибез дә, аннары теләсә нишләсеннәр, дигән тәртип түгел. Юк. Йокларга эш беткәч кенә ятарга туры килә. Шулай да 6-7 сәгать йокларга тырышам.

– Ә каян көч аласыз?

– Минем көчсез калганым юк. Көч туплау урыны – туган йортым һәм әти-әнием. Һәм гомумән, мин шундый энергетика атмосферасында, шундый актив кешеләр белән эшлим, көч кимеми, ә киресенчә, өстәлә генә бара. Тагын бер кабатлыйм инде, бигрәк тә эшнең нәтиҗәсен күргәндә рәхәт. Эшсез озак тора алмыйм, эчем поша башлый. Минем дә тәрбиям авылныкы бит. Кем татар авылында үскән, башкача булдыра да алмый. Үзе дә эшләячәк, янәшәдәге һәркемне дә эшләргә мәҗбүр итәчәк.

– Димәк, без, татар авылында тәрбияләнү төбәгебез үсешенә ярдәм итә, дигән нәтиҗә ясый алабыз. Чөнки Аллаһы Тәгалә иртә торучыларны ярата.

– Әлбәттә.

РОБОТМЫ, ӘЛЛӘ УНИВЕРСАЛЬ ЖУРНАЛИСТМЫ?

– Хәзер, яманаты чыккан пандемия вакытында, хәер, инде аңа кадәр дә, күп һөнәрләр юкка чыга. Сатучы, кассир, машинистларны роботлар кысрыклап чыгара... Сез ничек уйлыйсыз, робот журналистны алыштыра аламы? Менә Сезне, мәсәлән.

– Эре федераль мәгълүмат агентлыкларында аналитика таләп ителмәгән яңалыкларны язучы системалар бар инде. Кайчан да булса бу һәр һөнәргә дә кагылачак. Әлбәттә, кеше кулы һәм кеше баш мие өлгерә алмаган мәгълүмат агымы өчен коры фактуралы хәбәрне оператив җиткерә торган автоматлаштырылган системалар кирәк. Бу журналистика өчен бернинди куркыныч та тудырмый. Телевидениедә, мәсәлән, күптән инде зур төшерү төркеме таләп ителмәгән эш форматына күчтеләр. Хәзер кесә телефоны күп нәрсәгә сәләтле. Аңарда сыйфатлы видео һәм фото төшереп була. Журналист универсаль кешегә әйләнә: ул интервью да ала, шул телефоннан эфирга да чыга, хәбәрне дә яза. Бөтен 2020 ел буе минем кулымнан телефон төшмәде. Даими рәвештә төрле сәфәрләрдә, районнарда булдык. Пандемия пигында, әлбәттә, өйдә утырырга туры килде. Үзизоляция вакытында мин кызыклы тәҗрибә үткәрдем. Үземнең һәр пәнҗешәмбе уздырыла торган брифингларымны мин өйдән үткәрдем. Айпад аша элемтәгә чыгам да, ютуб буенча барлык журналистлар кушыла, мин сөйлим. Мәгълүматны телефон аша алам: сораулар җибәрәләр дә, мин барысын да хәл итәм. Ягъни бу шундый абсолют дистант булды: безнең һәркайсыбыз өйдә утырды, тик без зур эш башкардык. Бу безнең бүгенге чынбарлык, аннан куркырга кирәк түгел. Тиз арада үзгәрергә өйрәну таләп ителә. Заманга яраклашырга, мәгълүматны вакытында бирә белергә кирәк. Җәен, операторның видео төшергәнен көтеп тормыйча, бер көндә өч районнан оператив хәбәр әзерләргә кирәк булды. Барысын да телефоннан эшләдек: текст язабыз, яңалыкны сайтка элəбез, чатка җибәрәбез – һәм 5 минуттан яңалык барлык мәгълүмат агентлыклары тасмасына эләгә. Якын киләчәктә безнең барыбызны да шундый форматтагы эш көтә. Бу роботның хәленнән килерме икән? Юктыр, мөгаен. Идеяләрне, креативлыкны, кешеләр арасындагы ихлас мөнәсәбәтләрне бернинди робот та алыштыра алмый. Робот безнең Президентыбыз белән дә уртак тел тапмастыр. Рөстәм Нургалиевич еш кына стандарт булмаган карарлар кабул итә – бу исә теләсә нинди роботны тиз арада аптырашта калдырачак.

«КАРЬЕРА» РЕЦЕПТЫ

– Яшь журналистка ничек итеп Президентның матбугат хезмәте җитәкчесе дәрәҗәсенә күтәрелергә? Лилия Галимованың «карьера» рецепты бармы?

– Һәркемнең үз юлы инде. Мин алтынчы сыйныфтан башлап газетага мәкаләләр яздым. Бервакыт әтинең коллегасына үземнең журналист

булырга теләвемне әйттем. Ә аның килене Казанда телевидениедә эшли икән, кызыксынсаң, кил дә журналистларның ничек эшләгәнен кара, диде. Мин Казанга килдем, «Яңа Гасыр» телевидениесендә (ТНВ) яңалыклар хезмәтен Резида Галимҗан кызы Макуева җитәли иде. Ул биргән биремне җиренә җиткереп үти дә алмадым кебек... Мин университетка укырга кергәндә, ул инде Дәүләт Советы матбугат хезмәтендә эшли иде, үземне стажировкага алуын үтендем. Һәм яхшы кулга эләктем. Анда коллектив искиткеч иде – мине кызлары кебек кабул иттеләр. Алдан ук әйттеләр: практиканың ике варианты бар – йә без бер-беребезгә комачауламыйбыз, тиешле вакыт үткәч киләсең дә, без синең кирәкле кәгазьләреңә имза куеп җибәрәбез. Яисә безнең янда күп нәрсәгә өйрәнәсең. Шулай итеп, мин анда дүрт елга калдым. Журналистика факультетының телевидение бүлегендә укыдым һәм шул ук вакытта эшләдем дә. Миңа шактый җитди биремнәр бирделәр – халыкара чаралар, Европа Советының мәдәният комитеты утырышларын уздырдык... Җәйге практикамны телевидениедә үттем. Университетны тәмамлагач, ВГТРК га эшкә килдем. Башта хәбәрче, аннары махсус хәбәрче, аннары продюсер булдым... Бераздан рубрика авторы, аннары алып баручы, аннан соң мәгълүмат хезмәте башлыгы урынбасары, аннары мәгълүмат хезмәте башлыгы, директор урынбасары булдым. Ягъни 10 ел эчендә мин үземне телевидениедә эшнең бөтен форматында сынап карадым. Аннары Президент Аппаратында мәгълүмат белән эшләү, шәрехләү юнәлеше оештырылды, һәм мине Рөстәм Нургалиевич янына республика җитәкчелеге кабул иткән мөһим карарларны шәрехләүче рәсми вәкил сыйфатында чакырдылар.

100 ЕЛГА БЕРЕНЧЕ

– Үзегезнең журналистлык юлын башлаганда, моннан 10 ел элек, Сез моңа охшаш берәр нәрсә турында хыялланган идегезме?

– Әлбәттә юк. Мин бүген Президент Аппаратында эшләгән вазифа юк иде әле. Хәер, андый һөнәр дә юк иде. Рәсми вәкил – бары тик аралашу өчен җаваплы кеше, ул журналистлар аша халыкка теге яки бу карарның ни өчен кабул ителүен, киләчәктә нәрсә буласын аңлата. ТАССР төзелүнең 100 еллыгына әзерләнгәндә, оештыру комитеты утырышында мин Минтимер Шәриповичны очраттым, һәм ул үзенә генә хас зирәклек белән миңа: «Ә беләсеңме, ТАССРның 100 еллык тарихында бу һөнәрне үзләштерүче беренче кеше син бит!» – диде.

Һөнәр минем өчен чыннан да яңа иде. Элегрәк мин, гомерем буе телевидениедә эшләячәкмен, дип уйлый идем. Әмма телевидение – даими рәвештә «яңа кан» кереп торырга тиешле урын, эш хәтта яшьтә дә түгел, ә яңа кешеләрдә, аларның гадәти әйберләрне яңа караш белән, яңача ясауларында. Бу мөһим. Һәм гомумән, теләсә кайсы эштә әледән-әле селкенгәләп алу һәм үзгәрү мөһим, алайса ул туйдырырга мөмкин бит.

ҺӨНӘРМӘНДЛЕК ЭТАЛОНЫ

– Сез, мөгаен, яңа гына укуын тәмамлаган журналистлар белән еш очрашасыздыр. Күп кенә гаммәви мәгълүмат чаралары яшьләрне эшкә алырга теләми, алар начар әзерлекле, бөтен нәрсәне бутый, хаталы яза, дип зарлана. Янәсе, элегрәк исә журфак тәмамлаучылар акыллырак, төплерәк булган!.. Сез әлеге фикер белән килешәсезме?

– Мин барлык яшь журналистларга бәя бирә алмыйм. Үзем очрашканнары буенча фикер йөрткәндә, яшьләр белән генә түгел, күп еллар шул өлкәдә эшләүчеләр белән дә проблемалар килеп чыга. Без шундый гаять зур мәгълүмат агымында эшлибез һәм яшибез ки, шунлыктан кайвакыт нәрсәгәдер игътибар җитеп бетми, хаталар җибәрелә. Яшьләр – АНДЫЙ ТҮГЕЛ. Алар өчен без дә АНДЫЙ ТҮГЕЛ. Без – төрле буын. Аларның мәгълүматка таләпләре башка, эш ысуллары һәм формалары башка, нәрсәнең мөһим, нәрсәнең мөһим булмавына мөнәсәбәте башка. Әйе, хаталар бар, әмма без барыбыз да ялгышлардан сабак алабыз. Бу куркыныч түгел, дип саныйм. Бу чыннан да башка буын. Мин кайвакыт алар белән аралашам, кайберләре үзләренең тормышка карашы белән генә дә таң калдыра. Гаҗәпләнәм – алар бөтен нәрсәне үзләренчә кабул итә. Безнең кебек түгел. Безнең үз кыйммәтләребез, хәтта һөнәр сайлауда да. Мин шундый гаиләдә тәрбияләнгән ки, анда кешенең, минем әнием кебек, гомере буе бер урында эшләве һәм хезмәт кенәгәсендә бер генә язуы булу абруйлы санала иде. Бу – ул заманның һөнәрмәндлек эталоны. Ә бүгенге буын бер-ике ай эшләргә дә, ошамаса, бик җиңел генә икенче эшкә күчәргә мөмкин. Хәтта акчасы азрак булу да туктатмый аларны. Әгәр аларга эш канәгатьлек китерми икән, эшләмәячәкләр, чөнки кызык түгел. Бөтенләй башка кешеләр, бөтенләй башка кыйммәтләр хәзер.

ХАТЫН-КЫЗ ЭШЕ ТҮГЕЛ?

– Журналистика – бүген беренче чиратта сәясәт ул. Сезнеңчә, Татарстанда хатын-кыз сәяси карьера ясый аламы? Әллә бу шулай да хатын-кыз эше түгелме?

– Беренчедән, хатын-кыз, нинди генә эш белән шөгыльләнмәсен, кем белән генә җитәкчелек итмәсен, хатын-кыз булып калырга тиеш. Бу мө-

һим. Рөстәм Нургалиевичның ярдәмчеләре арасында һөнәри яктан бик көчле хатын-кызлар шактый. Алар әйләнә-тирәдәге тормышны структуралап һәм глобаль үзгәртергә сәләтле. Наталия Фишманга гына карагыз – ул агымдагы эш белән генә шөгыльләнми бит, ә бик күп кешенең тормышын яхшы якка үзгәртә. Хатын-кыз җитәкченең нинди нәтиҗәләргә ирешә алуына бер дигән мисал түгелмени бу?! Бу һәр ир--атның да хәленнән килерлек түгел әле. Һәм андый хатын-кызлар бик күп: аларның эше күренеп тормаса да, республикадагы глобаль үзгәрешләргә һәм анда яшәүчеләр тормышына гаять зур йогынты ясый. Шунлыктан мөселман төбәгендә яшәүче хатын-кыз өйдә утырырга тиеш дигән стереотип – сафсата. Татарстан җитәкчелегендә мондый хорафатларга ышанучылар юк. Рөстәм Нургалиевич – заманнан алдарак та бара торган кеше. Аның өчен кешенең җенесе мөһим түгел – ә менә аның үзе эшләгән җирне яратуы, хезмәт сөюе, республика өчен нәрсә дә булса эшләргә сәләтле булуы мөһим.

– Кемнәр ризыкны тәмлерәк пешерә? Ир-атлармы? Гүзәл затлармы?

– Мин ир-атлар әзерләгәнне яратам: нигәдер алар пешергән тәмлерәк тоела. Мин үзем ашарга пешермәү мөмкинлеге туса, аннан рәхәтләнеп файдаланырга яратучы һәм башкалар әзерләгәнне тәмләп ашаучы хатын-кызлардан.

– Ә башкалар пешергән ризыклардан иң яратканы нәрсә?

– Мин үзебезне гомумән бик бәхетле кешегә саныйм, чөнки без иң тәмле ризыклары белән дан казанган Татарстанда яшибез. Гөбәдия яратам. Аның майлы булуын яратам – авызда эрерлек булсын. Мантый, токмач яратам. Бала вакыттан яраткан ризыгым – бәрәңге пәрәмәче. Аны авылда дәү әнием мичтә пешерә иде. Хәтеремдә, дәү әни бик иртә тора, ашарга пешерә, ә мине искиткеч тәмле исләр уята. Аның мич янында кайнашуы, коймак пешерүе һаман күз алдымда... Бөтен нәрсә бик тәмле иде.

КРЕАТИВМЫ, ӘЛЛӘ ПИАРМЫ?

– Лилия, Сез безнең Президентның матбугат хезмәтен җитәкләүче тәүге хатын-кыз...

– Беләсезме, кайбер матбугат чаралары моны шундый зурлап язып чыккач, рәхәтләнеп көлгән идем. Әйтерсең лә, мин космоска очканмын! Әйе, миңа кадәр ир-атлар эшләгән. Ә шуннан ни?

– Берни дә түгел... Хатын-кызның язмышы шундый инде аның – үз шәхесенә игътибар җәлеп итү, бернишләп тә булмый! Менә безнең журналның 100 еллык тарихында аны беренче тапкыр хатын-кыз – Диләрә Байчурина җитәкләгәч, аның шәхесенә дә әлегәчә күрелмәгән игътибар бирелгән иде. Һәм хатын-кыз булган өчен генә түгел, бәлки журналга күп яңалык һәм креатив керткәнгә күрә дә. Ул чакта безнең сайтыбыз пәйда булды... Ә сез, ярар алайса, хатын-кыз буларак түгел, ә бәлки яңа матбугат секретаре буларак, нинди яңалыклар керттегез?

1 Пешерәбез!

2 Чистартабыз!

3 Басабыз!

4 Җәябез!

5 Майлыйбыз!

6 Куябыз!

7 Салабыз!

8 Сибәбез!

9 Турыйбыз!

10 Өстибез!

11 Майлы булсын!

12 Каплыйбыз!

13 Бөрәбез!

14 Мичкә тыгабыз!

15 Телибез!

– Без хәзер Рөстәм Нургалиевич журналистлар белән үткәрә торган матбугат очрашуларының форматын үзгәртәбез. Былтыр 8 Мартка багышланган очрашуны перинаталь үзәктә үткәрдек. Бәби тудыру системасының ничек эшләвен, җитлекми туган сабыйларны үстерү мөмкинлекләрен күрсәттек. Журналистларның икенче төркемен мәктәп ашханәсенә илтеп, республикабыздагы башлангыч сыйныф укучыларын бушлай кайнар ризык белән тәэмин итү системасының ничек эшләвен күрсәттек. Аннары барыбыз бергә җыйналдык та, Рөстәм Нургалиевич аларның сорауларына җавап бирде.

Быелгы Яңа ел алды матбугат очрашуын ТАССРның 100 еллыгына ачылган объектларның берсендә – яңа Милли китапханәдә үткәрдек. Китапханәне Милли-мәдәни үзәккә күчерү Президент карары иде. Әлеге карарга каршылар бик күп булуы да сер түгел. Әмма китапханә җәлеп итү урыны буларак та, җәмәгать мәйданы буларак та искиткеч матур килеп чыкты.

Президентның Яңа ел белән котлавының форматы да яңартылды. Без аны телевизион студиядә түгел, урамда яздырдык. Кремль ярындагы чыршы янында ул ихласрак килеп чыкты. Төп эшемнән тыш, минем бурыч – пиар оештыру да, Президентны ничек бар шулай күрсәтү. Без зур җитәкчеләрне телевизордан күргәнчә генә күзалларга күнеккән. Ә минем менә аның холкын, эш алымнарын күбрәк ачасым, күрсәтәсем, аңлатасым килә... Чөнки бу кызыклы, гыйбрәтле, халык белергә тиешле нәрсә. Шунлыктан очрашуларның яңа форматын уйлап табабыз да инде, аларда җитәкчебезнең сыйфатларын ничек тә тулырак ачарга омтылабыз. Аңа безгә ышануы өчен рәхмәт. Ышанычын ничек тә акларга тырышабыз.



ЗӘҢГӘР ШӘЛ

– Менә шулай әкренләп Президентның Яңа ел алдыннан үткәргән матбугат очрашуында Сез бөтен кешене дә таң калдырган «зәңгәр шәлгә» дә килеп җиттек. Ул Сезнең гардеробта ничек пәйда булды?

– Өлкәнәйгән саен үзеңнең тамырларыңа якыная барасың икән. Мин классик татар гаиләсендә туып-үстем, җәйләрне авылда үткәрә идем, һәм минем өчен «татарлыкны» чагылдыра торган ниндидер традицияләр, ниндидер әйберләрнең вакыт үткән саен кадере арта бара. Былтыр мин гаҗәеп хатын-кыз – рәссам һәм тегүче Луиза Скипина белән таныштым. Миңа 30 августка, ТАССРның 100 еллыгын бәйрәм итүгә, ашыгыч рәвештә милли үзенчәлекле кием тектерергә кирәк иде. Чарага өч көн кала. Һәм ул тегеп өлгертте! Мин аны алырга нәкъ өч көннән килдем һәм күрүгә аһ иттем – ул модалы да, үзенчәлекле дә, милли бизәкләр белән дә иде. Ә мин бит үземнең ни теләгәнемне дә җентекләп аңлатмаган да идем. Зәңгәр төстәге кием тегүен генә үтендем. Сөйләшә башладык та, нигәдер Кәрим Тинчуринның «Зәңгәр шәле» исемә төште. Шуннан образ туды. Мин бу спектакльне караганым юк, әмма китабын укыганым бар. Анда татар авылы һәм мавыктыргыч мәхәббәт тарихы бик кызыклы сурәтләнә. Минем төс-кыяфәтем шул образның заманча гәүдәләнеше иде.

Милли колорит – бик матур һәм оригиналь ул. Без шундый заманда яшибез, беркемне бернәрсә белән гаҗәпләндерә алмыйсың, бөтен нәрсәне сатып алып була. Минем балачагымдагы кебек кытлык юк, ул вакытта исә әнием миңа киемне үзенең иске күлмәкләреннән тегә иде.

– Чираттагы матбугат очрашуында нәрсә белән гаҗәпләндерергә җыенасыз?

– Журналистларны гаҗәпләндерүе кыен. Әмма хәзер инде моннан берничек тә котылып булмый, тырышырга туры киләчәк... Һәм кайбер фикерләр бар да инде. Әмма бу әлегә зур сер!

Татарстан журналистлары Президентның чираттагы матбугат очрашуын көткән һәм анда ничек таң калдырачакларын фаразлаган арада, «Татарстан» журналы инде гаҗәпләнә һәм яңа гына мичтән чыккан гөбәдия белән сыйлана! ТР Президенты матбугат секретаре шәхсән үзе пешергән чын татар гөбәдиясе бу! Безнең ашыбыз тәмле булсын, ә сезгә «зәңгәр шәлле» шеф-пешекченең ихлас котлауларын һәм теләкләрен җиткерәбез! **Т**



Редакция «Татар утары» ресторанына рәхмәтен белдерә.

ҺӨНӘРЛЕ ХУР БУЛМАС

Язманың видео-вариантлы да бар.

Автор: Руфия Фазылова

ЙОН ЭРЛӘҮ

Халкыбызны әйтәм, уңган да, булган да соң! Паласын да суккан, оекбашын да бәйләп кигән, казан асып, ашын да пешергән, маен да язган. Ә бүген безгә бу эшләрне эшләү түгел, хәтта сөйләү дә ят. Нишләмәк кирәк, заман белән бергә аерым шөгыльләр (сүзләр дә) тарих шүрлегенә урнаша бара... «Татарстан» журналы әнә шул ата-бабадан калган затлы һөнәрләрне, шөгыльләрне барларга булды. Яшь буын да колагына киртләп куйсын. Оныткан булсак, яңартыйк!

КАБА

Балык Бистәсе – шәл бәйләүчеләр ягы буларак дан казанган район. Биредә сабыйлар бишектә ятканда ук шәл бәйләргә өйрәнә, дип мәзәклиләр. Бишектә ятканда ук түгел инде түгелен, тик кул арасына керә башлауга, әниләр, дәү әниләр кыз балаларга инә тоттырган. Шулай итеп, узыша-узыша, өч буын шәл, йон оекбаш бәйләгән.

Балык Бистәсендә бүген элеккеге кебек шәл бәйләмиләр инде, чөнки сорау кимегән. Тик барыбер биредә хатын-кызлар кичләрен кул эшеннән башка уздырмый. Кем әйтмешли, эш канга сеңгән.

Олы Елга авылында яшәүче Дания апа Хөснетдиновада әле бу яшендә дә бер көн тик тормый – йон эрли, бәйли, сәйләннән картиналар ясый... Ә өендәге гөлләре! Гөлбакча диярсең! Хәтта чын ананас та үсеп утыра.

– Ананасны ашагач та, яфраклы ягын кисеп алып чүлмәккә утырткан идем, шуннан үсеп китте, – диде әбекәй.

Дания апа без килгәндә йонны, кабаны әзерләп куйган иде. (Үзе дә матур яулык, шәлләрен бәйләп, хаждан алып кайткан күлмәкләрен кигән.)

Сүзне озакка сузмый, эшкә керештек: иң беренче йонны язарга кирәк.

– Язгы йонны гына эрлиләр, чөнки көзгесен эрләп булмый, кыска ул. Анысы итек басу өчен генә ярый, – диде Дания апа.

Йонны язу әллә ни авыр эш түгел, чүпләрен аласың, кабартасың. Иң катлаулысы – эрләү. Әбекәебез язган йонны кабага беркетеп куйды. Каба – агачтан ясалган махсус җайланма ул. Аның очына тимер инә беркетелә. Бу йон кабадан төшеп китмәсен өчен кирәк. (Аерым якларда каба инәсез дә була.)

Хуҗабикә эш барышында үзенең кабасына бәйле тарихны да сөйләп бирде:

– Тормышка мин Яңа Чишмә районының Зирекле авылына чыктым. Ун ел яшәгәннән соң ирем үлеп китте. Тугыз һәм алты яшьлек улларым белән тол калдым. Аннан балаларымны ияртеп яңадан туган якка – Олы Елгага әйләнеп кайттым. Ә бу кабаны миңа Зиреклегә килен булып төшкәч, күрше бабай ясап биргән иде. Ул заманда да бөтен гаиләгә, күрше-тирәләргә йон эрләдем. Әлеге каба миңа бик якын, яшьлегем, балаларымның әтисе белән яшәгән елларның якты бер истәлеге. Шуның өчен дә Зирекледә калдырмадым аны...

ОРЧЫК

Йон эрләгәндә тагын бер мөһим эш коралы бар – орчык. Монысы инде каба кебек зур түгел, ә уч табаныннан аз гына озынрак, уртасы юанрак, ике баш-башы очлы таяк. (Хәер, орчыкның ни икәнен өлкән, урта буын барысы да белә.)

Әбекәебез кабага йонны беркетте дә эрләргә керешә. Бик игътибар белән карап, тыңлап торганнан соң, без дә кушылдык. Тик... моның өчен чынлап та тәҗрибә кирәк икән: йә җебе өзелә, йә орчык әйләнми...

– Бер көндә генә йон эрләргә өйрәнеп булмый ул, – диде Дания апа. – Тырышлык, сабырлык сорый торган эш бу...

– Ә сез кемнән өйрәндегез? – дим.

– Әниемнән өйрәндем. Без алты бала – биш кыз, бер малай үстек. Әни барыбызга да күлмәкләрне үзе тегеп кидертте. Әтием оста итек басучы

Фото: Лилиана Вәлитова

иде. Ул алты баласына да итек басып бирде. Нинди авыр елларда да яланаяк, өс киемсез йөрмәдек.

Санаулы минутлар эчендә әбекәй (безнең ярдәм белән дә, әлбәттә) орчыкны тутырды. Ул арада алдан әзерләп куйган икенче орчыгын да чыгарды. Шулай итеп, ике орчыктагы җепләрне бер йомгакка чорнады. Мөгаен, иң җиңел эш шул булгандыр.

– Хәзер инде йомгактагы йонны янә орчыкка чорныйбыз – монысы кату дип атала, – диде Дания апа.

Кату, ягъни җепне орчыкка чорнау да шактый катлаулы эш. Төп хикмәт – орчыкны тиз әйләндерергә кирәк. Ә ул безнең кебек кулына беренче тапкыр әлеге эш коралын тоткан кешегә җиңел түгел. Дания апага күз салам – эрләү машинасы диярсең, кулы кулга йокмый!

Шулай итеп, ике орчыктагы җепләр дә бергә бәйләнде. Иң авыр эшләр тәгәлләнде дияргә була, тик әле моның белән генә бетмәде...

Чираттагы адым – орчыктагы җепләрне аякка чорнау. Дөрес, хуҗабикә аны кулга чорнады. Ә элек хатын-кызлар, аякларын бөкләп утырып, эрләнгән җепне тез башына чорнаганнар. Исеме дә шуннан калган – аякка чорнау.

– Аякка чорнаганда кеше булса, яхшы, – дип аңлата Дания апа. – Берәү орчыкны әйләндерә, икенчесе җепне чорный. Бик бәләкәй чаклардан ук, әни, әбиләр безгә шулай җеп чорнаталар иде. Куллар арып бетә иде...

Җепләр орчыктан күчеп бетте. Хәзер ул ярты метр тирәсендәге озынча түгәрәк формага килде.

Чираттагы эш – җепне юу. Дания апа моның өчен «Фейри» куллана икән:

– Сарык йоны бик майлы була. Элек әче сабын белән юа идек, хәзер «Фейри» кулланам. Исе дә калмый, – диде.

Күбекле суда юып, ике-өч тапкыр чайкап алганнан соң, җепләрне киптерергә куярга була. Ап-ак төскә керә алар. Җиңеләеп тә китә. Шуннан... йомгакка чорныйсы гына кала.

ЙОМГАК

Безнең халыкны әйтәм, йомгакка бигрәк иркәләп эндәшкәннәр инде. Кайчак сары, йомшак, нәни дә ул... Дания апаның йомгагына да шундый берәр назлы сүз табасы килде – үзе ак, җепләре тигез... Оста кулы эшләгәне күренеп тора!

– Булгач булсын инде, әйдә, бәйләп тә күрсәтәм, – диде әбекәй. – Сарык йоны оекбаш өчен әйбәт. Безнең балалар шундый оекбаш киеп үсте бит. Көннәр буе суыкта йөреп тә, аяклары туңмый иде, чөнки сарык йоны бик җылы.

– Ә бүген кияләрме соң? – дим.

– Юк шул, исләре китми. Ике улым да гаиләләре белән авылда яши. Җиде оныгым бар, Аллага шөкер. Оныклар кечерәк чагында кияләр иде әле, хәзер носкиларны кибеттән алалар.

Шулай да, оныклар күңелен күрим дип, Дания апа кибет йоныннан башмаклар, бияләйләр бәйли икән.

– Күчтәнәчкә дип тә бәйлим, кунакка чакырсалар да, алып барам, – диде хуҗабикә.

Мин исә әле һаман сарык йонына исем китеп утырам. Без дә йон оекбашлар киеп үскән буын. Нинди салкыннарда да, көн буе урамда йөреп, аяклар ник бер өшесен иде. Күңелдә тагын бер хатирә яңарды – дәү әниләр сарык йонын тез башларына бәйләп куялар, язын-көзен галош төпләренә салалар. Имеш, болай эшләсәң, аяк авыртулары бетә...

– Әйе, авырткан җиргә кара сарык йонын куйсаң, ярдәм итә. Мин әле дә шулай эшлим, – диде Дания апа.

– Ак йон ярамыймы? – дим.

– Кара сарык йоны файдалы, дип әйтәләр инде. Әбиләрдән шулай калган. Гомер буе сарыклар асрадым. Әле дә асрыйм, Аллага шөкер. Арада гел бер кара сарык була. Әле менә кара бәрән туды...

– Алайса сез шуңа да кызлар кебек йөрисез инде? – дим Дания апага.

– Сарык йонының да файдасы бардыр. (Елмая. – Авт.) Аннары мин эш белән онытылып йөрим. Җәй көне бакча эшләре, балаларга ияреп җиләккә барам. Кайнатмалар кайнатам, күп итеп как ясыйм. Кышын тик тормаска дип, әнә шулай бәйлим, сәйләннән картиналар ясыйм.

Дания апа намазда. 2019 елда хаҗга барып кайткан, әле тагын барырга хыяллана. Дин белән дөньялыкны бергә алып баручы чын татар әбисе ул. Клубта узган төрле кичәләрдә катнаша. Олы Елганың үзе кебек актив тормыш белән яшәүче өлкәнрәк хатын-кызлары белән ел әйләнәсе төрле сәяхәтләргә баралар – Казан, Болгар, Свияжск... Берсе дә калмаган.

Ә сарык йонының файдасын сынап карарга киңәш итәм! Халык белми әйтмәс...

ЭШ БАРЫШЫ:

- йонны язарга;
- кабага куеп эрләргә;
- ике орчыкны бергә йомгакка чорнарга;
- катарга;
- аякка чорнарга;
- юарга;
- йомгакка чорнарга.

Әзер! Хәзер инде җылы оекбаш, башмаклар бәйләргә дә була!

2020 ЕЛ ЙОМГАКЛАРЫ

ТОП-10 РФнең ГАМӘЛГӘ АШЫРЫЛГАН ПРОЕКТЛАРЫ

«ПРОЕКТ РОССИЯ» ЖУРНАЛЫ ВЕРСИЯСЕ БУЕНЧА

«ТОЧКА НА КАРТЕ» ШӘҺӘР ЯНЫ КУНАКХАНӘСЕ

ВИДЛИЦЕ, КАРЕЛИЯ

Абруйлы басма экспертлары фикеренчә, каядыр еракта Карелиядә тормышка ашырылган экологик архитектура үрнәгенең елның абсолют лидеры булып танылуы очраклы хәл түгел. Бу күпмедер мәгънәдә замана билгесе. Оригиналь кунакханә – үзизоляция һәм читтән торып эшләү күзлегеннән караганда иң шәп урын.

ANTIPA КАФЕСЫ

МӘСКӘҮ

А.С.Пушкин исемендәге Дәүләт сынлы сәнгать музее янәшәсендәге Колымажный тыкрыгында пәйда булган кечкенә генә кафе – Изге газап чигүче Антип Пергамский храмы территориясендә озак еллар таушалган килеш торган хуҗалык корылмасын яңарту нәтиҗәсе. Басманың халыкара жюрие архитекторларның әлеге хезмәтен соңгы өч елда пәйда булган 30 иң яхшы реновация проекты исәбенә кертте.



FOSTER CINEMA КИНОТЕАТР-РЕСТОРАНЫ

МӘСКӘҮ

Мәдәният белән туклану тигез дәрәҗәдә кулланыла торган заманча гибрид киңлекләргә иң яхшы үрнәк бу. Әмма әлеге очракта тегесе дә, бусы да өстәмә рәвештә Hi-End-эстетика белән тулыландырылган, дип саный экспертлар. Аның элементлары артефактлар җыелмасы буларак түгел, бәлки, турыдан-туры йогынтысын сизәрлек һәм уңайлы шартларда кулланырлык итеп бирелгән. Сүз уңаеннан, киносеанслар биредә – бәхәсләр, ә романтик кичке ашлар кичәләр белән чиратлашып бара.

«НИЖЕГОРОДСКАЯ» ТРАНСПОРТ-КҮЧЕП УТЫРУ ТӨЕНЕ

МӘСКӘҮ

Әлеге объектны басма экспертлары тыйнак кына Россия башкаласы транспорт сәясәтенең символы һәм вакыт билгесе дип атадылар. Яңа төзелгән транспорт-күчеп утыру төене Европада иң эресе санала, ул метроның Некрасовская һәм Зур боҗра линияләренең «Нижегородская» станцияләрен, Мәскәү үзәк боҗрасының шул ук исемдәге станциясен, Горький тимер юлының (МЦД-3) Карачарово платформасын һәм җир өсте транспорты тукталышларын бер түбә астына берләштерде. Пандемия котырган вакытта ачылган «Нижегородская» күчеп утыру төене Мәскәү архитектура премиясен дә яуларга өлгерде. Әлеге премия 2020 елда транспорт объектлары номинациясендә беренче мәртәбә тапшырылды.

NORDIC SPA
ЯНТАРНЫЙ,
КАЛИНИНГРАД ӨЛКӘСЕ

Балтыйк диңгезе яры буенда, комлы дюналар һәм наратлар кочагында төзелгән SPA-үзәкнең архитектура ягыннан бизәлешенә экспертлар бик кыска бәя бирә: күп сөйләми торган югары дәрәҗәдәге архитектура. Моннан да яхшырак итеп әйтү мөмкин түгелдер. Проект авторлары иң мөһим нәрсәне тормышка ашыра алган – табигать үзенең кочагына әлеге объектны сеңдерүен сизми дә. Ә илебез картасында тагын бер идеаль ял итү урыны пәйда була.

«ТАТНЕФТЬ» ШТАБ-КВАРТИРАСЫ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ ҮЗӘГЕ
ӘЛМӘТ, ТАТАРСТАН

Жюри тарафыннан әлеге проект «ре»га (реновация, реконструкция, яңарту...) багышланган проектлар арасында иң яхшысы дип табыла. «Ре» биредә, ким дигәндә, өчәү, дип аңлата экспертлар. Нефть башкаласында әле 1970 нче елларда ук төзелгән модернистик калыптагы универмаг – яңартылганнан соң уникаль иҗтимагый-мәдәни үзәккә, 2000 нче елларда салынган капром (капиталистик романтизм) рухындагы типлаштырылган «шәм» – заманча офиска, ә ике бинаны уратып алган территория яңа иҗтимагый киңлеккә әверелә.

«АРТ-КВАДРАТ» ШӘҺӘР ҮЗӘГЕ
УФА, БАШКОРТОСТАН

Экспертларның фикере: әлеге объект – ел ачышы. ARTPLAY, FLACON һәм «Стрелки»ларның үзенчәлекле кушылмасы, бер үк вакытта белем бирү, күңел ачу киңлеге дә. Бары тик биш квартал – «квадрат»та утар, XIX һәм XX гасырларның яңартылган фабрикалары, конструктивизм, диңгез контейнерлары һәм заманча сәнгатьнең ни рәвешле бергә ярашуын карар өчен генә дә Башкортостанның башкаласына барырга була.



COTE ROCHEUSE
КРАСНОДАР КРАЕ

Чыннан да дөнья белән тамак идарә итә. Туры мәгънәсендә. Һәрхәлдә, безнең лауреатыбыз – романтик исемгә ия «Скалистый берег» шәраб ясау предприятиесе үзенең пәйда булуы белән архитектур-гастрономик юнәлешнең көчәюенә бурычлы. Мондый агым Италия, Испания яисә Франциядә генә түгел, Краснодар краенда да киң танылган. Җитмәсә хәзерге вакытта карарлык һәм тәмен татып карарлык продуктларыбыз да бар: Геленджик һәм Анапа шәһәрләре тирәсендәге виноград кырлары янәшәсендә шәраб ясау компанияләре дә үсеп чыга, аларны туристлар өчен бөтен шартлар тудырылган инфраструктура тулыландыра. Үзенең бетон һәм пыяладан торган тышкы кыяфәте белән экспертларны әсир иткән «Скалистый берег» шәраб ясау предприятиесе төзелде генә әле, язга ул халык өчен ачылачак.

КАЗАНДА КАБАН КҮЛЛӘРЕ ЯР БУЙЛАРЫН ТӨЗЕКЛӘНДЕРҮ, 2 НЧЕ ЧИРАТ
ТАТАРСТАН

«Суда агач сукмак салынган һәм спортның ишкәкле төрләре өчен күнегүләр базасы» да булган Кабан күле яр буйлары җәй ахырында халык өчен ачылды. Яр буеның әлеге өлеше Татарстанның башкаласындагы Түбән Кабан күлендә тормышка ашырылган кыю, күләмле һәм күп яктан уникаль проектның икенче чираты булды, дип аңлата экспертлар. Казандагы Түбән Кабан күленең беренче өлеше моннан ике ел элек Turenscar Кытай бюросы проекты буенча төзекләндерелгән иде инде. Ул, сүз уңаеннан, 2019 елда «Проект Россия» Ел премиясендә «Ел экопроекты» номинациясе буенча дипломга ия булды.

ТӨП ТУРИСТЛЫК КОМПЛЕКСЫН ЯҢАРТУ
СУЗДАЛЬ, ВЛАДИМИР ӨЛКӘСЕ

Суздальдәге туристлык комплексының беренчел, әллә кайчан төзелгән кыяфәтен бүген «Чародеи» дип аталган иске совет фильмында гына күрергә мөмкиндер. Кайчандыр зурлыгы буенча аңа тиңнәр булмаган. Ә бүген, дистәләрчә ел үткәннән соң, комплекс янәдән яшәрде, заманчаланды. Самовар һәм корама одеяллар белән бизәлгән совет модернизмын тагын кайда табып була икән?

«Проект Россия» – РФндә архитектура, шәһәр төзелеше, төзелеш технологияләре һәм дизайн буенча профессиональ журнал, рус һәм инглиз телләрендә басыла. Россиядә, БДБ илләрендә, ерак чит илләрдә таратыла.

Фото ТР Президенты сайтыннан)

ТОП-10 ТУРИЗМ БУЕНЧА МИЛЛИ РЕЙТИНГ – 2020

Туризм буенча милли рейтинг – ел саен уздырыла торган тикшеренү. Ул туризмга багышланган «Отдых в России» журналы тарафыннан «Рейтинг» Мәгълүмати коммуникацияләр үзәге белән берлектә әзерләнә. Туризмның үсешенә, Россия төбәкләренең туристларны җәлеп итү ягыннан әзерлегенә, аларның туристлык потенциалына, төбәкнең илебез һәм чит ил туристлары арасындагы популярлыгына бәя бирелә. «Алтын егермелек» – рейтингның беренче төркемендә 1-20 нче урыннар алган төбәкләр урнашкан.

МӨҺИМ

«Рейтинг» МКҮ эшчәнлеге принципларына ярашлы рәвештә тикшеренүдә экспертлар – бу очракта «Отдых в России» медиатөркеме белгечләренең фикерләре һәм бәяләмәләре исәпкә алына. Медиатөркемгә туризмга багышланган «Отдых в России» журналы һәм сайты, берничә туристлык сайты, инглиз телле аудитория өчен басыла торган Tourism & Leisure in Russia ялтыравыклы журналы һәм сайты керә.

119,4 балл

МӘСКӘҮ ӨЛКӘСЕ

118,7 балл

ФЕДЕРАЛЬ ӘҺӘМИЯТТӘГЕ МӘСКӘҮ ШӘҺӘРЕ

118,4 балл

ФЕДЕРАЛЬ ӘҺӘМИЯТТӘГЕ САНКТ-ПЕТЕРБУРГ ШӘҺӘРЕ

118,1 балл

КРАСНОДАР КРАЕ

114,5 балл

КЫРЫМ РЕСПУБЛИКАСЫ

РЕЙТИНГ ТУРЫНДА

2019 – 2020 еллар буенча ачык чыганакларны һәм ведомство статистикасын анализлау нигезендә һәр күрсәткеч буенча 15 таблица әзерләнә. Һәр таблицадагы беренче урын 8,5 балл бирә. Калган һәр урын өчен 0,1 балл алына. Шулай итеп, эксперт бәяләмәләре исәпкә алынган, баллар суммасы буенча Туризм буенча милли рейтингның лидерлары һәм аутсайдерлары билгеләнгән 15 таблица җыелма таблицаны барлыкка китерә.

МӨҺИМ

Россия төбәкләренең туристлык тармагы үсешенә, аларның туристларны җәлеп итү ягыннан әзерлегенә, туристлык потенциалына, төбәкнең илебез һәм чит ил туристлары арасындагы популярлыгына бәя биргәндә түбәндәгеләр исәпкә алына:

- Төбәкнең туристлык тармагы һәм кунакханә инфраструктурасы үсеше дәрәҗәсе
- Туристлык һәм кунакчыллык тармагының кереме, аның төбәк икътисадына керткән өлеше
- Төбәкнең шифаханә-курортлар тармагының үсеше: шифаханә-курортлар оешмалары тарафыннан күрсәтелгән түләүле хезмәтләрнең күләме
- Бернчә көнгә килүче туристлар арасында төбәкләрнең популярлыгы
- Чит ил туристлары арасында төбәкнең популярлыгы: коллектив урнаштыру урыннарында урын алган чит ил гражданнары саны
- Төбәкнең туристлык ягыннан уникальлеге һәм җәлеп итүчәнлеге
- Төбәктә җинаятьчелек дәрәҗәсе: 100 мең кешегә исәпләгәндә кылынган җинаятьләр саны
- Ял итү урыны буларак интернетта төбәк белән кызыксыну дәрәҗәсе: төбәктә ял итү турында эзләү системаларында сорауларның саны
- Мәгълүмат киңлегендә төбәкнең туристлык потенциалын алга этәрү: ММЧларында төбәк исеме аталган язмаларның һәм хәбәрләрнең саны

108,6 балл

АЛТАЙ КРАЕ

105,2 балл

ПРИМОРЬЕ КРАЕ

105,1 балл

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

100,7 балл

БАШКОРТОСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

98,7 балл



СВЕРДЛОВСК ӨЛКӘСЕ

КУКМАРА РАЙОНЫНЫҢ ПОЧИНОК-КУЧУК АВЫЛЫ. МАРИЛАРНЫҢ ШОРЫКЙОЛ ДИГӘН ЙОЛА БӘЙРӘМЕ.

Авторы: Алсу Троицкая

Турист – ул кунак

Кайчакта тормышта шулай да була, кечкенә генә җирле бәйрәмнәр үзләренең киң күләмле «туганнары» кебек үк кәттә, кай ягы беләндер хәтта алардан да үзенчәлеклерәк вакыйгага әверелеп китә. Әйтик, мариларның Шорыкйол бәйрәмен генә алыйк, тамырлары белән ул бик тирәнгә китә. Аны гыйнвар башында билгеләп үтәләр, асылы һәм мәгънәсе белән ул христианнарның святки йоласына бик якын.

АЯГЫҢ ТӘПЕЛДӘМӘСӘ, АВЫЗЫҢ ЧӘПЕЛДӘМИ

Починок-Кучук авыл җирлегендә шамакайлар киеменнән өйдән-өйгә йөрү гадәте беркайчан да юкка чыкмаган – хәтта коммунистик совет чорында да.

– Кем әйтмешли, бәйрәм итү – эш эшләү түгел. Иң кыены һәрвакыт святки алды атнасы иде, – дип искә ала «Кна вел» мари халык фольклор ансамбле солисткасы Людмила Зәбирова. – Ничек әзерләнүебезне балачактан башлап хәтерлим. Хатын-кызлар йортны һәм ишегалларын җыештыра, барысын да тәртипкә китерә. Ирләр барлык хуҗалык кирәк-ярагын тикшереп чыга, балыкчылар балык тоту җайланмаларын карый-төзәтә – яңа елга төзек булмаган әйберләр белән керергә ярамый. Барысы бергә бакчадагы агач һәм куакларнын ботакларын җайлый, көртләрне өеп куя – монысы булачак уңыш өчен. Ә бәйрәм үзе мари теленнән «сарык аягы» дип тәрҗемә ителә, шуңа күрә, яңа елда нәселе артсын өчен, сарыкларның аягын тарту гадәте бар. Кыскасы, святки алды атнасында хәлдән тайганчы эшләп, үзең «аяксыз каласың»...

Бәйрәм табынына куела торган ризык дөрес тукланучылар өчен каралмаган. Монда сиңа пилмән дә, койка да, аш та, коймак та һәм, әлбәттә инде, тәм-том да бар...

КӨТЕЛГӘН КӨТЕЛМӘГӘННӘР

Ишекләрне дөбердәтеп кагалар. Ишегалдындагы шамакайлар төркеме бар тавышына: «Шорыкйол!!!» – дип кычкыра. Күңелле агым белән Кыш Бабайның мари туганы Васли кугузя (Василий бабай) һәм аның карчыгы Васли Куба җитәкчелек итә. Ак сакаллы Василий бабайның авыл Мәдәният йорты директоры Геннадий Пет-

Фотоларны Кукмара муниципаль районы башкарма комитеты тәкдим итте

ров, ә аның маскарад күзлеге кигән юлдашының Людмила Зәбирова икәнен танып алабыз.

Яхшы һәм яман рухларны чагылдыручы чуар киемле шамакайлар килүгә йорт хуҗалары тиешенчә әзерләнгән. Үзләренең хуҗалык уңышлары турында ишегалдына элеп куелган каз-үрдәк-тавык түшкәләре, йоннан бәйләнгән әйберләр, бай табын, юмарт сый-хөрмәт белән «хисап бирәләр». Өстәлдә самавыр кайнап утыра, төрле бәлешләр, тәм-томнар тау кебек өелгән. Бакчада биек кар көртләре – алары яңа елда мул уңыш өмет итү билгесе.

Бу ишегалдыннан Василий бабай шамакайлары тамаклары туеп, канәгать булып, «Кум пача! Кум пача! Кум пача!» – дип кабатлый-кабатлый чыгып китә, тәрҗемә иткәндә «Өч бәрән! Өч бәрән! Өч бәрән!» – дигән сүз була инде. Әгәр хуҗалар юмарт булмаса һәм, Аллаһ сакласын, эшләргә дә яратмаса, шамакайлар аларга бер генә бәрән теләр иде. Әгәр инде бу йортны әйләнеп үтәләр икән, бусы бөтенләй яман билге. Шамакайларны кертмәүчеләр дә була. Элек, урамга чыга алмасыннар дип, андыйларның капка төпләренә кар өеп киткәннәр. Хәзер инде, билгеле, алай эшләп тормыйлар. Үзара килешеп, кызык өчен эшләсәләр генә инде...

Һәр яңа йорт, һәр ишегалдын үткән саен шамакайлар саны яңа персонажлар хисабына арта бара, һәм әлеге агым берничә дистә метрга сузыла.

Быел марилар янына республиканың Әгерҗе, Арча районыннан, Удмуртия, Киров өлкәсе, Мәскәү, Мари Элдан да кунаклар килде.

Шамакайлар һәм кунакларның җырлар, биюләр, уеннар белән авылның үзәк урамы буйлап узуы бәйрәмнең кульминациясен тәшкил итте.

СВЯТКИ ЮРАУЛАРЫ

Шорыкйол вакыты – бу әле төрле юраукүрәзәләр, «марича святки» вакыты да.

Сарыклары булган хуҗалыкта кәләш яшендәге кызлар булачак кияүләрен юрый алганнар. Барысы да бик гади һәм күңелле: караңгыда абзарга керәсең дә бер сарыкны аягыннан эләктерәсең. Кайсы эләксә, киявең дә шундый булачак. Яшь, ак, кара. Ә инде аксагы яисә бик арыгы эләксә – беркемгә дә үпкәли алмыйсың.

Юрау кәртләре урынына киез итек тә ярап тора. Ишегалдыннан тышка ыргытасың: ул кайсы якка карап төшә, кияүне яисә кәләшне шул яктан көтәсе.

Кемгә юралганыңны ачыклауның тагын бер чарасы: тавык кетәклегенә берничә савыт куясың да, шунда этәч кертеп җибәрәсең. Кайсын сайлар? Иген бөртекләре салынган савыт – бай кияүгә чыгасың, күмерлесе – гомер буе фәкыйрьлек йөген тартасы, сулы савыт – ирең эчкече булачак.

Әлеге кышкы бәйрәмдә булганнан соң, «Татарстан» тагын бер кат шуңа инанды: безнең республикада туристларны җәлеп итәрлек территория булдыру өчен зур потенциал бар. Бөтенләй башка төрле халыкларның гаҗәеп мәдәнияте, кунакчыл кешеләр, искиткеч матур җирлек һәм табигать, брендлы һөнәрләр. Калганы – безнең кулларда...

МАРИ МӘДӘНИЯТЕНӘ ЧУМАРГА ГАРАНТИЯ БАР

Төрле тәм-томнар белән рәхәтләнеп сыйлангач, җырлап-биеп аргач, бәйрәмгә күпме кеше җыелганын санап чыгарырга тырышабыз. Йөз илледән артып киткәч, бу эшебезне ташлап, традицион мари дине карты*, «Кна вел» мари фольклор ансамбле җитәкчесе һәм, гомумән, биредәге абруйлы кеше Леонид Искаковка мөрәҗәгать итәбез.

– Әгәр сезгә туристлар килсә, сез шат булыр идегезме?

– Бүгенге көндә бар кешенең дә сәяхәт итү мөмкинлеге юк. Һәм без үз бәйрәмнәребез һәм фестивальләребез турында күпме генә сөйләсәк тә, янчыкларда акча барлыкка килмәсә, Россиядә эчке туризмның гөрләп күтәреләсен көтәсе юк. Әмма без, әлбәттә, кунакларга һәрвакыт шат. Бездә ел саен Шарыкйолга халык күп җыела. Менә бу бәйрәмне генә алыйк, без бит берәүне дә мәҗбүриләп чакырмадык, ә шулай да күрше районнардан да, Киров өлкәсеннән дә, Удмуртиядән дә, Мари Элдан да килделәр.

Күпме килсәләр дә, барысын да сыйлыйбыз, кирәк булса, кунар урын да табабыз. Менә узган елның алдагысында безгә, дөрес, җәй көне, Эстониядән 28 кеше килде. Алар безнең милли гореф-гадәтләр белән генә кызыксынып калмадылар, традицион мари дине турында да белергә теләделәр. Без аларның барысын урнаштырдык. Кич белән берләштерелгән зур концерт оештырдык. Соңыннан, бездән киткәч тә, күп тапкырлар шалтыратып тордылар, тагын күбрәк халык белән безнең якларга кабат килеп чыгарга вәгъдә бирделәр. Тик, үзегез беләсез, пандемия... Сез әллә безгә нииндидер үзенчәлекле гастрономия яисә туристик трендлар өчен киләләр, дип уйлыйсызмы? Юк! Аларны аутентик телне, фольклорны, гореф-гадәтләрне саклаучылар җәлеп итә. Традицион мари диненә инде берничә мең ел,һәм без йолаларның күпчелеген бүгенгәчә саклап кала алдык. Нәкъ менә шул аларны бирегә җәлеп итә.

Әйе, мари мәдәниятенә чумарга, барабан һәм волынканы тыңларга, дәртле биюләрне күрергә теләүчеләр өчен иң зур минус – бирәдә кунакханәләрнең булмавы. Әмма туристларны урнаштыру мәсьәләсе быел җәй көне хәл ителәчәк инде. Починок-Кучук авыл җирлегендәге Синерь авылында чын мари утары төзелеп килә – кунак йорты, кара мунчасы, амбарлары белән. Анда балык тотарлык буа да, традицион мари кухнясы да, изге әрәмәгә экскурсия дә булачак...

– Гомумән, мари мәдәнияте һәм аның борынгы көнкүреше мохитенә чумуны гарантиялибез, – ди Леонид Искаков, гармунын кочаклап. – Сезнең моннан китәсегез дә килмәс, чөнки туристлар безнең өчен туристлар гына түгел, ә чып-чын кунаклар!

*Карт – мариларның традицион динендәге жрец.

PRESSA

Фото: Александр Ефремов

ҖИРДӘГЕ ИҢ ШӘП УРЫН!

ӘЛКИ РАЙОНЫ:
ЭКСКУРСИЯНЕ БАШЛЫК ҮЗЕ УЗДЫРА

Үз районы турында аның башлыгыннан да яхшырак белүче бармы? Әлбәттә, юк! Район башлыгы бу җирдә туып-үскән булса бигрәк тә! Нәкъ менә Александр Никошин кебек. Без килгән көнне Әлки җирен туңдырган-катырган 38 градуслы салкынны бар дип тә белми ул.

– Аның каравы, күрегез әле, нинди матурлык! – дип, үз биләмәләренә ишарәли район башлыгы һәм безне экскурсиягә дәшә.

«Берәүләргә – салкын
кар бөртеге,
Берәүләргә – йолдыз, энҗеләр!
Карны кар дип белгән
син акыллы,
Ак чәчәкләр күрәм мин юләр...»

Саҗидә Сөләйманованың без хәзер искә алган шигырь юллары әйтерсең лә «Татарстан» журналының ҖИРДӘГЕ ИҢ ШӘП УРЫН – Әлки районында үткәргән менә шушы кояшлы суык көне хакында язылган иде.

– Бездә искиткеч урыннар күп, әмма **ИҢ ЯРАТКАН УРЫНЫМ –** үзебезнең бассейн. Милли проектлар программасы буенча төзелде ул. Аның нәкъ менә бездә төзелүендә – Президентыбыз Рөстәм Миңнехановның һәм ватерполочы, Олимпия уеннары призеры, әүвәлрәк Дәүләт Думасы депутаты да булып алган Ирек Зиннуровның тырышлыгы гаять зур.

Хәзер яшьләребез монда бик зур нәтиҗәләргә ирешәләр! Күптән түгел генә биредә су тубы буенча башта яшүсмер егетләр, аннары кызлар арасында Россия чемпионаты узды – илебезнең барлык төбәкләреннән яшь спортчылар килде. Авылда булып авылда мондый дәрәҗәдәге чемпионат кайчан үткәрелер иде әле?! Беркайчан да. Ә хәзер бу – **ТИҢЕ ЮК УРЫН.**



Әгәр районыгызга башка төбәктән турист яки берәр чит ил кешесе килә икән, аңа беренче чиратта нәрсә күрсәтерсез, дип еш сорыйлар миннән? **КОСМОНАВТИКА МУЗЕЕН, әлбәттә!** Базарлы Матакта каян килеп космонавтлар булсын инде? Ә менә барыйк әле, барысын да үзегез белерсез!

Бездәге космонавтиканың тамырлары... сәүдәгәрлеккә тоташа. Әйе-әйе... Сәүдәгәр Сергей Михайлович Лисенков революциядән соң Базарлы Матакта бөтен байлыкларын ташлап калдырып, гаиләсе белән – Себергә, соңыннан Америкага кача. Ә XXI гасырда аның оныгының улы – АКШ гражданы, «Аэроджет» компаниясенең Россия вәкиллеге башлыгы Анатолий Михеев, Базарлы Матакка килеп, үз нәселенең күчемсез милеген туган як тарихын өйрәнү музеена тапшырды. Өстәвенә, музейны «космик» шефлыкка да алды. Чөнки сәүдәгәр нәселе дәвамчысының эше космос өлкәсе белән бәйле. Ул бирегә дусларын – Советлар Союзы Геройлары очучы-космонавт Александр Баландин белән Муса Манаровны алып килде. Алар музейга бер кочак бүләк тапшырды, әнә шул «галәм сәяхәте» экспонатларыннан, скафандрлар, космонавтлар ризыкларыннан тиңсез космос экспозициясе барлыкка килде дә. Анда Әлки районы гербы төшерелгән кечкенә флаг та бар әле, ул галәм гизеп кайтты, шуны раслап, космик мөһер дә сугылган.

Хәзер республикабыз гастротуризмны да үстерү юнәлешендә эшли. Һәр район үзенә генә хас ризык белән шаккатыра ала. Ризык ягыннан мактанычыбыз – бәлеш, Юхмачы чәкчәге һәм Түбән Әлкидәге «Яшь Көч» тутырмасы, аны Карга авылында да бик тәмле эшлиләр әле. Әгәр дә районнан читкә кунакка барсак, Казангамы, Ульяновскигамы, Мәскәүгәме – **ТЕГЕ ЧӘКЧӘГЕГЕЗНЕ генә** алып килегез, диләр. Чәкчәкне бөтен җирдә пешерәләр, тик бездәге кебеге беркайда да юк!

Төрле районда – төрле кешеләр. Кайдадыр шаяннар күп, кайдадыр спортны аеруча үз итәләр, ә **әлкиләләр – ТЫРЫШ ХЕЗМӘТ КЕШЕЛӘРЕ**. Алар үз хезмәтләре белән авылны юкка чыгудан саклый, моның өчен аларның барысына да: комбайнчыларга да, фермерларга да, сыер савучыларга да, җирлек башлыкларына да хөрмәт белән баш иябез... Соңгы 3 елда гына да 120 дән артык кече шәхси хуҗалык теркәлде. Авылларда мондый кече фермалар күбрәк булган саен, алар авылны, шәһәрне, илне шулкадәр күбрәк туендырып-ашатып тора алачак. Бу – бик зур хезмәт, әлбәттә.

Авылны саклау эшендә **ЯКТАШЛАРЫБЫЗ ЯРДӘМЕН ДӘ** тоябыз. Айрат Хәйруллин ярдәме белән Әлки авыл хуҗалыгы районына әйләнде. Иван Казанков тырышлыгы белән Хузангай авылы елдан-ел үсә, алга бара. Биш ел элек биредә тигез ялан иде, ә хәзер монда 3000 баш савым сыерына исәпләнгән комплекслар калкып чыкты, мөгезле эре терлекнең барлык баш саны 5000 гә җитә. Без инде 20 тонна сөт савабыз. Һәм моңа 5 ел эчендә ирештек! Бу – зур сан. Быелтыр Президентка сөт эшкәртү заводын күрсәттек, анда 7 төр сыр һәм май ясыйбыз. Алар бөтен ил буенча сатыла, хәзер хуҗалыкның 760 кибете бар. Хузангайда яңа җиһазда 8 төр ярма җитештерәләр, май төрәләр.

Абыйлы-энеле Шәйхетдиновларның кабул итү пункты сөт сатып ала, бәяләре яхшы. Әлки сөтен генә түгел, Чаллы, Лениногорск, Чирмешәннекен дә җыялар. Аны суытып, бөтен ил буйлап тараталар. Продукцияне бөтен ил буйлап китереп бирә алуыбыз белән дә горурланабыз.

Һәр якташыбыз туган җирен үстерүгә өлеш кертә. Кемдер – акчалата, кемдер – киңәше белән, кемдер төрле кичә-бәйрәмнәр үткәреп. Һәр авылда якташлар нәрсә дә булса эшләргә тырыша. Әйтик, Бөек Җиңүнең 75 еллыгына, диңгезчеләргә, чик сакчыларына, десантчыларга багышланган һәйкәлләр...

Абыйлы-энеле Шәйхетдиновлар былтыр әтиләренең туган ягы – Татар Борнае авылында мәчет төзеде. Казанков Хузангайда искиткеч гыйбадәтханә салдырды...







Барлык торак пунктларыбыз яшеллеккә күмелеп утырсын иде. Урман эчендәге шәһәр яки шәһәрдәге урман кебек. **Сез ПАРКЛАРЫБЫЗНЫ күреп китәргә тиеш.** Бездә дүрт парк бар һәм алар шундый итеп урнашкан, машина белән барасы түгел. Өйдән чыгуга – парк. Ана даны паркы, Үзәк парк, Тыл хезмәтчәннәре паркы, Геройлар паркы. Быел чаңгы базасы булдыру юнәлешендә эш башлыйбыз, биредә дә парк ясалачак. Анда ике чакрымга якын яктыртылган чаңгы юлы булачак...



– Әлки районы башлыгын нәрсә борчый? Сезнеңчә, хәзерге заманда ни сәбәпле чын-чынлап кәеф кырылырга мөмкин? Ни-нәрсәне бәхетсезлек дип атарга була?

– Мине халыкның авылдан шәһәргә китүе борчый. Яшьләр аз. Үлүчеләр саны да туучылар санынннан артып китә. Бу хакта уйланырга кирәк. Ә калганы, минемчә, кешенең үзеннән тора. Мин гел әйтә киләм: көтүдә сарыкның агы да, карасы да бар. Һәр авылда һәрвакыт шундый берәү табыла: ул һичнәрсәдән канәгать түгел, аңа гел шикаять язарга, зарланырга булсын. Һәркемгә ярарга тырышу кирәкми дә. Моның өчен яшәмибез бит. Без яхшы, игелекле эшләр башкарырга тиеш. Кешеләрнең күпчелеге яхшы күңелле ул. Шөкер итеп торучылар барыбер күпчелекне тәшкил итә. Ремонтланган клуб, яңа салынган юл өчен рәхмәт белдерәләр... Авыл халкы белән беренче очрашуларыбызны искә алам. 2006 елда Карга авылында халык җыелган иде һәм шунда бер бабай: «Барысы да әйбәтләнеп бара, ә минә интернет юк!» – ди. Без ул чакта көлдек кенә. Ә хәзер бу – көнүзәк мәсьәлә. Бүген интернетсыз мөмкин түгел. Без махсус вышкалар куябыз, алга барабыз. Мәктәпләргә интернет кергән – монда инде, ни дисәк тә, коронавируска рәхмәт әйтергә кирәк. Әмма интернетны кечкенә, хәтта 100 хуҗалыгы да булмаган авыллар да сорый. Интернет шәһәрдән туеп авылга кайтучыларга да кирәк. Бик аз гына процент булса да, андыйлары да бар.

– Әлки районы башлыгы ни белән горурлана?

– Хәзер районда һәр торак пунктка кадәр юллар булуы белән. 2016 елда «Алексеевскдорстрой» ААҖ директорлар советы рәисе Фоат Вәли улы Вәлиев, әйдәгез әле, Яңа Әнҗерәдә безнең ниләр эшләгәнне Президентыбызга күрсәтик, дип тәкъдим итте. Авылны торгыздык. Күлне чистарттык, юл салдык. Президентны алып килгәч, ул авылның нибары 20 хуҗалык икәнен күрде. Әмма анда клуб, һәйкәл, спорт мәйданчыгы бар, күл буйлары чистартылган, матурланган. Һәм Рөстәм Нургалиевич: «Кая ул фермер? Аның нинди проблемалары бар? Ничек ярдәм итәргә?» – дип сораша башлады. Ә анда абыйлы-энеле Гобәйдуллиннар яши – хезмәт сөючән егетләр. Аларга трактор кирәк иде. «Трактор мәсьәләсен хәл итәргә кирәк», – диде Президент. Тракторны шунда ук бирделәр. Хәзер бу авылның, әйтерсең, икенче сулышы ачылды – әллә ничә йорт салдылар!

– Әлки районы башлыгы ни турында хыяллана?

– «Алтын үзән»не эшләтеп җибәрергә хыялланам. Сәнәгать мәйданчыгы турында әйтүем. Һәр авылда тормыш лаеклы һәм матур, эш урыннары күбрәк булсын иде дип хыялланам. Ике корпус бар инде. Яңа елга эшләтеп җибәрергә теләгән идек, әмма бу коронавирус аркасында... Анда якынча 50 мең башка исәпләнгән үрдәк фермасы булачак. Урман эшкәртү планлаштырыла. Бетон заводы. Җәй көне инде ача башларбыз дип уйлыйм.

Тагын бер хыял... Актай елгасы Матакны икегә бүлә. Мин шул тирәне матурлау теләге белән һәрвакыт янып йөрдем. Хәзер бу хыял да тормышка ашырыла – Президент безгә 26 млн сум бүлеп бирде. Елганы чистартырга, тирәнәйтергә, ярларны ныгытырга, пляж ясарга телибез...

facebook.com/protatarstan

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

twitter.com/protatarstan

instagram.com/protatarstan

Реклама 16+

БЕЗНЕҢ ТӨРКЕМНӘРГӘ РӘХИМ ИТЕГЕЗ!

Мәңгелек кыйммәтләр/

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

Бу санда тәкъдим итәбез:

Татарстанда КҮПМЕ ир-ат үзен өйләнгән дип саный

Геройларны КЕМ тәрбияли

Фәйзулла Туишев гармуннары КАЙДА саклана

Кызыл Байрак КАЙСЫ ягы белән күренекле

ТАТАРСТАН ИР-АТЛАРЫ САННАРДА

Февраль – ир-атлар ае, кырыс ай, батырлар ае! Безгә читтән килеп кергән бернинди Гашыйклар көне дә аның ямен җуйдыра алмый. Чөнки бу ай бүләкләре кыю затлар – ЧЫН ИР-АТЛАРГА аталган.

Үзенең 100 еллык гомере дәвамында «Татарстан» журналы ирләрнең ниндиләре турында гына язмады:

ИҢ ЯШЬЛӘРЕ турында да...
ИҢ БУЛДЫКЛЫЛАРЫ турында да...
ИҢ ҖИТЕЗЛӘРЕ турында да...
ИҢ КЫЮЛАРЫ турында да...
ҮЗ ГОМЕРЛӘРЕН БАЛАЛАР ТӘРБИЯЛӘҮГӘ БАГЫШЛАГАН ЧЫН АТАЛАР турында да...

Шулай ук «Татарстан» **ИР-АТЛАРЫБЫЗНЫҢ НӘРСӘ ТУРЫНДА СӨЙЛӘҮЛӘРЕ** турында да язды.

НӘРСӘ ТУРЫНДА ХЫЯЛЛАНУЛАРЫ турында да.

Хәтта дүрт аяклы дусларыбыз – холыклары һәм һөнәрләре буенча ирләр булган хәрби, сугышчан, эзләнү эшләрендә катнаша торган **ЭТЛӘР ТУРЫНДА** да язды...

Моннан тыш, «Редакция кухнясы» рубрикасында Татарстан ир-атлары барыбызны да тәмледән-тәмле ризыклар белән сыйлады.

Гомумән, «Татарстан» журналының февраль саны һәрвакытта да үзенең кызыклы, бәйрәмчә булуы белән аерылып торды.

Быелгы февраль «Татарстан»да шулай ук үзенчәлекле. Саннарга бай. Статистикага бай. Мәгълүматы белән гаҗәпләндерә торган.

Бүген сез түбәндәгеләрне белерсез:
– Татарстанда **КҮПМЕ** ир-ат яши...
– **НИ ӨЧЕН** алар сан ягыннан хатын-кызларга караганда кимрәк...
– Авылда яшәүче ир-атлар (25тән 55 яшькә кадәр) шәһәрлеләргә караганда **КҮПМЕГӘ** артыграк...
– **НИ ӨЧЕН** 8 Мартта ир-атларның акча янчыгын бушатудан кыенсынмаска кирәк...
– Өйләнгән, аерылган һәм буйдак ир-атлар **КҮПМЕ**...
– **КҮПМЕ** ир-ат үзенең гаилә хәлен яшерә...

Татарстанстаттан тулы мәгълүмат! Исемнәре яшерен кешеләрдән шәрехләүләр белән бергә.





САНЫ ҺӘМ ЯШЬ ТУРЫНДА:

Татарстанда
1 808 637 ир-ат яши

Татарстанда
2 094 251 хатын-кыз яши

Шулардан:
1 368 970е – шәһәрдә
439 667се – авылда

Шәһәрдә ирләр хатын-кызларга караганда 26,5 меңгә АЗРАК
Авылда ирләр хатын-кызларга караганда 21 меңгә АЗРАК

Малайлар кызларга караганда **1026 га** күбрәк туа
Шәһәрдә малайлар кызларга караганда **871 гә** күбрәк туа
Авылда малайлар кызларга караганда **155кә** күбрәк туа

25 яшьлекләр арасында шәһәрдә яшәүче ир-атлар хатын-кызларга караганда күбрәк

25–55 яшьлекләр арасында авылда яшәүче ир-атлар хатын-кызларга караганда күбрәк

БҮЛӘКЛӘР ҺӘМ ХЕЗМӘТ ХАКЛАРЫ ТУРЫНДА:

44 238 сум –
Татарстанда ир-атларның уртача хезмәт хакы

31 773 сум –
Татарстанда хатын-кызларның уртача хезмәт хакы



Ирләрнең уртача хезмәт хакы хатын-кызларның уртача хезмәт хакыннан **12 465 сумга АРТЫГРАК**

Ир-ат җитәкчеләрнең хезмәт хакы хатын-кыз җитәкчеләрнекенә караганда **26 650 сумга КҮБРӘК**

Урта баскычтагы ир-ат белгечләрнең хезмәт хакы шул ук эшне башкарган хатын-кызларныкына караганда **20 443 сумга КҮБРӘК**

Сак хезмәтендә эшләүче ир-атларның хезмәт хакы шул ук эшне сайлаган хатын-кызларныкына караганда **8256 сумга КҮБРӘК**

Авыл, урман хуҗалыгы, балыкчылык һәм балык тоту тармагында эшләүче квалификацияле ир-атларның хезмәт хакы хатын-кызларныкына караганда **2845 сумга КИМРӘК**

Квалификация таләп ителмәгән эшләрдәге (җыештыручылар, төзелеш эшчеләре һ.б.лар) ир-атларның хезмәт хакы **4060 сумга КҮБРӘК**

Чүп-чар җыюда эшләүче ир-атларның хезмәт хакы шундый төр эштә эшләүче хатын-кызларныкына караганда **2189 сумга КИМРӘК**

– Ир-атларның барлык вазыйфаларда да эшләре күбрәк һәм авыррак. Хәтта физик яктан караганда да. Бары тик шул гына.

– 8 Мартта һәрвакыт ир-ләрне җәлли идем, чөнки коллективларда бүләкләр алырга, моның өчен акчаны да күбрәк җыярга кирәк (хатын-кызлар күбрәк бит!). Менә бит ничек икән!

* Хезмәт хакы турында мәгълүматлар сайлап тикшерү нигезендә (кече эшкуарлык субъектларын кертмичә) 2019 елның октябрь өчен китерелә. Тикшеренүләр 2 елга 1 мәртәбә үткәрелә.

ГАИЛӘЛЕЛӘР ҺӘМ БУЙДАКЛАР ТУРЫНДА:

1 422 500
ир-ат үзенең гаилә хәле турында әйтте

379 071
ир-ат беркайчан да өйләнмәгән

804 863 ир-ат
рәсми рәвештә өйләнгән

95 904 ир-ат
гаилә хәлен теркәми яши

76 587 ир-ат
рәсми рәвештә аерылган

17 156 ир-ат
рәсми рәвештә аерылмаган, әмма аерым яши

48 919 ир-ат – тол

1 638 ир-ат
үзенең статусын күрсәтмәгән

Шәһәрдә яшәүче аерылган ир-атлар авылда яшәүчеләргә караганда **44 635кә күбрәк**

Шәһәрдә яшәүче тол калган ир-атлар саны авылда яшәүчеләр белән чагыштырганда **18 899 га күбрәк**

280 523 буйдак
шәһәрдә яши

98 548 буйдак
авылда яши

Шәһәрдә буйдаклар саны авылдагылар белән чагыштырганда **181 975кә күбрәк**

– Аерылышучылар буенча статистиканы бозып, мин демографияне яхшырткан булып чыгам. Мин икенче тапкыр өйләндем. Ике никахымда да икешәр балам бар.

– Ирне шәһәрдә табу җиңелрәк, әмма аның белән яшәргә авылга кайтырга кирәк булып чыга. Чөнки анда гаиләләр ныклырак икән.

* Никахта торганнар һәм буйдаклар саны турындагы мәгълүматны Татарстанстат бөтенроссия халык санын алу вакытында җыя.

Автор: Руфия Фазылова

ЕЛЫЙ ИКӘН ИРЛӘР ДӘ...

Менә ул Россия Героен үстергән ата кеше – Радик Әхмәтшин. Башта диңгез флотында хезмәт иткән әтисенең батырлыклары, үзенең хәрби очкычларда ничек өйрәнүен сөйләде. Бу вакытта ирнең йөзендә шат елмаю балкыды. Ә улы – Россия Герое исеме бирелгән Маратны искә алгач, ата кешенең тавышы калтырап китте, ул бер мәлгә тынып калды. Әйе, бу аңлашыла да: 36 яшьлек улыңның үле гәүдәсен алып кайтсыннар әле...

«МӘҖБҮРИ РӘВЕШТӘ ОЧКЫЧНЫ ҖИРГӘ УТЫРТТЫМ»

Радик Әхмәтшин тормыш иптәше Римма ханым белән өч бала тәрбияләп үстергән – ике ул, бер кыз. Ир белән хатын кечкенәдән таныш була, чөнки икесе дә Лаеш районының Атабай авылыннан. Әхмәтшиннар быелгы кышны туган авылларында уздырган. Атабайда барлык уңайлыклары да булган зур агач йорт салганнар.

Радик абый очучы, Ставрополь хәрби училищесын тәмамлаган. Бу аның балачак хыялы булган.

– Безнең әти диңгез флотында хезмәт иткән, – дип сүзен башлады ул. – Шуңа да минем диңгезче булуымны теләде. Ә мин кечкенәдән очкычлар белән җенләндем. Хәтерлим, бакчага шома таяк утыртып куеп, шуңа кул белән тотынып, уң якка йөз, сул якка йөз тапкыр әйләнә идем. Шул рәвешле үземне очучы булырга әзерләдем. Турникта тартылу, йөгерү, йөзү (Кама елгасы авылга орынып тора бит) турында да онытмадым.

Әхмәтшиннар иртә өйләнешә. Ни өчен дигәндә, хезмәткә киткәндә, егет сөйгән ярын да үзеннән калдырмаска була. Римма да, чын декабрист хатыны кебек, ире артыннан гарнизонга яшәргә ияреп китә.

– Безнең беренче балабыз Лилия – Приморье краеның Владивосток шәһәрендә, уртанчысы Марат Камчаткада туды, – дип дәвам итте Радик абый. – Ә төпчегебез Рәмис Ленинградта аваз салды. Менә шулай дөнья буйлап йөрелде инде. Бер карасаң, күп тә хезмәт итмәдем – 1972 елда училище тәмамлап, очкычка утырдым. Һәм 1986 елга кадәр хезмәттә булдым. Аннан лаеклы ялга киттем. Без эшләгән чорда гади очучылар егерме биш ел эшлиләр иде. Тик хәрби очучылар аерым статуста йөрде, бер елыбыз икегә исәпләнде. Шуңа да утыз алты яшемдә инде лаеклы ялга киттем. Аннан соң гаиләм белән Казанга күченеп кайттык. Акрынлап Атабайдагы әлеге йортны төзедек. Балалар да булышты.

Радик абый очучы-истребитель булып хезмәт итә. Ул һавадан СССРның чик буйларын саклаган. Күктә бер кош та очырмый, диләр бит, бу нәкъ менә шул очрак. Җирдәге локаторлар чик буенда ниндидер ят әйбер, техника күреп алуга, очучыга команда җибәрә. Хәрби очучы, дүрт минут эчендә җыенып, самолетын күккә күтәрергә тиеш.

– Тормышыгызны куркыныч астына куйган чакларыгыз булдымы? – дим.

– Техник сәбәпләр аркасында, берничә тапкыр гадәттән тыш хәл килеп чыкты – андый чакта тиз генә җиргә төшү ягын карыйсың. Мәҗбүри рәвештә шулай очкычны җиргә утырттым. Ә болай, Аллага шөкер, мин хезмәт иткән чорда сугышлар булмады. Тыныч чакта хезмәт иттем.

Очучы булудан туктагач та, гомере буе самолетлар тирәсендә эшләгән – егерме алты ел Казан аэропортында диспетчер булып хезмәт куйган.

ДИҢГЕЗ ОФИЦЕРЫ

Радик абыйның әтисе дә диңгез офицеры булган. Бөек Ватан сугышы барганда диңгезче булып хезмәт иткән. Аннан соң аларны япон сугышына җибәргәннәр.

– Әтием Вәгыйзь 1924 елгы. Күп сөйләшми иде ул, – дип, хатирәләрен яңартты әңгәмәдәшем. – Сугыш турында да күп сөйләмәде. Шулай да аерым очракларны беләм: 1947 елда, сугыштан калган миналарны юк итеп йөргәндә, мина кыйпылчыклары эләгеп, аларның корабльләре икегә аерыла. Әти шунда контузия ала. Исән калган хәрбиләр берәм-берәм су өстенә йөзеп чыга. Океан уртасында була бу хәл. Контузия

ХӘРБИЛӘР ДИНАСТИЯСЕ:

Вәгыйзь Әхмәтшин

Радик Әхмәтшин

Марат Әхмәтшин

алган эти өч сәгатьләп су өстендә була. Арттан йөзеп килгән корабль аларны коткара. Әти физик яктан бик көчле булган. Идел елгасында коенып үскәнгә, яхшы йөзүче саналган. Шуңа күрә генә исән калгандыр, дип уйлыйм.

Контузия алу сәбәпле, Вәгыйзь Әхмәтшинны туган ягына кайтарып җибәрәләр. Биш еллап диңгез, океаннарда йөзгән егет Атабайга кайтып гаилә кора. Ир белән хатынның бер-бер артлы балалары туа.

– Әти батыр булган, – дип сүзен дәвам итте Радик абый. – Әле хезмәттән кайткач та, елгада суга бата башлаган берничә кешене коткарган ул. «Синең әтиең мине судан алып чыкты», – дип әйтәләр иде. Ул чакта авылда кеше күп булган, барысы да су коенган. Таза-таза егетләр, кеше бата башлагач, куркып калганда, эти уйлап та тормыйча суга сикерә торган була. Батучы кешене чәченнән генә сөйрәп алып чыккан.

Радик абый сөйли, ә мин гаҗәпләнеп утырам: этисе Вәгыйзь дә, үзе дә авыл балалары өчен хас булмаган һөнәрләр сайлаган. Алма агачыннан ерак төшми шул... Әхмәтшиннар нәселе дәвамчысы Марат Әхмәтшин да ата-бабасының юлын дәвам итәргә уйлаган.

– Маратның бик тә хәрби очучы буласы килде, – дип сүзен дәвам итте ата кеше. – Тик мин каршы килдем. Куркынычсызрак һөнәр сайлавын теләдем. Шуңа да Казан артиллерия училищесына җибәрдек үзен. Марат бик теләмичә генә кергән иде, аннан бик яратып укыды.

– Ә ни өчен хәрби очучы булуын теләмәдегез? – дим.

– Куркыныч һөнәр бит. Үзең өчен курыкмыйсың икән, ә менә бала өчен йөрәк өзелә. Тик... улыбызны барыбер югалттык...

Бер мәлгә икебез дә сүзсез калдык. Ата кешенең тавышы калтырый башлады. Мондый чакта сүзнең артык икәнен аңлыйм, шуңа да алга таба сөйләшүебезне дәвам итү өчен, Радик абыйга вакыт бирәм...

«ӘТИ, СИН МИНЕ АҢЛАРГА ТИЕШ...»

Өйдә тынлык урнашты. Күзем Маратның стенкада торган фотосурәтләренә төште. Әнә аның кечкенә вакыты, әнә хәрби хезмәттә чагы. Өченче сурәттә гаиләнең түгәрәк, бәхетле чоры. Барысы да шат, елмаеша... Шулвакыт күрше бүлмәдәге Римма апаның елаган тавышы сискәндереп җибәрде. Ана кеше башта ук:

– Әтисе белән аралашыгыз, Марат турында еламыйча бер сүз дә сөйли алмыйм. Вакыт дәвалый диләр, дөрес түгел. Июньдә балабызны югалтканга биш ел була, аның турында уйламаган бер генә минутым да юк... – дигән иде... Радик абый тиз арада үзен кулга алды һәм сүзен дәвам итте:

– Тагын Маратның ни өчен хәрби очучы булуын теләмәдемме? Туксанынчы еллар азагы иде бит. Илдә ыгы-зыгы барган вакыт. Бергә эшләгән хезмәттәшләр белән сөйләшеп торам, алар әйтәләр: хәрби очучы һөнәрен үзләштерүче курсантлар хәтта самолетларда оча алмый икән, керосин юк. Ничек инде тәҗрибәсез очучыны һавага чыгарып җибәрәсең? Шуңа да ул юлдан китмәсен, дидем.

Марат тырыш егет була – мәктәптә дә, артиллерия училищесында да яхшы укый. Шуннан яшь хәрбине юллама белән Төньяк Кавказга җибәрәләр. Егет хезмәт юлын этисе кебек

үк гаиләле килеш башлый. Йөргән кызы Гүзәл белән гөрләтеп туй итәләр. Аннан Кабарда-Балкар Республикасындагы Прохладный шәһәренә китәләр. Анда яшь гаилә сигез ел яши. Ике балалары туа. Шул арада Марат Әхмәтшин кайнар нокталарга да барып кайтырга өлгерә...

Капитан дәрәҗәсенә ирешкән Маратның хезмәт иткән полкы таркала. Һәм ир белән хатын туган ягына – Казанга күченеп кайта. Аларга Осиново бистәсеннән фатир бирәләр. Марат транспорт оешмасына инженер булып урнаша, аннары йөк машиналары ширкәтенә күчә. Тик хәрби кеше «тыныч» тормышка ияләнә алмый, гарнизонда яшәгән вакытларын сагына. Һәм... гаиләсе, әти-әнисе белән киңәшләшкәннән соң, яңадан хәрби хезмәткә әйләнеп кайта. (Лаеклы ялга китәргә өч ел вакыт калган була.) Барып гариза яза, медицина тикшерүе уза. Капитан Әхмәтшинны Түбән Новгородка билгелиләр. Берничә ай хезмәт иткәннән соң, Марат гаиләсен дә алып китәргә тиеш була. Тик...

– Улыбыз апрель уртасында Сүриягә китте, – дип, ул вакытларны искә алды Радик абый. – Дөрес, безгә дә, хатынына да бу хакта башта әйтмәде. Шомлы командировка турында соңрак кына белдек. Разведка җитәкчесе итеп җибәргәннәр үзен.

– Әти, син мине аңларга тиеш. Хәрби заданиены үтәмәскә хакым юк, – диде ул. Марат 1 июнь көнне гаиләсенә шалтыраткан. Кешеләр аңламасын дип, хатыны белән татарча сөйләшкән. Кайтырга күп калмады, борчылмагыз, дигән. Ә инде өченче июньдә аның гомере өзелә...

Марат Әхмәтшинга, вафатыннан соң ике атна узгач, Россия Герое исемен бирәләр.

Капитан Әхмәтшин җитәкләгән полк һөҗүмгә дучар була. Бу урында шунысын да әйтим: Марат берүзе ДАИШның (Россиядә тыелган террорчылык төркеме) 200 сугышчысына каршы тора. Иптәшләре атыш тавышына килеп җиткәндә, капитан Әхмәтшин кан эчендә ята. Ә кулында – чекасы алынган граната. Әхмәтшин, бернигә дә карамастан, дошманга бирелергә уйламаган...

Марат һөҗүм вакытында өч литрлап канын югалта, шуңа да аның гомерен саклап кала алмыйлар. Шулай итеп 36 яшен генә тутырып килгән хәрбине бик зурлап туган ягына алып кайтып җирлиләр.

– Марат Казанда үсте, 113 нче татар-рус мәктәбен тәмамлады, – диде Радик абый. – Улыбызны ата-бабаларыбыз янына – Атабай зиратына җирләргә дигән карарга килдек. Елга әллә ничә тапкыр каберенә барып кайтабыз. Бик авыр... Сөйләп аңлата торган гына түгел...

Марат Әхмәтшинга, вафатыннан соң ике атна узгач, Россия Герое исемен бирәләр. Геройның өч баласы бүген әтиләренә бирелгән Алтын Йолдыз медален зур горурлык белән алып карый. (Балалыклары белән фаҗигане тулысынча, бәлки, әле аңлап та бетермиләрдер.) Россия Героеның ул-кызлары булулары белән чиксез горурланалар икән. Шуңа үзләре дә хәрби юлны сайлаган: олы кызы Зәринә Мәскәүдә Президент кадет корпусында укый, ә уртанчы улы Әмир Казан Суворов училищесында белем ала. Менә шундый гаилә, шундый язмыш...

Бала кайгысы күрергә язмасын, дип тели һәр ата-ана. Әйе, моннан да авыр хәсрәт булмыйдыр. Әхмәтшиннар гаиләсенә сабырлык, мең кат сабырлык телибез... Илгә батыр ул үстергәнсез, ә батырлар мәңге үлми.

ӨЧЕНЧЕ МӨФТИ

Автор:
Илдус Заһидуллин

Россиядә шәригать һәм ил кануннарын «килештерү», православие дәүләтендә мөселманча яшәү рәвешен кайгырту кебек катлаулы мәсьәләләр белән шөгыльләнү һәр мөфтидән сәясәтче ясаган. Аларның язмышы ил һәм миллият тарихы белән үрелеп, җәмгыять законнары йогынтысында үзгәреш кичергән. Бу яктан караганда өченче мөфти Габделвахит Сөләймәновның язмышы кызыклы.

САНКТ-ПЕТЕРБУРГ МУЛЛАСЫ

Габделвахит Сөләймәнов 1786 елда Сембер губернасы Кормыш өязе Зур Ырбишча авылында ахун гаиләсендә туа. Ул Оренбург янындагы Сәгыйть бистәсе мәдрәсәсендә укый, гарәп һәм фарсы телләрен яхшы үзләштерә. XIX гасыр башында, татар байларына ялланып, Санкт-Петербургка барып урнаша, вак сәүдә белән шөгыльләнә. Биредә Сембер губернасыннан чыккан мишәр җәмгыятендә мулла вазыйфаларын да башкара. 1822 елның Мәхкамәи шәргыягә барып имтихан бирә һәм шәһәрдә мөселман мәхәлләсен терки.

Империя хакимияте мулланы кайвакыт мөселман илчеләр белән рәсми очрашуларга җәлеп итә. Хезмәтләре өчен мулла үзе һәм улы Сөләйман, 1832 елда тархан дәрәҗәсенә лаек булып, крестьяннар түләгән салымнардан азат ителә.

1828 елда император Николай I, Кавказны тыныч юл белән империягә кушу планын тормышка ашыру максатында, бу як халыклары элитасы балаларын башкалага хәрби хезмәткә чакыра. Бераздан аларны хәрби уку йортларына да кабул итә башлый. 1835 елда Николай I нең энесе, хәрби уку йортларының җитәкчесе Михаил Павлович Габделвахит Сөләймановны Кавказ мөселманнарын укыту өчен мөгаллим итеп эшкә чакыра.

Югары даирә вәкилләре белән танышлык һәм алар алдында ышаныч казану Габделвахит Сөләймановка 1840 елның 19 июнендә мөфти итеп билгеләнүгә юл ача.

РЕФОРМАЛАР УЗДЫРУ ТӘКЪДИМНӘРЕ

Хөкүмәт яңа мөфтинең матди хәле һәм яшәү урыны турында кайгыртучанлык күрсәтә. 1840 елда аңа Уфада фатир арендалау өчен казнадан ел саен 350 көмеш сум акча һәм беренче вакытка урнашу өчен 800 сум бирелә. 1849 елда хөкүмәт аны 1,5 мең сум акча белән бүләкли. Еллык хезмәт хакы 1286 сум 55 тиен, шуңа өстәп фатир өчен 350 сум һәм тукланыр өчен 285 сум 90 тиен бирелә.

Мөселманнар Габделвахитны Уфада олы хөрмәт күрсәтеп каршы алалар. Яңа вазыйфага керешеп, ике айдан артык вакыт үткәч, Габделвахит Оренбург генерал-губернаторы В.А. Перовскийдан, Мәхкамәи шәргыядәге казыйларны һәм өстәл җитәкчеләрен үзенә буйсындыру өчен, өстәмә вәкаләтләр һәм сәркатип билгеләүне сорый. Аның мөрәҗәгате җавапсыз кала. Мөфтинең дәрәҗәсен күтәрү буенча хөкүмәт кабул иткән бердәнбер карар дип, 1856 елда Оренбург губернасы төрмәләренең попечительләр комитеты рәисе итеп билгеләүне атарга мөмкин. Аның урынбасары (вице-директор) итеп Оренбург епископы Антоний билгеләнә.

Руханилар яңа мөфтидән үзләренә яклау һәм ярдәм өмет итәләр, үзләренең матди хәлләрен яхшырту һәм хокукларын күтәрү турында гаризалар юллыйлар. 1842 елда Габделвахит мөфти, аларның гозерләрен гомумиләштереп, хөкүмәткә

Фотолар автордан алынды

тәкъдимнәр белән мөрәҗәгать итә. Ул проект түбәндәге пунктлардан тора.

1. Барлык руханилар (мөәзиннәр, имамнар, ахуннар һәм мөхтәсибләр) крестьяннарга һәм мещаннарга гына йөкләнгән рекрут хезмәтеннән азат булырга тиеш.
2. Башка төбәкләргә сайланган имамнар яңа урында паспортсыз яшәргә тиеш.
3. Мулланың уллары, яше тулмаган булса да, вакантлы урын булганда, имам итеп сайланырга хокуклы.
4. Имамнарның һәм аларның 23 яшьтән кечерәк мәдрәсәдә укучы улларының крестьян буларак дәүләт алдындагы бурычларын һәм салымнарын мәхәллә халкы мәҗбүри рәвештә күтәрергә тиеш.
5. Мәхәллә, беренче чиратта, вакантлы урынга мулла улын сайларга бурычлы, андый кандидат булмаса, гади кеше баласын да сайлый ала.

Мөфти 1842 елның 15 сентябрендә язган хатында тагын да кыюланып, муллаларның мәхәлләгә беркетелгән булуын, башка шөгыльгә алынса, мәхәллә халкының дини халәтенә зыян киләчәген искәртеп, аларга чиновникларга һәм хәрбиләргә түләнгән кебек казнадан хезмәт хакы билгеләнергә тиеш дип белдерә. Православие руханиларының салымнардан азат булуларын искә төшерә. Әмма Николай Iнең 1840 нчы елларда исламга карата сәясәте кырыслана. Шул сәбәпле бу тәкъдимнәр кәгазьдә генә кала.

Шулай да хөкүмәт 1850 елда мөселман руханиларын рекрут хезмәтеннән һәм канун бозган өчен тән җәзасыннан – крестьяннарны кебек чыбык белән суктырудан азат итә. 1852 елда муллаларга мәхкамәдә мөселманнарны ант иттергәндә катнашкан яки төрмәгә тоткыннар янына барган өчен командировка акчасы түли башлый. Ләкин күпчелек үзгәрешләр дәүләт кануннарын төгәл үтәтү юнәлешендә була. Әйтик, 1849 елдан балигъ булмаганнарга никах укыган өчен руханиларны 6 айга кадәр төрмәгә утырту тәртибе кертелә. 1855 елда руханиларның вазыйфага керешү яше билгеләнә: ахуннар – 25 яшьтән, хатиблар һәм имамнар – 22 яшьтән, мөәзиннәр – 21 яшьтән.

Мәхкамәи шәргыйдә штатлар җитмәү Габделвахитның күңелен бигрәк тә төшерә. Әмма 1841 елда хөкүмәт өстәл башлыгы һәм ике канцелярия хезмәткәре штатларын өсти.

Мөфти гыйлемле казыйлар туплау максатында аларны билгеләүне үзенә тапшыруны сорап карый, ләкин теләгенә ирешә алмый. Казан губернасы руханилары тарафыннан Мәхкамәи шәргыягә әгъза итеп сайланучы дини белемнәре сай руханилардан котылу өчен дә кирәк була бу. Мәхкамәи шәргыйдә эшне яхшылап оештыра алмавының төп сәбәпләренең берсе казыйларның наданлыгы була.

МӨСЕЛМАННАРНЫҢ НИКАХЛАШУ ҺӘМ АЕРЫЛЫШУ КАГЫЙДӘЛӘРЕ

Риза Фәхретдин мөфтинең шәхси сыйфатларыннан кешеләр белән аралашуда гади булуын, хәттә Мәхкамәи шәргыягә эшләүче писарь белән ауга йөрүен билгеләп үтә. Шиһабетдин Мәрҗани, мөфти белән аралашкан елларын искә төшереп, болай дип яза: «Китап сөюенә, галимнәр белән аралашырга яратуына, Госмания дәүләте китапларын, газеталарын һәм язмаларын карап бару өстенә, кайбер рус әсәрләрен дә укуына карамастан, чын мәгънәсендә гыйлем иясе була ал-

Уфаның Беренче җәмигъ мәчете. XX гасыр башы фотосы.

маган. Шулай да төрки телдә язылган язмаларны үз телендә, үз дәрәҗәсенә күрә камил рәвештә, күче җиткәнчә аңлата иде. Тыйбб китапларыннан файдалана, дару үләннәренең күбесен белә, гарәпчә, фарсыча һәм башка чит телләрдә булган язмаларны төрки һәм рус телендә аңлата иде».

Эчке эшләр министрлыгы аңа мөселманнар өчен никах һәм аерылышу кагыйдәләрен эшләүне йөкли. 1841 елда кабул ителгән кагыйдәләрдә никахны фәкать кыз бала тәрбияләнгән мәхәллә мулласы укырга тиешлеге, егет белән кызның Россия кануннарындагы балигълык яшенә җиткән булулары карала. Никахка кадәр кәләш янына кеше җибәреп, мулла аның «риза» булуын ишетергә, ягъни кәләшнең ирекле, үз теләге белән тормышка чыгуын белергә тиеш була.

Оренбург казак гаскәрендә хезмәт итүче мөселманга никах укыганчы, мулла аның командирыннан рөхсәт сорарга тиеш. Башкорт яки башка казак сословие вәкиле икенче хатын алырга теләсә, шулай ук муллага үзенең командирыннан беренче хатыны белән аны кимсетми яшәгәнлеге һәм икенче хатынга өйләнү өчен җитди сәбәп булуы хакында кәгазь алып килү мәҗбүри итеп куела.

Рекрут хезмәте 20 ел булу сәбәпле, имамнарга ире солдатка алынган хатынны, мөрәҗәгать иткән очракта, аеру хокукы бирелә.

МӨСЕЛМАННАРНЫ ДӘҮЛӘТ ОПОЛЧЕНИЕСЕНӘ ЧАКЫРУ

1853–1855 елгы Кырым сугышында Россиянең җиңә алмаячагын яхшы аңлаган Николай I, гаскәрләргә ярдәм итү өчен, дәүләт ополчениесе төзү турында Указга кул куя. Ополчениегә мөселманнарны җәлеп итү максатында, 1855 елның апрелендә Габделвахит Сөләйманов дин кардәшләренә мөрәҗәгать белән чыга. Аның фикер сөреше мөфтинең сәяси эшчәнлеген күзалларга мөмкинлек бирә.

Иң башта Габделвахит мөселманнарның рус падишаһы яклавы астында үз диннәрен иркен тотып яшәүләрен, Россиядә һәр теләгән кешегә баю, һөнәр үзләштерү һәм сәүдә итү өчен шартлар тудырылган булуны искәртә, дәүләттә мөселманнарның руслар белән бер дәрәҗәдә уңышка ирешү, дәүләт бүләкләренә ия булу мөмкинлеге турында әйтә. Ачлык яки йогышлы авырулар таралган елларда хөкүмәтнең орлык һәм дарулар белән ярдәм кулын сузуын искә төшерә.

Аннары Россиядә бәхетле тормышта яшәгән мөселманнарның хәлен чит илләрдәге дин кардәшләренеке белән чагыштыра. Әммә мөфти халыкара вакыйгаларны нык бутап күрсәтә. Төркиянең союзниклары белән бергә хәрәкәт итүен яшереп, Европа илләре мөселман дәүләтен Россиягә каршы сугышта тартып кертте, югыйсә төрекләр Россиядән ярдәм сорарга әзер, дип хәбәр итә. Дин кардәшләрен ополчениегә язылырга өнди, иганә ярдәме күрсәтергә чакыра.

Уфа каласында мөфти Габделвахит Сөләйманов төзеткән Мәркәмәи шәргыя бинасы. XX гасыр башы фотосы.

ТӨЗҮЧЕ МӨФТИ

Уфага килгәч, Сөләйманов, Мәхкәмәи шәргыяның бер катлы бинасы проектының расланмаган булуыннан файдаланып, аңа үзгәрешләр кертә. Төп яңалык – бинаны ике катлы төзеп, икенче катка мөфти фатирын урнаштыру. Әйтергә кирәк, хөкүмәт раслаган проектта аның бу тәкъдиме исәпкә алына.

Төзелеш эшләре башлангач, 1861 елның 22 маенда, Габделвахит Сөләйманов яңа тәкъдимнәр белән чыга. Аның фикеренә колак салып, сметага өстәмә эшләр языла: ат абзары, кареталар, ат арбалары һәм чаналары өчен сарай, кер юу урыны булган мунча төзү, казыйлар өчен флигельдә базлар казу һәм ишек алдын таш койма белән әйләндерү. Шулай итеп, Мәхкәмәи шәргыя бинасы бер комплекс буларак корыла.

Төзелеш эшләре мөселманнардан никах укыткан өчен җыелган акча (салым) хисабына 1865 елда тәмам була. Прокурор тикшерүе акчаның төгәл, дөрес файдаланылганын раслый.

Төзелеш эшләре башлангач та, никахны теркәгән өчен салым җыюны туктату мәсьәләсе калкып чыга. Габделвахит мөфтинең никах теркәгән өчен салымны саклап калуы соңрак Мәхкәмәи шәргыя эшчәнлеген оештыруга зур файда китерә.

Мөфтигә бинаның төзелеп беткәнен күрергә, яңа урында эшләргә һәм яңа фатирда яшәргә насыйп булмый. Ул 1862 елның 4 августында 76 яшендә вафат була. Уфа зиратына җирләнә.

Замандашы Габделвахит Сөләйманов турында Шиһабетдин Мәрҗани болай дип яза: «Мөфти булгач, Россиянең олылары белән азмы-күпме аралашырга, эшне үзгәртеп һәм төзәтеп корырга, шәригатькә яраклашырга теләге бар иде. Ләкин гыйлеме азлыктан һәм ярдәм таба алмавы сәбәпле, көч-куәт туплый алмады». Чынлыкта Николай I хөкүмәте үзенә файдалы булган очракта гына мөселманнарның тәкъдимнәрен хуплау кагыйдәсен куллана башлый. Шуңа күрә Габделвахит мөфтинең руханиларның хокукларын һәм социаль хәлен уңай якка үзгәртү, Мәхкәмәи шәргыя эшчәнлеген яхшырту һәм башка мөселман эшләре белән бәйле тәкъдимнәре дәүләт тарафыннан чын яклау тапмый.

Әзерләде: Мөршидә Кыямова

«КАРУСЕЛЬ – МИНЕМ КОНСЕРВАТОРИЯМ»

Озын буйлы, чандыр гәүдәле, кай ягы беләндер чегән баласына охшаган малай, әтисеннән качып, үзлегеннән гармун уйнарга өйрәнә. Әмма тормыш авырлыкларыннан кырысланган әтисе Кәбир абзый гармунны малае кулыннан тартып алып вата, улына каты гына «сабак укыта». Тик Фәйзулланың җыр-моңга омтылышы һәм үҗәтлеге арткан саен арта гына бара.

Фотолар Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе һәм Татарстан Милли музее фондларыннан алынды.

БЕЛЕШМӘ

Фәйзулла Кәбир улы Туишев 1884 елның 6 декабрендә Самара губернасы Иске Төгәлбуга авылында күп балалы гаиләдә туа. Туган авылында 3 ел мәдрәсәдә укый. 1895 елда Туктаровлар (Туишев – артистның тәхәллүсе) гаиләсе Мәләкәскә күченә. Бик яшьли үзлегеннән гармун уйнарга өйрәнә. Гастроль тормышы да иртә башлана. 1894 елга кадәр Чабаксар балаганында эшли. Самарадан Әстерханга кадәр Идел буйлап гастрольдә йөри. Шуннан соң 10 ел буе – күчмә циркта, 1907–1910 нчы елларда Сембер шәһәре циркында җырчы, жонглёр, цирк җайдагы булып эшли.1912 елда Мәскәүдә һәм 1914 елда Петербургта узган концертлары зур уңыш казана. 1918–1926 нчы елларда Ерак Көнчыгышта һәм Себердә яши. 1926 елда Казанга әйләнеп кайта. 1937 елдан Татар дәүләт филармониясендә эшли.

Утыздан артык музыкаль әсәр авторы. Репертуарында төрле халыкларның көйләре, маршлары һәм классик әсәрләре урын алган. Музыкантның чыгышларын Г. Тукай, Ф. Әмирхан, С.Гыйззәтуллина-Волжская, Г. Камал, Г. Кутуй, М. Горький сокланып тыңлаган. Федор Шаляпин белән берничә тапкыр чыгыш ясаган. Махсус музыкаль белеме булмаган Туишевның әсәрләренә Ленинград консерваториясе профессоры Михаил Юдин, композитор Александр Ключарёв югары бәя биргән. ТАССРның 23 еллыгына багышланган сюита, Балалар сюитасы, Совет Армиясе геройларына багышланган сюита, «Уйлану», «Ватан», «Тракторчы кыз», «Лирик бишек» җыры һ.б. әсәрләре зур популярлык казанган. Аларның кайберләре Татарстан радиосы фондына да язылган.

ТАССРның атказанган артисты (1926 ел), ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1934 ел), ТАССРның халык артисты (1944 ел). Халык уен коралларында уйнаучыларның I Бөтенсоюз смотрының II премиясе лауреаты (1939 ел, Мәскәү).

1958 елда Казанда вафат була.

1988 елда Татарстанда Фәйзулла Туишев исемендәге гармунчылар конкурсы уздырыла башлады. Ике ел саен үткәрелә торган бу ярыш халыкара конкурска әверелде. Фәйзулла Туишев иҗаты бик күп музыкантларга өлге булды, аның үрнәгендә милләтнең башка гармунчылары үсеп чыкты.

ХАЛЫКТАН ЧЫККАН ТАЛАНТ

Сүзебез татарның беренче профессиональ гармунчысы Фәйзулла Туишев турында. Аның автобиографиясендә шундый юллар бар:

«Атам батрак иде... Минем балачагым хәерчелектә узды. Гаиләдә 13 бала. 8–9 яшемдә рус малайлары белән уйнаганымны хәтерлим, аларның төрле уенчыклары бар, тик мин генә хәерче – берниндиуенчыгым да юк иде. Якын дустым – Ваня Кузнецов, ни өчен якын, чөнки аның гармуны бар! Бик яхшы булмаса да, гармун белән бик тә кызыксынам. Кайчагында дустым гармунын миңа да биргәли – көй чыгарырга маташам, бервакыт мавыгып китеп, клапанын ваттым. Дустымнан эләкте, яңа гармун сатып алгач, ул миңа аны тоттырмады инде...»

Фәйзулла үз гармуны турында хыяллана. «*...Менә мин үземә акча тупларга керештем – йөгереш ярышларында катнаша башладым, анда миңа 5 тиен, 10 тиен бирәләр. Шул юл белән мин 3 сумга якын акча тупладым һәм Мәләкәс шәһәрендәге ярминкәдән 2 сум 50 тиенгә гармун сатып алдым. Ул чакта мин үземне дөньядагы иң бәхетле кеше дип тойдым. Тик, кызганыч, әти яраткан гармунны – минем кыйммәтле коралымны кулымнан тартып алып, идәнгә ташлады һәм аяклары белән таптап изде, үземә дә эләкте*».



Дуслар: Фәйзулла Туишев һәм Александр Ключарев. 1955 ел.

Туган авылыннан Мәләкәскә күчкәч, Фәйзулла карусельләргә йөрергә ярата. Аны аттракцион үзе түгел, ә музыкантлар һәм артистлар кызыксындыра торган була. Артист, музыкантлар гади кешеләрнең күңелен ача, аларга төрле кәмит күрсәтә. Бәләкәй Фәйзүк шулар тирәсендә чуала. Шаян, кызыксынучан малай үзе дә артистларның игътибарын җәлеп итә. Башта Фәйзук «подхватта» тора, ә соңрак куплетлар башкара, бии һәм гади акробатик күнегүләр ясый башлый. Гармунчылар чыгышын малай авызын ачып күзәтә, аларның уен коралы белән эш итүләре бигрәк тә кызыклы тоела аңа. «Карусель – ул минем өчен консерватория һәм музыка техникумы...», – дип яза соңрак Фәйзулла Туишев үзенең автобиографиясендә.

Татарлар «тальян гармун» дип атап йөрткән корал ул вакытта ук халык арасында таралган булса да, аңа карата аеруча зур кызыксыну XX гасырның беренче унъеллыгында уяна. XIX гасырның 90 нчы елларында сәләтле рус гармунчысы Петр Невский исеме бөтен илгә яңгырый. Невский ярминкәләрдә, трактирларда, халык күңел ачкан урыннарда чыгыш ясый. Бәлки, малай чагында Туишев танылган артистны Мәләкәс ярминкәсендә күргәндер, сәнгать белгечләре дә шулай фаразлый.

Авырлык белән көн күрүче гаиләдә тәрбияләнгән, музыка мәктәбенә йөрмәгән, бернинди музыка уен коралы яңгырамаган мохиттә тәрбияләнеп тә, олы сәхнәгә чыккан, дөнья күләмендә танылган Федор Шаляпинга уйнарлык һиммәткә ирешкән Фәйзулла Туишевны халыктан чыккан талант дип кенә бәяләргә мөмкиндер. Җәй көннәрендә төрле мәйданнарда уйнап йөрсә, кыш айларында Мәләкәснең бер туе да аның катнашыннан башка узмаган. 12 яшендә инде ул тирә-юньдә нык таныла. «Гармунчы Фәйзүк» Мәләкәстәге тамашаларда халык мәхәббәтен яулый, ә аннан соң гармунда уйнап акча эшли башлагач, гаиләдәгеләр дә җиңел сулап куя, күрәсең, эш калдырып йөрүче «гармунчы»га һәм уен коралына карата да мөнәсәбәт үзгәрә...

Мәләкәскә килгән артистларга ияреп, Фәйзулла беренче мәртәбә Казанга килә. Үсмер егет Масленица бәйрәмендә чыгыш ясый, аны барысы да рус егете дип кабул итә, чөнки төрле гармуннарда оста уйнаучы татарны күз алдына китерүе дә читен була әле ул вакытта. Җитмәсә, егет шәп итеп русча сөйләшә, рус халык көйләрен башкара... Ә менә аның мөселман икәнен белеп алгач, «Печән базары» әһелләре, шәригатькә каршы барганы өчен, музыкантның кирәген бирәләр. «Тәмуг кисәве»н, «шайтан малае»н тотып, һушыннан язганчы кыйныйлар. Егет яңадан туган ягына кайтып китә, әмма гармунын кулыннан төшерми...

МИЛЛИ МУЗЕЙДАГЫ КОЛЛЕКЦИЯ

Россия шәһәрләре буйлап йөргәндә, Фәйзулла төрле халыкларның милли музыкаль традицияләрен бик җиңел үзләштерә. Кавказ, Үзәк Россия, Украина һ.б. төбәкләрдә яшәүче халыкларның музыкасын бөтен нечкәлекләре һәм үзенчәлекләре белән өйрәнә ул.

Татарстан Милли музеенда Фәйзулла Туишевның шактый бай коллекциясе, шәхси әйберләре саклана. Музейның фәнни хезмәткәрләре әлеге милли хәзинәдән күргәзмә оештырды. Биредә аның үзенчәлекле гармуннары, концерт костюмы, читеге, фотосурәтләр, документлар, гаилә архивыннан алынган тавыш тәлинкәләре, халык тарафыннан аңа бүләк ителгән сувенирлар белән танышырга мөмкин.

«Фәйзулла Туишев үзенең коллекциясен музейга тапшыру турында 1956 елда, авырый башлагач сүз кузгата. Безнең фондтагы фотосурәттә сакланып калганча, ул анда бай гармуннары коллекциясе фонында төшкән. Музейның өлкән фәнни хезмәткәре Рөстәм Касыймов белән коллекцияне фондка тапшыру турында сөйләшәләр. Ә коллекция үзе безгә 1959 елда гына килеп керә. Үзе вафат





Данлыклы гармуннар.

булганнан соң, тормыш иптәше китереп тапшыра. Анда 25 документ һәм гармунчының 39 шәхси әйбере, шул исәптән 17 се төрле зурлыктагы, төрле формадагы гармуннары була. Алар XIX гасыр азагы – XX гасыр башында Германия, Россиядә һәм башка илләрдә эшләнгән, күбесе Казан музыка уенчыклар фабрикасында җитештерелгән. Шунысы кызык: кайбер гармуннарга ул «Бәдерниса», «Мәрьям», «Асия», «Фәхерниса» кебек хатын-кыз исемнәре биргән. Ә ни өчен икәне мәгълүм түгел», – дип сөйләде безгә Милли музейның өлкән фәнни хезмәткәре **Миләүшә Хәйруллина.**

Музейда саклванучы гармуннарның техник торышын атаклы музыкант **Рәшит Мостафин** да өйрәнеп чыккан. «Искитмәле гармунчының уен кораллары да үзенчәлекле. Алар төрле зурлыкта, яңгырашлары да үзенчәлекле. Кайберләре Туишевка атап махсус эшләнгән», – ди Рәшит Мостафин. Аның фикеренчә, виртуоз музыкантның гармуннарына яңа сулыш өрергә кирәк, югыйсә, алар кибеп яраксызга чыгарга мөмкин. Чыннан да, күпне күргән, бай концерт тормышы узган уен кораллары фәнни яктан да өйрәнелергә тиеш. Әлеге гармуннарда милли сәнгатебезнең үткәне чагыла. Гомумән, гармунда уйнау, гармун ясаучылар мәсьәләсе бүгенге көндә кискен тора дияргә мөмкин. Аны ясаучылар да, гармунда уйнаучылар да бармак белән генә санарлык.

Музыкантның гармуннары төрле зурлыкта, ул аларның һәрберсендә виртуозларча төрле

Фәйзулла Туишев концерт костюмыннан.

Шәриф Камал, Кави Нәҗми һәм Фәйзулла Туишев. 1939–1940 нчы еллар.

милләт әсәрләрен башкара алган. Гармунчының чыгышын түземсезлек белән көтеп ала торган булганнар, чөнки ул сәхнәдә чын-чынлап, хәзерге тел белән әйтсәк, шоу оештырган. Бәләкәй гармуннардан башлап, зурракларына күчә яисә киресенчә, көй уйнаганда гармуннарны һавага чөеп-чөеп ала, хәтта шул вакытта да гармуннар моң чыгарудан туктамый! Халык тамашаны авыз ачып күзәтә, соңыннан кайнар алкышларга күмә.

Истәлекләрдән күренгәнчә, Мәкәрҗә ярминкәсендә 1910 елда Фәйзулла Туишев «Сәйяр» труппасы артистлары белән очраша. Әлеге очрашу аның татар көйләренә игътибарын арттыра. Моңарчы рус, чуваш көйләренә мөкиббән егет үз репертуарын татарның «Иске кара урман», «Агач башы», «Туганай», «Ташлар аттым Болакка» әсәрләре белән баетып җибәрә. Ә татар халкы мондый чыгышларны, әлбәттә, шунда ук үз итә, гармунчы егетнең даны таралганнан-тарала.

МАҖАРАЛАРГА БАЙ ТОРМЫШ

1915 елда Петербургта Фәйзулла Туишев Федор Шаляпин белән очраша. Мәшһүр җырчы, музыкантның талантын сизеп, аңа үзе белән концертта чыгыш ясарга тәкъдим итә. Шуннан соң Шаляпин белән Туишев дуслашып, тагын берничә концерт куялар.

Бервакыт татар артисты Иваново шәһәренә гармун ясаучы оста янына килә. Гастроль тормышы аның мул яшәешен тәэмин итә, үзенә теләгән уен коралын сатып алу өчен ул акчасын кызганмый. Ивановода да 14 уен коралына заказ бирә. Заказны көтәргә кирәклеге ачыклангач, вакытны бушка уздырмау җәһәтеннән, Туишев шундагы бер ресторанга эшкә урнаша. Биредә ул Максим Горький белән очраша. Музыкант бу очрашу турында болай дип язып калдыра: «*Горький миңа: «Ә, күптәнге таныш, музыкант Туишев! Сез ничек монда килеп чыктыгыз? Сез бит ресторан гармунчысы түгел, ә безнең ватан солисты». Мин шәһәрдәге йомышымны һәм ресторанда эшләргә мәҗбүр булуымның сәбәбен аңлаттым... Горький мине табынга чакырды, аннары дусларына Казанда яшәве турында бик кызыклы итеп сөйләде. Мин Алексей Максимович өчен рус көйләрен башкардым... Аерылышыр алдыннан ул миңа болай диде: «Моннан тизрәк китәргә тырыш, бу кабак синең талантың өчен зарарлы!»*

Татар музыкантының тормышы төрле маҗараларга бай. Туишев Самарада Красильников циркында эшли. Бервакыт янгын чыга һәм зур цирк бинасын ут ялмап ала. Икенче көнне, янгыннан соң, цирк директорының, артистларга хезмәт хакын түләмичә, шәһәрдән качканлыгы ачыклана. Бөтен труппа – кырыкка якын артист – эшсез, акчасыз кала. Фәйзулланың хәле тагын да мөшкелрәк, ике-өч ай яшәгән фатиры өчен түләнмәгән, ә янгын чыкканчы, аның бүлмәсенә караклар кереп, бөтен милкен һәм бай гардеробын урлап чыккан була...

Туишевның һәр гастроле зур уңыш белән уза. Артистлык язмышы аны кая гына ташламый, кайда гына чыгыш ясамый ул: Самара, Баку, Түбән Новгород, Петербург, Иркутск... Монголия, Кытай, Корея, Япония, Америка... Татар гармунчысы аяк баскан һәм уйнаган барлык шәһәрләрне, илләрне санап та бетерерлек түгел. Артистның үзенчәлекле музыкаль хәтергә ия булуы мәгълүм, аның виртуоз бармаклары бер ярым тоннан да теләсә нинди көйне отып ала алган. Музыкант үз чыгышларына җитди әзерләнгән, фотоларга төшкән чагында да киемендәге һәр детальгә игътибар итә торган булган. Костюм-киемнәре бик затлы, болар артистның иҗаты шаулаган чактагы мул тормышына бер дәлил.

КАЗАН ЧОРЫ

Фәйзулла Туишев төрле җирләрдә яшәп, иҗат итсә дә, 1926 елда Казанда төпләнеп кала. Биредә гармун фабрикасын ачуда башлап йөри. Аны фабриканың техник советына баш белгеч, соңрак консультант итеп билгелиләр. Татар дәүләт филармониясе оешкач, 1937 елда данлыклы музыкант биредә эшли башлый. Ачылганнан соң, аның төп солистларыннан берсе булып китә. Филармония каршында баянчылар ансамбле оештыру белән шөгыльләнә, 1939 елдан даими рәвештә дәресләр бирә башлый.

Виртуоз музыкантның 1949 елның 17 августында язган васыятьнамәсендә мондый юллар бар: «*Минем үлем очрагында үземнеке булган әйберләрне, музыка коралларын, картиналар, фатир торышын һәм башка предметларны, сатмау шарты белән, хатыным Ләйлә Солтан кызы Туишевага васыять итәм. Хатыным вафатыннан соң, мин фатирымны һәм андагы әйберләрне – барысын да минем яраткан Совет дәүләтенә тапшырырга васыять итәм. Минем туганнарым да, хатынымның туганнары да мираска хокуклы*

Фәйзулла Туишевта кунакта.

түгел, мөлкәтем Совет власте заманында минем тарафтан җыелган. Бу диңгездәге тамчы булса да, мин республикама, орденлы Татариямә калдырам... Республикамнан һәм хөкүмәттән, сәнгать эшләре буенча начальниктан, Министрлар Советыннан минем шундый мәхәббәт белән җыелган почмак-музейның үз урынында калдырылуын үтенәм. Композиторлар берлегенең музей-почмакта булган хәлләрне күзәтеп торуын сорыйм».

Әлеге васыятьнең ни дәрәҗәдә үтәлүен ачыклавы читен, чөнки Фәйзулла Туишев гомеренең соңгы елларын юклыкта уздыра. Заманында зур суммалар түләп алган гармуннарының кайберләрен хәтта сатарга мәҗбүр була. Фәйзулла Туишевның вафатыннан соң, хатыны да кайбер истәлекле шәхси әйберләрне чыгарып сата, гармуннарының күпчелек өлеше эзсез югала. Күпсанлы истәлекле фотолары (1941 елда Муса Җәлил белән төшкән фотосурәте, Федор Шаляпин бүләк иткән истәлек фотосы һ.б.лар), замандашларының хатлары, концерт афишалары, Александр Ключаревка имзаланган тәмәке савыты, Бөек Ватан сугышы вакытындагы чыгышлары өчен солдатларның рәхмәт хатлары һ.б.лар Татарстан Милли музее фондында саклана. Әлеге бай тупланма татарның беренче профессиональ гармунчысы турында этрафлы католог төзергә дә мөмкинлек бирер иде. Күренекле шәхеснең кайбер документлары исә Татарстан Дәүләт архивында да саклана.

Заманында Фәйзулла Туишев иҗатын, тормышын яхшылап өйрәнгән язучы Фатыйх Хөсни дә, үзенчәлекле тормыш юлы узган, гаҗәеп кешеләр белән очрашкан маэстро турында китап язып булыр иде, дигән бит.

ХАТИРӘЛӘР...

Фатыйма Вәлиева, музыка белгече:
– Фәйзулла Туишев – үз йөзе, үз башкару стиле булган гаять зур артист. Концерт программасыннан башлап, һәр нәрсә алдан уйланылган планга туры килә һәм образ тудыру идеясенә буйсындырыла. Сәхнәгә ашыкмый гына чыга ул, йөзе бик тә җитди, иреннәре кысылган, күзләре ярым йомык була. Аның куәтле артистлык темпераменты әсәрнең беренче авазларыннан ук мавыктырып, үз артыннан ияртеп алып китә. Ул кайвакыт үзе дә сизмәстән, менә дигән югары художестволы вариацияләр тудыра. Гармунның мөмкинлекләре чикле булуын бик яхшы белгән Туишев, анда башка төрле халык музыка коралларыныкына (мандолина, курай, балалайка) охшаган авазлар һәм хәтта кеше тавышлары чыгарып, төрле тембрдагы авазлар тудырырга омтыла.

Кирам Сатиев, баянчы, Татарстанның халык артисты:
– Казанга өченче мәртәбә килүендә Фәйзулла Туишев Габдулла Тукай белән таныша. 1912 елда Мәскәүдә зур уңыш казанганнан соң, Туишев Петербург каласында да күренергә кирәк, дигән кыю фикергә килә. 1914 елда ул Петербургка китә. Аның «Халык йорты» залында оештырылган беренче концерты зур уңыш белән уза: аның исемен танылган рус гармунчылары Петр Невский һәм Павел Малазов исеме белән янәшә куялар.

махсус проект

«ТАТАРСТАН» ЮБИЛЯРЛАРЫ

59

ЧЫГАРЫЛЫШ



Фәрит Хәнифов, ТР транспорт һәм юл хуҗалыгы министры, март аенда үзенең 60 яшьлек юбилеен билгеләп үтә.

Эдуард Данилов,
«Главтатдортранс» ДКУ директоры

РЕСПУБЛИКА ҮСЕШЕНӘ КЕРТКӘН ӨЛЕШЕГЕЗ БИК ЗУР

– Хөрмәтле Фәрит Мөдәррисович!

Сезне «Главтатдортранс» дәүләт казна учреждениесе хезмәткәрләре коллективы һәм шәхсән үз исемемнән юбилеегыз белән ихлас тәбрик итәм!

Бу күркәм бәйрәм – башкарган эшләрегез һәм шәхси сыйфатларыгыз өчен хөрмәт сүзләребезне җиткерергә бер форсат ул. Төзелеш өлкәсендәге уңышлар Сезнең җаваплы хезмәтегез белән бәйле булды, бүген исә Сезне республиканың транспорт инфраструктурасын һәм юл комплексын үстерү буенча яңа эшләр көтә. Татарстан Республикасының транспорт һәм юл хуҗалыгы министры вазыйфасын актив, инициативалы, үз эшенең остасы булган һәм теләсә кайсы катлаулы хәлләрне тиз арада хәл итә ала торган лаеклы кеше башкаруын билгеләп үтәргә кирәк. Тирән тәҗрибәгез, оештыру сәләтегез һәм фидакарь хезмәтегез тармак белән уңышлы идарә итәргә булыша.

Сезнең яңа вазифага килүегез белән Татарстанның автомобиль юллары хуҗалыгы яңа үрләр яулар һәм татарстанлылар иминлеге хакына масштаблы яңа проектларны гамәлгә ашырыр, дип ышанабыз. Республиканың транспорт тармагын үстерү юлында хезмәттәшегез һәм аркадашыгыз буларак, һөнәри осталыгыгызны һәм алга карап эш йөртә белүегезне югары бәялим.

Хөрмәтле Фәрит Мөдәррисович! Сезгә мөһим эшегездә уңышлар телим! Көч-куәтегез һәрвакыт ташып торсын! Сезгә һәм якыннарыгызга ныклы сәламәтлек һәм иминлек телим!

Рөстәм Нуриев,
Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы башлыгы

БАШКАРГАН ЭШЛӘРЕГЕЗ ӨЧЕН ИХЛАС КҮҢЕЛДӘН РӘХМӘТ

– Хөрмәтле Фәрит Мөдәррисович!

Алабугалылар һәм шәхсән үз исемемнән юбилеегыз белән ихлас котлауларыбызны кабул итеп алыгыз!

Бүген Сезнең хөрмәткә яңгыраган җылы сүзләргә кушылам һәм Сезнең Татарстан Республикасы иминлеге хакына башкарган эшләрегез өчен рәхмәтләремне җиткерәм. Төзелеш өлкәсендә һәм республиканың транспорт һәм юл хуҗалыгы министры вазифасында алып барган актив эшчәнлегегез Сезне үз эшенең остасы һәм тәҗрибәле җитәкче итеп танытты.

Сезнең Алабуга муниципаль районы үсешенә керткән өлешегез өчен аеруча рәхмәт. Сез биредә берничә дистә ел тырыш хезмәт куеп, зур нәтиҗәләргә ирештегез һәм шуның өчен алабугалыларның ихтирамын яуладыгыз. Алабуга җирендә тугры дусларыгыз һәм ышанычлы аркадашларыгыз Сезне бары тик сагынып искә алалар.

Хөрмәтле Фәрит Мөдәррисович! Юбилей көнегездә Сезгә җаваплы эшегездә алга таба да уңышлар, ниятләрегезнең чынга ашуын һәм бетмәстөкәнмәс көч телим. Сезгә һәм гаиләгезгә зур шатлыклар һәм иминлек, бәхет һәм ныклы сәламәтлек юлдаш булсын!

Фото «Главтатдортранс» ДКУ матбугат хезмәтеннән алынды; Алабуга муниципаль районы матбугат хезмәтеннән алынды

Илнур Гарипов, ТР Президенты Аппараты Җитәкчесе урынбасары – ТР Президентының Территорияләр белән эшләр идарәсе башлыгы, февраль аенда үзенең 50 яшьлек юбилеен билгеләп үтә.



Мәҗит Салихов,
«ТР ДЭБИ» ДАУ башлыгы

ҮЗИДАРӘНЕ НЫГЫТЫП

– Хөрмәтле Илнур Мәхмүтович!

Юбилеегыз уңаеннан ихлас котлауларымны кабул итеп алыгыз!

50 яшь – ирешелгән нәтиҗәләргә әйләнеп карау, алга таба эшчәнлек алып бару, шәхси казанышларга ирешү, планнар кору өчен яхшы форсат ул. Сез һәрвакытта да ватанпәрвәр булуыгыз, актив тормыш позициягез, һөнәри осталыгыгыз һәм һәрнәрсәгә җаваплы каравыгыз белән аерылып тордыгыз. Татарстан Республикасының дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча төбәк шәһәрләрендә һәм районнарында җирле үзидарә органнары белән нәтиҗәле хезмәттәшлеккә, урыннарда хакимият вертикален төрле яклап ныгытуга һәм муниципаль берәмлекләрне модернизацияләүгә йөз тотып, озак еллар дәвамында татарстанлыларның иминлеге хакына хезмәт итәсез.

Хөрмәтле Илнур Мәхмүтович! Сезне юбилеегыз белән ихлас котлыйбыз һәм Сезгә ныклы сәламәтлек, эшегездә уңышлар, гаилә җылысы һәм иминлек телибез! Алдагы тормышыгызда да һәрвакыт уңышлар гына юлдаш булсын! Шатлык һәм күтәренке кәеф Сезне ташламасын, ә бәйрәм көнендә әйтелгән җылы сүзләр һәм изге теләкләр тормышка ашсын!

Реклама

Анатолий Иванов,
Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башлыгы

АНЫ БӨТЕН РЕСПУБЛИКА ОЛЫЛЫЙ

– Хөрмәтле Илнур Мәхмүтович!

Мамадыш муниципаль районы халкы һәм шәхсән үз исемемнән Сезне чын күңелдән юбилеегыз белән тәбрик итәм!

Бүген Сезне, югары дәрәҗәгә ирешкән абруйлы җитәкче, үз эшенең остасы һәм ярдәмчел кешене, бөтен республика олылый. Сез үзегезнең бөтен көчегезне, тәҗрибә һәм талантыгызны дәүләт институтларының эшен камилләштерүдә һәм республиканы төрле яклап үстерүдә кулланасыз. Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Президентының Территорияләр белән эшләр идарәсе башлыгы вазифасында башкарган хезмәтегез нәтиҗәсендә безнең төбәк җирле үзидарәне үстерү ягыннан актив үсә, Татарстан Республикасы хакимияте органнары тарафыннан муниципаль районнардагы вазгыятькә даими мониторинг алып барыла, оператив төстә контрольдә тотыла.

Сезне абруйлы дәүләт эшлеклесе, алга карап эш итә белә торган сәясәтче һәм ышанычлы оештыручы буларак беләләр. Үз чиратында Мамадыш муниципаль районы һәрвакытта да Татарстанның үсешенә үз өлешен кертә һәм Сезгә республиканың җирле үзидарә системасына төрле яклап ярдәм итүегез өчен рәхмәтен белдерә.

Хөрмәтле Илнур Мәхмүтович! Шушы күркәм бәйрәмегез көнендә Сезгә республика иминлеге хакына башкарган мөһим эшләрегездә алга таба да уңышлар телим! Эшләрегез уңай барсын, яңа очрашулар шатлык һәм матур тәэсирләргә бай булсын! Үзегезгә һәм якыннарыгызга ныклы сәламәтлек, бәхет һәм уңышлар насыйп булсын!

Фото «ТР ДЭБИ» ДАУ матбугат хезмәтеннән; Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районыннан алынды

Илшат Нуриев,
Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башлыгы, Арча район Советы рәисе

СЕЗНЕҢ ХЕЗМӘТ ЮЛЫГЫЗ – ЛАЕКЛЫ ҮРНӘК

– Хөрмәтле Илнур Мәхмүтович!

Арча районы халкы һәм шәхсән үз исемемнән Сезне юбилеегыз белән котлыйм!

Сезнең хезмәт юлыгыз – һөнәри осталык һәм туган республикабызга намус белән хезмәт итү үрнәге ул. Максатчанлык, җаваплылык, төгәл билгеләнгән принциплар, хезмәт сөючәнлек сыйфатлары Сезгә республика территориясен үстерүгә, татарстанлылар тормышына уңай үзгәрешләр кертүгә юнәлдерелгән иң кыю планнарыгызны тормышка ашырганда уңышка ирешергә мөмкинлек бирә.

Шушы күркәм бәйрәмегез көнендә Сезнең белән бергә эшләгәндә алган тирән тәҗрибә, муниципаль районнарны модернизацияләүгә һәм республика җитәкчелеге белән җирле үзидарә вәкилләре арасында нәтиҗәле хезмәттәшлек итүгә керткән саллы хезмәтегез өчен рәхмәт сүзләребезне кабул итеп алыгыз.

Хөрмәтле Илнур Мәхмүтович! 50 яшь – һәркемнең тормышындагы гәҗәеп бер чор ул. Бу яшьтә бай тормыш тәҗрибәсе дә, зирәк акыл да бар, инде бик күп эшләр башкарылган, шул ук вакытта киләчәктә яңа планнар көтеп торган чак. Ниятләрегезнең барысы да уң булсын, ә хезмәт сөючәнлегегез, тормышны яратуыгыз, эшлеклелек сыйфатларыгыз киләчәктә дә Сезгә күркәм башлангычларыгызны гамәлгә ашырырга ярдәм итсен. Үзегезгә һәм якыннарыгызга ныклы сәламәтлек, бәхет һәм иминлек телим! Юбилеегыз белән!

Рягат Хөсәенов,
Лениногорск шәһәре мэры, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы башлыгы

ТУГАН ТАТАРСТАНЫБЫЗНЫҢ ҮСЕШЕ ХАКЫНА

– Хөрмәте Илнур Мәхмүтович!

Лениногорск районы халкы һәм шәхсән үз исемемнән Сезне юбилеегыз белән тәбрик итәм!

Бу көнне Сезгә бик күп җылы сүзләр, котлаулар, рәхмәтләр һәм ихтирам сүзләре әйтелүенә иманым камил. Аларның иң ихласларына һәм изгеләренә кушылырга һәм Сезгә бәхет, иминлек теләргә рөхсәт итегез.

Сез үзегезнең гомерегезне Ватаныбыз, туган Татарстаныбыз иминлегенә багышлап, фидакарь хезмәтегез белән зур нәтиҗәләргә ирештегез һәм хезмәттәшләрегезнең хөрмәтен казандыгыз. Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе урынбасары – Президентның Территорияләр белән эшләр идарәсе башлыгы вазифасында Сез безнең республиканың муниципаль берәмлекләре эшчәнлеген күз уңында тотасыз һәм әлеге территорияләрнең үсешенә зур өлеш кертәсез.

Сез Татарстанның муниципаль районнары эшен бөтен нечкәлекләренә кадәр белеп торасыз, идарәчелек эшендә тирән тәҗрибәгез, финанс өлкәсендә белемегез һәм оештыру сыйфатларыгыз бар. Күпсанлы югары дәүләт бүләкләре дә Сезнең эшчәнлекнең сокландыргыч нәтиҗәләре турында сөйли.

Хөрмәтле Илнур Мәхмүтович! Ихлас котлауларыбызны кабул итеп алыгыз. Сез башкарган дәүләт эшләренә яңадан-яңа уңышлар насыйп булсын! Үзегезгә һәм якыннарыгызга ныклы сәламәтлек, иминлек, шатлык-куанычлар һәм уңышлар телим!

Фото Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы матбугат хезмәтеннән; Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы матбугат хезмәтеннән алынды

Ранис Камартдинов, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы башлыгы

МУНИЦИПАЛЛАРГА ТЕРӘК

– Хөрмәтле Илнур Мәхмүтович!

Буа районы халкы һәм шәхсән үз исемемнән Сезне юбилеегыз белән ихлас котлыйм!

Бүген Сезнең өчен истәлекле көндә республика районнарының җирле үзидарә органнары, шул исәптән безнең районның да эшчәнлеген камилләштерү мәсьәләләрен даими игътибар үзәгендә тотуыгыз өчен рәхмәтемне һәм ихтирамымны җиткерәсем килә. Озак еллар дәвамында ТР Президенты Аппараты Җитәкчесе урынбасары – ТР Президентының Территорияләр белән эшләр идарәсе башлыгы вазифасында эшләп, Сез республика җитәкчелеген муниципалитетлар белән бәйләп торган мөһим буынга әйләндегез. Хакимиятнең төрле дәрәҗәдәге вәкилләренең үзара нәтиҗәле хезмәттәшлеген тәэмин итеп, Сез территорияләрнең эзлекле рәвештә үсүенә, Татарстаныбызның социаль-икътисадый хәлен ныгытуга һәм татарстанлыларның тормыш рәвешен яхшыруга хезмәт итәсез. Халыкның тормыш рәвешен яхшыртуга юнәлтелгән республика һәм федераль программаларда катнашу мөмкинлеге нәтиҗәсендә районда барган үзгәрешләр өчен буалылар бик рәхмәтле. Монда Сезнең дә өлеш зур. Сезнең фидакарь хезмәтегез, актив гражданлык позициягез һәм һөнәри осталыгыгыз хөрмәткә лаек. Хезмәт тәҗрибәгез, дипломатик һәм эшлеклелек сыйфатларыгыз нәтиҗәсендә Сез иң катлаулы бурычларны да хәл итә ала торган көчле җитәкче абруен яуладыгыз.

Хөрмәтле Илнур Мәхмүтович, юбилей көнендә ихлас теләкләребезне җиткерәбез һәм җаваплы вазифагызда уңышлар телибез! Үзегезгә һәм якыннарыгызга бәхет, көч-куәт, күңел тынычлыгы, иминлек, уңышлар һәм ныклы сәламәтлек насыйп булсын!

Аяз Шәфигуллин, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы башлыгы, Ютазы район Советы рәисе

КӨЧЛЕ ШӘХЕС

– Хөрмәтле Илнур Мәхмүтович!

Ютазы районы халкы һәм шәхсән үз исемемнән юбилеегыз уңаеннан ихлас котлауларны кабул итеп алыгыз!

Бүгенге көндә ТР Президенты Аппараты Җитәкчесе урынбасары – ТР Президентының Территорияләр белән эшләр идарәсе башлыгы буларак, Сез Татарстан Республикасы Президентының, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары белән үзара хезмәттәшлеген тәэмин итүгә, Татарстан Республикасының район һәм шәһәрләрендәге иҗтимагый-сәяси һәм социаль-икътисади вазгыятькә мониторинг алып баруга юнәлтелгән, республиканың муниципаль берәмлекләрен үстерү буенча мөһим дәүләт эшләре белән шөгыльләнәсез.

Сез республикада перспективалы һәм нәтиҗәле эшли торган җитәкчеләр исәбенә керәсез. Зирәк акыллы, талантлы, тәҗрибәле сәясәтче һәм көчле шәхес. Сезнең актив тормыш позициягез, югары һөнәри осталыгыгыз һәм хезмәт сөючәнлегегез турында бик күпләргә мәгълүм. Без Сезгә җирле үзидарә мәнфәгатьләренә карата игътибарлы булуыгыз һәм ярдәм итүегез өчен рәхмәтле.

Хөрмәтле Илнур Мәхмүтович! Ихлас йөрәктән Сезгә Татарстан территорияләрен үстерү кебек җаваплы хезмәтегездә уңышлар телим! Үзегезгә һәм якыннарыгызга ныклы сәламәтлек, бәхет, уңышлар, иминлек юлдаш булсын!

Фото Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы матбугат хезмәтеннән; Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы матбугат хезмәтеннән алынды



Нәҗип Хаҗипов,
Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
башлыгы

“ ТЕЛӘЧЕ ҖИРЕНДӘ ТӘРБИЯЛӘНГӘН

– Хөрмәтле Илнур Мәхмүтович!

Теләче районы халкы һәм шәхсән үз исемемнән Сезне юбилеегыз белән чын күңелдән котлыйм!

Бүген без Сезне зирәк җитәкче һәм тирән ихтирамга лаек кеше буларак олылыйбыз. Сез – районыбыз тарихында якты эз калдырган һәм аның үсешенә, чәчәк атуына зур өлеш керткән шәхес. Хезмәт юлыгыз Теләчегә өзелмәс җепләр белән бәйләнгән. Туган ягыгыз Сезне татарның милли гореф-гадәтләренә, туган телгә, хезмәткә ихтирам традицияләрендә тәрбияләгән, шуның нәтиҗәсендә Сез чын мәгънәсендә үз эшенең остасы һәм ачык күңелле, ярдәмчел кеше булып өлгергәнсез.

Илнур Мәхмүтович, белгәнебезчә, Сез күренекле педагоглар гаиләсендә үскән татар интеллигенциясе вәкиле. Кече яшьтән бай татар мәдәниятен сеңдереп үсеп, тырыш хезмәт һәм талантыгыз нәтиҗәсендә татар милләтенең укымышлы улы булып җитешкәнсез. Эш сөючән, җаваплы, ватанпәрвәр шәхес булуыгыз һәркемне сокландыра. Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Президентының Территорияләр эшләре буенча идарәсе башлыгы вазифасында Сез җирле үзидарәне үстерү һәм муниципаль районнарның хакимият органнары белән республика җитәкчелеге арасында элемтәләр булдыру буенча мөһим эш башкаруыгызны дәвам итәсез. Сезне Теләченең һәрбер кешесе белә дисәк тә, һич арттыру булмас, чөнки 10 елдан артык һөнәри эшчәнлек елларын Теләчегә багышладыгыз, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы хакимиятенең аппарат җитәкчесе булып эшләдегез.

Еллар узып, Сез югары дәрәҗәдәге җитәкче һәм күренекле җәмәгать эшлеклесе булгач та, кече Ватаныгызга җылы мөнәсәбәтегезне саклыйсыз, якташларыгыз өчен терәк һәм якын кеше булып каласыз.

Без Сезгә Иске Җөри авыл җирлегенә, Иске Җөригә күрсәткән ярдәмнәрегез өчен рәхмәтле. Иске Җөри урта гомуми белем бирү мәктәбе татар телен саклау һәм өйрәнү символы булып тора. Без Сезгә белем бирү учреждениесенең яңа бинасы төзелешенә булышлык итүегез өчен бик рәхмәтле. Район территориясендә сәламәт яшәү рәвешен, физик культураны һәм массакүләм спортны пропагандалауга зур өлеш кертәсез. Туган ягыгызның үсешенә даими игътибарыгыз чиксез хөрмәткә лаек. Теләче халкы якташының хезмәтендә биек үрләр яулавы белән генә түгел, ә туган җиренә тугры калуы белән дә хаклы рәвештә горурлана. Теләче кешеләре өчен Сез зыялы шәхес, оста оештыручы һәм туган ягына сак карый торган олы йөрәкле кеше үрнәге булып торасыз.

Хөрмәтле Илнур Мәхмүтович! Юбилеегыз белән ихлас котлауларны кабул итеп алыгыз. Сезгә республика иминлеге хакына башкара торган җаваплы дәүләт хезмәтендә алга таба да уңышлар телибез! Игелекле ниятләрегезгә һәрвакытта да уңышлар юлдаш булсын, яңа проектларыгыз нәтиҗәләре белән сөендерсен! Үзегезгә һәм якыннарыгызга бетмәс-төкәнмәс көч-куәт, гармония, иминлек, шатлыклар, бәхет, уңышлар һәм ныклы сәламәтлек телибез!

Фото Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районыннан алынды

КЫЗЫЛ БАЙРАК

Автор: Руфия Фазылова

«ШВЕЦАРИЯДӘ ЯШИБЕЗ!»

Югары Ослан районының Кызыл Байрак авылына баргач, җирле халык шулай диде. Авыл Идел елгасының уң як ярына урнашкан. Тирә-якта – нарат агачлары, таулар... Гаҗәеп матур җирләр. Шуңа да Кызыл Байрак әдәбият әһелләре, сәнгать кешеләренең яраткан урыны саналган: җәйләрен бирегә килеп, дача арендалап яшәгәннәр. Без дә, истәлекләрне яңартып, «Кечкенә Швецария» буйлап сәяхәт кылдык.

Фото: Лилиана Вәлитова

КҮП БАЛАЛЫ ГАИЛӘ

Кызыл Байрак Шеланга авыл җирлегенә керә. Зур түгел ул, 110 кеше теркәлгән, ә ел әйләнәсе 80ләп кеше яши. Нигездә өлкән яшьтәгеләр гомер итә, яшь гаиләләр дә бар. Мисал өчен, алты ел элек, Казанда туып-үсеп, фатир алып яши башлаган ир белән хатын Кызыл Байракка күченеп кайткан. Иң беренче әлеге күп балалы гаилә янына юнәлдек.

Диләрә һәм Шамил Әхмәровларның олы кызлары Мияга ун яшь, уллары Камилгә – тугыз, төпчекләре Әминәгә ике яшь икән.

– Минем бала вакытым Кызыл Байракта узды, – диде гаилә башлыгы. – Башта без бу йортны дача урынына тоттык. Йортыбызның икенче катыннан Идел күренә, елга кул сузымында гына бит. Шәһәр һавасыннан соң биредә тән генә түгел, җан да ял итә. Шуңа да авылга кайтырга карар кылдык.

Шамил атаклы мәгърифәтче, «Мәктәп» журналын нәшер итүче Шиһап Әхмәровның нәселен дәвам итүче, дүртенче буын онык. (Мәгърифәтче 1882–1966 нчы елларда яшәгән.) Кызыл Байрак авылын оештыручыларның берсе нәкъ менә Шамилнең бабасы булган.

Тарихка күз салсак, 1920 нче елларда татарларга рәсми рәвештә яр буенда яшәргә рөхсәт ителә. Карар чыкканнан соң, Шиһап Әхмәров Кызыл Байракка кешеләр күченеп килсен өчен төрле хатлар яза. Һәм теләгенә ирешә – Арча якларыннан беренче биш гаилә Кызыл Байракка килеп урнаша. Шиһап Әхмәров үзе дә җәйләрен бирегә кайтып яши башлый. Авылның даны тиз тарала: соңрак Апас районының Шыгай авылыннан да берничә гаилә килеп төпләнә. Аннан соң мишәр ягы – Ульяновскидан ир белән хатын килә. Иң кызыгы – җирле халык телендә әлегә кадәр «Арчалар урамы», «Апаслар урамы», «Мишәрләр урамы» дигән атамалар сакланып калган. Гәрчә инде күптәннән һәр урамның үз рәсми исеме булса да.

Сүзне яшь гаилә белән башлаган идем... Шамил белән Диләрә икесе дә югары белемле белгечләр. Гаилә башлыгы – Казан авиация институтын, хуҗабикә Казан дәүләт финанс-икътисад институтын тәмамлаган. Без килгәндә гаилә тулы составта иде. Атна уртасында балаларның өйдә булуын күргәч:

– Авырып торалармы әллә? – дип сорап куйдым.

– Балалар быел өйдә генә укыды, – диде Шамил. – Узган ел, март аенда онлайн укуга күчтек тә, шуннан мәктәпкә бармадылар. Дөрес, чирек азагында сыйныфташлары янында контроль эш эшләп кайталар. Март аеннан мәктәпкә йөрерләр инде, укытучыларын, сыйныфташларын сагындылар.



Диләрә һәм Шамил Әхмәровлар алты ел элек Кызыл Байракка күченеп кайткан.

– Миңа кадәр мәктәп бар иде, шулай ук бер укытучы гына укыткан, – ди Сания Борһанова.

Иске клуб бинасы ярым җимерек хәлгә килгән.

Мия Шеланга урта мәктәбенең өченче, Камил икенче сыйныфында белем ала икән. Үзләре әйтүенчә, «5» билгеләренә генә укыйлар.

– Мәктәп укытучылары турында бары яхшы фикер генә әйтә алабыз, – диде Диләрә. – Бездә бит ничектер авыл мәктәпләренә кимсетеп карау сизелә, янәсе, белем дәрәҗәсе түбән. Чын күңелдән әйтәм: Шеланга мәктәбенең укытучылары белемле дә, тәрбияле дә.

– Ә ни өчен бу уку елын балаларыгыз өйдә укыды? – дим.

– Пандемия башлангач, вирустан куркып калдык. Беренче сәбәп шул. Икенчесе – балаларны мөстәкыйль рәвештә белем алырга өйрәтәсебез килде. Үзләре эзләнсен, укуның кадерен аңласыннар, дидек. Мөстәкыйльлеккә өйрәнделәр, без моңа шат. Хәзер тыныч күңел белән мәктәпкә җибәрсәк тә була.

БЕРДӘНБЕР УКЫТУЧЫ

Сания Борһанова – Кызыл Байракның бердәнбер укытучысы. Дөрес, башлангыч мәктәп 2008 елда ябылган инде. Бүгенгә көндә авылның өч баласы Шеланга мәктәбенә йөреп укый.

– Безнең мәктәп аз комплектлы иде, – дип сүзен башлады мөгаллимә. – Башта балалар башлангычта дүрт ел укыдылар, аннан программаны өч еллыкка калдырдылар бит. Өч сыйныфка ундүрт бала иде. Барысын да үзем укыттым.

– Ә балалар бер-берсенә комачауламый идеме соң? – дим, аптырап.

– Юк, киресенчә, бер-берсенә булышалар иде. Зуррак укучылар, кечкенәләрне энеләре, сеңелләре кебек карап, ярдәм итеп тордылар.

– Мин КДУның рус филология факультетын 1978 елда тәмамлап кайттым, – дип сүзен дәвам итте Сания апа. – 1980 елдан Кызыл Байрак башлангыч мәктәбендә эшли башладым. Миңа кадәр мәктәп бар иде, шулай ук бер укытучы гына укыткан. 1962 елда ачылган ул. Егерме сигез ел эшләгәч, яраткан эш урынымны ташларга туры килде – мәктәп яшендәге балалар бетте. Ике-өч баланы өч чакрым ераклыктагы Шеланга белем бирү үзәгенә йөртеп укыта башладылар.

Сания апа Кызыл Байракта туып-үскән. Тормыш иптәше белән ике ул үстергән. Бүген төп нигезендә ялгызы яши. Авылның гөрләп торган чакларын бик яхшы хәтерли ул.

– Кызыл Байракта 1980 нче елларда совхоз бик көчле эшләде, шуңа да авылда яшьләр дә кала иде. 90 нчы еллардан соң авыл күзгә күренеп кечерәя башлады. Совхоз таркалды – эш урыннары бетте. Бу минем әби-бабай нигезе. Алар 1925 елда Түбән Новгород якларыннан бирегә күченеп килгәннәр. Башта землянкада яшәгәннәр, аннан кечкенә генә өй салганнар. Заманасына күрә инде...

Сания апа үзе Шеланга мәктәбендә укыган, чөнки ул балачакта Кызыл Байракта белем үзәге булмаган. Казанга барып белем алгач та, туган ягына кайту ягын караган.

– Татарстанда бүтән мондый матур урын юк бит! – диде ул. – Кешеләргә шаккатам: ничек бу җәннәт почмагын ташлап китеп була?!

Мөгаллимә быел сиксән яшен тутырган. Тик һич кенә дә аңа үз яшен бирмисең! Яшь булып калуының сере белән кызыксынгач, Сания апа болай дип җавап бирде:

– Актив тормыш рәвеше алып барам. Күңелсез уйларга урын калдырмыйм. Күп еллар кышын да Идел елгасында коендым. Дөрес, соңгы елларда коенмыйм инде, аягыма операция ясаттым. Табиблар кушмый. Шулай да өйдә салкын су белән юынам, үземне чыныктырам. Контраст душның файдасы бик зур, киңәш итәм!

МӘКТӘП УРЫНЫНА КЛУБ?

Сания Борһанова хезмәт куйган мәктәпне карап чыктык без. Ул бүген клуб буларак эшли икән. 1960 нчы елларда салынган бина ул. Шуннан бирле бер тапкыр да ремонт күрмәгән. Әмма бүтән чара юк, клуб ярым җимерек хәлгә килгәч, бинасы әйбәтрәк дип, мәдәният үзеген бирегә күчергәннәр. Нәтиҗәдә, ярты гасыр элек салынган бина хәзер күз өстендәге каш кебек – китапханә дә, ФАП та биредә.

Юк, кимсетеп әйтүем түгел, киресенчә, проблемадан чыгу җаен тапканнар, диюем. Клуб мөдире Рафилә Ганиятова халыкның күңелен күрергә тырыша. Өлкәннәр өчен төрле кичәләр оештыра.

– Мин китапханә эшен дә алып барам, – диде Рафилә апа. – Ярты ставкада китапханәче, ярты ставкада клуб мөдире булып эшлим. Кеше саны күп түгел бит бездә. Шулай да китапханәгә йөрүчеләр шактый. Мәктәптә укучы балалар да килгәли, даими рәвештә газета-журналларны алып укучылар да бар.

Клубның хәзерге залы мәктәп сыйныфы булган. Хәтта ул чордан калган агач парталар да саклана. Алай гына да түгел, балаларның кайбер кул эшләре дә тора. Ишек алдында да кайчандыр мәктәп укучылары утырткан чыршылар үсеп утыра.

Клуб, китапханә бүлмәсеннән аермалы буларак, фельдшер-акушерлык пункты ремонтланган. Әллә кайчангы буяулары кубып беткән, пленка кадакланган клуб тәрәзәләреннән соң, ФАПка кергәч, дөнья яктырып китте.

– Рәсми рәвештә минем карамакта 83 Кызыл Байрак авылы кешесе, – дип аңлатты фельдшер Светлана Матягина. – Ләкин җәй көннәрендә кеше саны бермә-бер арта. Кем мөрәҗәгать итсә дә, беренче ярдәмне күрсәтәм.

– Китапханәгә йөрүчеләр шактый. Мәктәптә укучы балалар да килгәли, даими рәвештә газета-журналларны алып укучылар да бар, – диде Рафилә Ганиятова.

– Рәсми рәвештә минем карамакта 83 Кызыл Байрак авылы кешесе, – дип аңлатты фельдшер Светлана Матягина.



Фельдшер ханым гаиләсе белән күрше Шеланга авылында яши. 1991 елда Яшел Үзән медицина училищесын тәмамлап, юллама белән бу якларга килгән. Һәм биредә яшәп калган.

– Фельдшер булып эшли башлаганга, быел утыз ел була, – диде Светлана Владимировна. – Хезмәт юлымны Кызыл Байракта башладым. Күз алдына китерегез: бер авыз сүз татарча белмим. Ә мине чып-чын татар авылына җибәрделәр. Ул чорда русча бөтенләй белмәүче кешеләр дә бар иде. Хәер, хәзер дә минем белән бары татар телендә сөйләшүче әбиләрем бар.

– Аңлашасызмы? – дим.

– Әйе, акрынлап татар телен өйрәндем, тик сөйләшмим. Ничектер кыенсынам.

– Кызыл Байракта нинди халык яши? – дим.

– Бик тәрбияле кешеләр яши. Хәтерлим, училищены тәмамлагач та, Кызыл Байракка дип юллама бирделәр. «Бармыйм. Татар авылы, үзе кечкенә дә икән», – дим. Тик уку йортының җитәкчесе картага төртә-төртә аңлатты: «Менә, кара, Идел елгасы ярында ук урнашкан бит. Кечкенә авылда халык бердәм була. Киреләнеп торсаң, хәзер берәр юлсыз, бик ерак авылга җибәрәм», – диде. Шуннан ризалаштым инде. Ул карарыма бер дә үкенмәдем. Халык белән аңлашып эшлибез. Монда хәзер күбрәк өлкәннәр яши. Өйләренә барып хезмәт күрсәтәм. Бөтен кешедә телефоным бар, кан басымын үлчәргә булса да чакыралар.

САЛИХ СӘЙДӘШЕВ ЭЗЕ...

Кызыл Байракта татар зыялылары ял итәргә яраткан, дигән идем. Алар арасында күренекле композитор Салих Сәйдәшев тә бар. Татар профессиональ музыка сәнгатенә нигез салган бу шәхес кечкенәдән бирегә кайтып йөри торган булган. Соңрак Салих Сәйдәшев үзенең чордашлары, иҗатташлары – Шәриф Камал, Гадел Кутуй, Галимҗан Ибраһимов, Һади Такташ, Кәрим Апанаевлар белән дә кайтып йөргән.

– Кызыл Байракта һәр йортка мемориаль такта эләргә була, чөнки авыл даһилар җыела торган урын булган, – дип сөйли Шамил Әхмәров. – Мәсәлән, беренче урамда композитор Рөстәм Яхин яшәгән. Рояленда уйнап, бөтен авыл кешеләрен ял иттергән ул. Кызыл Байрак кичен бер ял итү үзәге кебек гөрләп торган: композиторлар, шагыйрьләр, табиблар, кыскасы, бөтен татар һәм рус интеллигенциясе биредә булган.

Салих Сәйдәшевне Кызыл Байрак белән бәйләүче җепләр хакында аерым язу кирәктер. Авылга нигез салучыларның берсе Шиһап Әхмәров турында алдарак әйтеп узган идем. (Габдулла Тукайның якын дусты да булган ул.) Мәгърифәтче Салих Сәйдәшевнең бертуган апасы Әминәгә өйләнә. Әти-әнисе үлү сәбәпле, Салих кечкенәдән апасы гаиләсендә тәрбияләнә. Шиһап Әхмәров аңа яхшы музыка белеме бирә, атаклы остазларда укыта. Кечкенә Сәйдәш җәйләрен апасы, җизнәсе белән Кызыл Байракта уздыра. Композитор булып өлгергәч тә, Иделнең уң як ярында урнашкан авылны онытмый. Авыл өлкәннәре әле дә аның, көймәгә утырып, көй иҗат итәргә берәр кечкенә утрауга китәргә яратуын искә алып сөйли.

Кызыл Байракта атаклы композитор хөрмәтенә дистә еллардан бирле «Сәйдәш аланы» сәнгать бәйрәме үткәрелеп килә. Моны Рөстәм Әхмәров белән Галиәскәр Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры директоры Шамил Закиров башлап җибәргән була. Шамил Зиннуровичның вафатыннан соң да, «Сәйдәш аланы» яшәүдән туктамый. (Дөрес, соңгы елларда ул аның кадәр масштаблы узмый.) Шамилнең әтисе, танылган табиб Рөстәм Әхмәров, Салих Сәйдәшев исемендәге Фонд булдырган, шуның җитәкчесе булып тора. Биш ел элек композиторга багышланган китап чыгарган. Хәзерге вакытта Салих Сәйдәшевнең фотоларыннан торган зур фотоальбом эшләргә ниятлиләр.

...Кызыл Байрак авылы табигатен язып, сөйләп бетерү мөмкин түгел. Аның бөтен гүзәллеген күрү өчен җәй көне килергә кирәктер, мөгаен. Хәер, кышын да сихри бер матурлык бар биредә. Һәр йорт тәрәзәсеннән, ишек алдыннан җәйрәп яткан Идел елгасы күренә... Чыннан да, иҗат итәр өчен, илһам алыр өчен бик матур урыннар монда.

Кызыл Байрактан киткәндә бер фикер туды: татарның зыялылары белән бәйләп, ни өчен биредә туристлык маршруты оештырмаска? Шәһәргә якын, табигате – искиткеч. Шул рәвешле авыл да яшәрер иде. Берәр меценат яки эшкуарны эзләп карыйкмы әллә?!

ТАРИХ БИТЛӘРЕННӘН

Рафилә Хәмидуллина, Кызыл Байрак авылы китапханәчесе:

– 1920 нче елларда татарларга рәсми рәвештә елга яр буйларында яшәргә рөхсәт ителә. Безнең авылга да 1924 елда нигез салына. Бу эштә Татар Үзәк башкарма комитеты рәисенең беренче урынбасары Гали Ганиевнең роле зур була. Революциягә кадәр Идел елгасының уң як яры итальян алпавыты җирләре булган. Алар игелгән, уңдырышлы туфрак саналган.

Кызыл Байрак белән бергә, Идел буенда Берек, Нариман, Бакчасарай кебек татар авыллары да оеша. (Тарихтан беләбез: Иван Грозный гаскәре Казан ханлыгын басып алганнан соң, су буенда урнашкан авыллардан татарлар куыла. Татарларга су буйларында яшәргә рөхсәт ителми. – Авт.) Шул рәвешле татарлар да янәдән Идел елгасы яр буйларында яши башлый. Авылның исеме исә Совет хакимияте хөрмәтенә бирелгән.

ТАТАРСТАНДА УКЫЙСЫҢ –

«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

Реклама 16+

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

ТАТАРСТАНДА ҖИҢӘСЕҢ –

«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

ТАТАРСТАНДА ЭШЛИСЕҢ –

«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

ТАТАРСТАНДА ЯШИСЕҢ –

«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

WWW.PROTATARSTAN.RU

2021

ГОД РОДНЫХ ЯЗЫКОВ И НАРОДНОГО ЕДИНСТВА
В РЕСПУБЛИКЕ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА
ТУГАН ТЕЛЛӘР ҺӘМ ХАЛЫКЛАР БЕРДӘМЛЕГЕ ЕЛЫ

. . . .

. . . .

. . . .

. . . .

. . . .

. . . .

. . . .

. . . .

Татарстаннан кайнар сәлам!

2021

ГОД РОДНЫХ ЯЗЫКОВ И НАРОДНОГО ЕДИНСТВА В РЕСПУБЛИКЕ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА ТУГАН ТЕЛЛӘР ҺӘМ ХАЛЫКЛАР БЕРДӘМЛЕГЕ ЕЛЫ

Фото Карина Туктамышева архивыннан.

Фотода: Карина Туктамышева –
«Татарстанның чуваш гүзәле – 2018»

Татарстанда 116 262 чуваш кешесе яши
(2010 елгы халык санын алу
нәтиҗәләре буенча)